Татарстан Фәннәр Академиясе
Тарих институты

# САДРИ
# МАКСУДИ-АРСАЛ

## МИЛЛИЯТ ТОЙГЫСЫНЫҢ СОЦИОЛОГИК ӘСАСЛАРЫ

Казан – 1999

Китап басмага Тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм исламият бүлегендә әзерләнде

Профессор Яхъя Абдуллин редакциясендә

САДРИ МАКСУДИ-АРСАЛ. Миллият тойгысының социологик әсаслары. Казан, 1999. — 138 бит.

Китап татар һәм төрек халыкларының мәшһүр җәмагать һәм дәүләт эшлеклесе, галим һәм фикер иясе Садри Максудиның (1878—1957) 1955 елны Истанбулда нәшер ителгән атаклы әсәренең татар теленә тәрҗемәсе. Китап Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының матди ярдәме белән басылды.

## КИТАПНЫ БАСМАГА ХӘЗЕРЛӘҮЧЕЛӘР ИСЕМЕННӘН БЕРНИЧӘ СҮЗ

Садри Максуди (1878—1957) — күренекле җәмгыять эшлеклесе һәм галим-мөтәфәккир. Казан артында Ташсу дигән авылда мулла гаиләсендә дөньяга килә. 1888—95 елларда Казан мәдрәсәләренең берсендә, ә 1897—1901 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1902 елдан башлап Сорбоннада (Париж) хокук фәннәре һәм филология гыйлемен өйрәнә. Ватанына әйләнеп кайткач актив сәяси эшчәнлеккә тартыла, «Мөселман иттифакы» җитәкчеләренең берсе була. 1907 елда 2-нче, соңыннан 3-нче дәүләт думаларының депутаты итеп сайлана. Соңгысында думаның мөселман фракциясе белән җитәкчелек итә. Бу елларда аның патша самодержавиесенең милли сәясәтен фаш итеп һәм урыс булмаган милләтлрнең хокукларын яклап дәүләт думасында ясаган чыгышлары һәм вакытлы матбугатта басылган мәкаләләре зур яңгыраш табалар. Февраль революциясе алдыннан ул Казанда адвокатлык эше белән шөгылләнә, «Йолдыз» һәм башка матбугат органнарында языша.

С.Максуди төрки халыкларының азатлыгы һәм бердәмлеге идеясе тарафдары була һәм февраль революциясеннән соң милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсенә әйләнә. 1917 елда ул мөселман халыкларының милли-мәдәни автономиясе концепциясен нигезләүгә күп көч куя. 1917 елның маенда мөселман халыкларының Мәскәүдә узган 1 съездында Бөтенрусия үзәк милли шурасы составына кертелә. 1917 елны узган барлык мөселман съездларының да эшендә актив катнаша. 1917 елның азагында Милли мәҗлес составына сайлана һәм аның җитәкчеләреннән берсе була.

Большевистик хакимият тарафыннан милли-азатлык хәрәкәте эзәрлекләнә башлагач С.Максуди чит илгә китәргә мәҗбүр була. 30 елдан артык гөмерен ул Төркиядә уздыра. Төрек революциясе җитәкчесе К.Ататөрек белән якынлаша, 2 мәртәбә

Төркия парламенты (мәҗлесе) депутаты итеп сайлана. Төркия делегациясе члены буларак милләтләр лигасы эшендә дә катнаша. 1945 елдан ул Истанбул университеты профессоры һәм актив рәвештә фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Аның язган хезмәтләре хокук гыйлеме, тарих, шул хисаптан төрки тарих, лингвистика һәм фәлсәфә мәсьәләләренә карыйлар.

Совет хакимияте нығыгач милләт мәнфәгатен яклап эш иткән татар интеллигенциясенең башка вәкилләре кебек үк Садри Максудиның да хезмәтләрен уку-өйрәнү түгел; хәтта исемен дә телгә алырга ярамады. Аның милләт кайгысын кайгыртып Дәүләт Думасында сөйләгән кайнар нотыклары һәм ялкынлы мәкаләләре басылган гәҗит-журналлар ябык архивларның яшерен фондларында бикләнеп тотылдылар, ә чит илләрдәге эшчәнлеге һәм анда язылган хезмәтләре тимер пәрдә аша үтеп илгә керә алмадылар.

Ниһаять, 80-елларның азагында башлаган үзгәреш җилләре безгә мирасыбызны барлау һәм өйрәнү өчен мөмкинлекләр ачтылар. 1989 елның августында миңа Әбрар Кәримуллин белән бергәләп махсус чакыру белән Истанбулга «Төркиянең социаль һәм икътисади тарихы» буенча V халыкара фәнни конгресста катнашырга насыйп булды. Без икебез дә конгресс утырышларында докладлар белән чыктык һәм төрек туганнарыбыз тарафыннан тулы аңлашу таптык.

Конгресс барган көннәрдә безнең анда булуыбызны ишетеп Әнкарадан милләттәшебез Мәхмут Таһир килеп төште. Бу милләт җанлы кеше хезмәте буенча инженер-энергетик булса да гомерен милләтәшләребезне бергә туплауга, милли җәмгыятьләр оештыруга, милли мирасыбызны барлауга һәм өйрәнүгә багышлый. Күпкырлы эзләнүләре нәтиҗәсендә язылган мәкаләләрен үзенең катнашында оештырылган «Казан» журналында, Төркия һәм башка илләрдә чыккан фәнни җыентыкларда бастыра. Без Мәхмүт Таһир әфәнде белән ул көннәрдә күп сөйләштек һәм фикер алыштык. Бу фикри бәйләнешләр Казанга кайткач хат аша дәвам итте. 1991 елны килгән хатларының берсендә М.Таһир миңа Садри Максудиның «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән теоретик хезм-

әте барлыгы турында язды. Хат белән шушы хезмәтнең кайбер бүлекчәләренең ксерокста басылган күчермәсен җибәргән. Әгәр хезмәт мине кызыксындырса китапны тулысынча җибәрергә вәгъдә иткән иде. Килгән язмалар белән танышкач мин аңа китапны җибәрүен үтенеп хат яздым. Әмма җавап булмады һәм байтак вакыт үткәннән соң аның вафат булуы турындагы хәбәр килеп иреште.

Тора-бара Төркия белән бәйләнешләр киңәю юлына басты. Татарстаннан Төркиягә баручылар һәм Төркиядән Татарстанга килүчеләр ишәйде. Шундый төркемнәрнең берсе белән үземнең шәкертем Эльмир Губеев якыннан таныша. Моны белү белән аңа Садри Максудиның әйтелгән китабын китертү турында сүз алып барырга киңәш иттем. Төрек кардәшләребез озак көттермәделәр һәм безгә бу китапның 1975 елда чыккан басмасын җибәрделәр.

Китап кулга төшүгә Эльмир белән икебез аның «Миллият тойгысының социологик һәм биологик әсаслары», «Милләтләрнең барлыкка килүе» һәм «Милли хиснең барлыкка килүе» дигән бүлекчәләрен татарчага тәрҗемә итеп «Мирас» журналына тәкъдим иттек. Журнал редколлегиясе кулъязманы бик хуплап каршы алды һәм басарга да хәзерләде. Ләкин тора-бара редакциядә китапны тулысынча басу теләге уяна һәм безгә аның барлык бүлекләрен дә тәрҗемә итәргә тәкъдим ясала. Бу эшкә төрек теленнән хәбардар булган башка иптәшләрне дә тартырга туры килде. Эльмир Губеевтән тыш китапны төрекчәдән татарчага тәрҗемә итүдә бу юлларның авторы, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан философия фәннәре кандидаты Рашат Әмирханов, фәнни хезмәткәр Рафаэль Мөхәммәтдинов һәм Татар мәдәни үзәгеннән фәнни хезмәткәр Асия Рәхимова, Төркиядә укучы туташыбыз Ләйлә Гаффарова тартылды.

Китапның татарчага тәрҗемәсе «Мирас» журналының 1994—1996 елларда чыккан санарында дөнья күрде. Тәрҗемәне бу китап өчен хәзерләгәндә яңадан карап чыгылды, кайбер төзәтмәләр кертелде һәм китапка автор тарафыннан бирелгән искәрмәләр тәрҗемә итеп өстәлде.

Без хәзер милли тормышыбызда тирән үзгәрелләр дулкынына килеп кердек. Хәзергә бу үзгәрешләрнең кыйбласын билгели алырдай төпле бер милли идеологиянең нигезе салынмаган. Милләтнең киләчәген тәэмин итү өчен мондый нигез бик кирәк. Шунсыз бөтен милләттәшләребезнең игътибарын билгеле бер кыйблага җәлеп итеп булмаячак. Бу кыйбланы билгеләүдә һичшиксез милли мирасыбыз үзенең уңай ролен үти алачак. Садри Максудиның укучы игътибарына тәкъдим ителә торган «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән китабы һич шиксез мирасыбызны барлауда һәм милли кыйблабызны билгеләүдә мөһим роль уйнардай әсәр.

Бу фәлсәфи характердагы хезмәт беренче мәртәбә 1955 елда Истанбулда басылып чыга. Ул дөньякүләм танылган зур галимнәрнең хезмәтләренә һәм социологик тикшеренүләргә таянып язылган һәм «Ырык (раса) мәсьәләсе», «Милләт вә миллият», «Миллият мәсьәләсендә каршылыклы агымнар», «Тарихта миллият тойгысы» һәм «Заманыбызда миллиятчелек» исемле бүлекләрдән тора. Бүлекләрдә милләт вә миллият мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсле мәсьәләләр тикшерелә, аларга тирән фәлсәфи һәм социологик анализ бирелә. Әсәр каралган мәсьәләләрнең һәр яклап теоретик дәлилләнгән чишелеше белән характерлы.

Китапның тәрҗемәсе бераз җиңеләйтелгән һәм кыскартылган 1975 елгы басмасы нигезендә хәзерләнде.

Бу төрек теленнән татар теленә теоретик характердагы хезмәтне тәрҗемә итеп бирүнең беренче тәҗрибәсе. Шуңа күрә тәрҗемәдә төгәлсезлекләр дә булуы ихтимал. Алар өчен укучылардан алдан ук гафу үтенәбез. Тәрҗемә өстендә эш әле дәвам итәчәк. Аны камилләштерү буенча киңәшләрен җиткергән милләттәшләребезгә бик рәхмәтле булыр идек.

*Яхъя Абдуллин, профессор*

# САДРИ МАКСУДИНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Бу китап мәрхүм әтием Садри Максудиның иң соңгы язган һәм үзе зур әһәмият биргән хезмәте иде. Вафатыннан соң үткән елларда аның бу әсәренең әһәмияте ни дәрәҗәдә булганлыгы тагын да ачыграк күренде: бу әсәре С.Максуди өчен юлкүрсәткеч-белешмә булды, һәм аның тормышына мәгънә һәм хис өстәде, аның идеалларын мәңгеләштергән бер һәйкәл ролен үтәде. Кыскача итеп әйткәндә, Садри Максуди үзенең якты образы, шәхсияте, абруе һәм төрле төрки төркемнәр арасында вә өлкәләрдә башкарган эшләре бу дөньяда тоткан урыны белән гомуми төркилекнең бер символыдыр.

С.Максуди төркилекнең бер бишеге булган, ләкин гасырлар дәвамында бәйсезлеген югалтып яшәгән өлкәләрнең берсендә, Казан ханлыгының башкаласына якын Ташсу авылында дөньяга килгән һәм кече яшьтән әтисе имам Низаметдин әфәнденең Истанбулда басылган әлифба китабыннан укырга-язарга өйрәнгән.

19 нчы гасырның II яртысында Төркия белән башка төрки халыклар арасындагы мәдәни бәйләнешләр хәзерге бәйләнәшләрдән бик нык аерылып тора. Казанның зур китапчы сәүдәгәрләрендә Истанбулда яңа басылган гәзит һәм журналларны, ягъни айлык һәм атналыкларны дөньяга чыгуларына ук табарга була иде. Хәтта Истанбулдагы нәширләр теге яки бу китапны басканда Казандагы, Ташкенттагы, Бакудагы, Бакчасарайдагы таралышын да күз алдында тоталар иде.

Аннан казанлылар, хәзерге кебек, үзләренә руслар таккан татар исемен танымый да иделәр. Асылда дини белем бирү максаты белән ачылган мәктәп-мәдрәсәләр программасында дини фәннәрдән тыш укытылган гарәп һөм фарсы телләре янында төрек теле дә үз урынын алып тора.

С.Максудидан 10 яшькә өлкәнрәк булган һәм әле бик яшьли Казанның Галләмия мәдрәсәсенә җитәкче итеп куелган абыйсы һади Максудинның өе Истанбулдан кайтарылган гәҗит-журналлар белән тулы була.

Чынлыкта С.Максудиның балалыктан чыгып акыл җыйган еллары шушы шартларда барган һәм Истанбул фикере һәм хисе сеңгән шундый бер мохит эчендә аның күзләре ачылган.

Урамда урыс полициясен, тирә-юньдә урыс чиновникларын, казармаларда урыс гаскәрен күрү аның яшь йөрәген ризасызлык орлыклары белән тутырган.

Шуңа бәйле рәвештә, башлангыч белемне Ташсудагы мәчет каршындагы мәктәптә, урта белемне мәдрәсәдә алган яшь С.Максуди тирә-юнендәге кешеләрне гаҗәпләндереп, якыннарын борчуга салып, дусларын тирән уйланырга мәҗбүр итеп мөһим бер карарга килә: ул укуын урыс мәктәбендә дәвам итәчәк. Шушы карарга килгәч тә, ул мәдрәсә дипломын урыс учительская школасына илтеп тапшыра.

Гаиләсенең аның бу теләгенә каршы килмәве С.Максудига милли хисен кимсетмичә, аның өчен чит булган рус культурасын өйрәнүгә һәм шул ук вакыт үз теле турында да кайгырту, әгәр кирәк булса, бу юлда булган киртәләрне үтеп чыгу турында да уйларга мөмкинлек ача. Ул рус телен, рус әдәбиятын ныклап өйрәнүгә күп көч куя. Һәм моның беренче нәтиҗәсе 17 яшьлек студентның рус романы техникасын кулланып ана телендә милли роман яза башлавында күренә.

Яшь казанлының милли уй-омтылышлары салынган бу «Мәгыйшәт» исемле роман 1898 нче елда Казанда басылып чыга һәм Казан төркиләре әдәбиты тарихында үз урынын ала.

Шул ук вакытта яшь язучы вә шәкертнең күңелендә яңа омтылыш-хыяллар да туа башлый. Ул елларда Русиядә француз культурасына иярү бик көчле була, әдәбият дәресләрендә туктаусыз француз язучылары, француз фикер ияләре, француз тормышы, француз сәнгате турында сөйләнелә. Бу шартларда С.Максудиның күңелендә дә Русиядән Франциягә китеп, француз культурасы белән якыннан танышу, рус аристократлары кебек французча аралашу, француз университетында белем алу теләге туа һәм көчәя бара. Ул үзенең бу теләген гаиләсеннән яшерә. Шулай да абыйсы белән Кырымга җәйге сәяхәте вакытында үзен бик сокландырган, гаҗәпләндергән һәм яраттырган И.Гаспралы белән таныша һәм аңа хыялын-серен чишә.

Ул вакытта «Тәрҗеман» гәҗите аша бөтен төрки халыклар арасында миллиятчелек идеяләре тараткан И.Гаспралы бик мәшһүр шәхес була. Бу беренче очрашудан соң ук аның

белән хат алыша башлаган С.Максуди соңыннан аны үзенең рухи атасы дип таный.

С.Максуди Истанбул аша Франциягә барып чыга һәм 1901—1906 нчы елларда Парижда юридик белем ала. Ә бу елларда анда Яхъя Кемал, Ю.Акчура,[1] Әхмәт-Фәрит-тәк[2] тә укыйлар. Төрле тарафлардан Парижда тупланган яшь төрекләр бергә җыелып, бер туктаусыз Абдул Хамид дәвереннән чыгу юллары турында бәхес алып баралар һәм конституция әзерлиләр.

Минем әтием Яхъя Кемал белән бик еш очрашып тора, күп тапкырлар ресторанга кичке ашка киләләр. Сәяси белем алу белән бергә бөтен вакытын француз шигърияттен өйрәнүгә багышлаган Я.Кемал, үзенең соңгы шигырен укыгач, әтигә: «Җаным, син шигърияттә бернәрсә аңламыйсың», дигән. Әти исә аңа: «Синең белән һич тә җитди сөйләшеп булмый, чөнки син һәр сөйләшүне рифма сугышына әйләндерергә тырышасың», — дигән.

Шулай икесе ике караштa булуларына карамастан, төрки халыкларның үткәне турындагы уйлар бу ике егетне берләштерә, бер-берсен якынайта һәм очрашырга мәҗбүр итә.

С.Максуди, диплом алып, җитлегеп милли хисләр белән тулып, ашкынып 1906 нче елда Казанга кайта һәм актив эшчәнлек башлап җибәрә.

Ә бу вакытта Русиядә сәяси шартлар милли мөмкинлекләр ягыннан караганда бик кызыклы үзгәрешләр кичерә. Шуннан бер ел элек Конституция кабул ителә.[3] Азчылыкны тәшкил иткән һәм таралып яшәгән төрле төрки төркемнәр дә оешып сайлауларга әзерлек алып баралар. Садри Максуди да үзенең адвокатлык конторасын ачу уеннан кире кайтып, сәяси тормышка керә һәм үзенең кандидатурасын, Казан төркиләре исеменнән, парламентка сайлауга куярга карар бирә.

1906 нчы елның 21 нче августында, Измир кебек үзенең ярминкәсе белән мәшһүр булган, инде исеме руслаштырылган борынгы төрки шәһәр, төркиләр үзләре Мәкәрҗә дип атаган Нижний Новгородта Русия мөселманнары[4] съездында яңа гына укуын тәмамлап кайткан, ә хәзергә үзенең Париждан җибәреп торган һәм миллиятчелек рухы белән сугарылган мәкаләләре

белән И.Гаспралының «Тәрҗеман» гәҗите аша таныш булган яшь С.Максуди, съезд карары белән төзелгән сәяси партиянең җитәкче идарәсенә сайлана. «Дума» дип аталган урыс парламентына сайлауларда җиңгән, русча нотык сөйләве, тарихны яхшы белүе, югары культуралыгы һәм бик чиста французча сөйләшүе белән үзенә игътибарны тарткан С.Максуди, озак та үтми, парламент советы әгъзасы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Думаның бу һәм аннан соңгы чакырылышы утырышларында үз милләтенә олы мәхәббәт белән эш иткән һәм милләткә кагылган һәрбер куркынычка күкрәге белән ташланырга әзер булган, рәсми рәвештә Казан төркиләренең вәкиле булып та, гомуми төркиләр турында кайгыртып та сүз алып барган С.Максудиның нигезле сәяси нотыклары Русия төркиләре тарихында гына түгел, бөтен Русия тарихында да нык танылдылар.

Ул нотыкларның иң әһәмиятлеләрен искә төшереп үтик:

1. Казакъ вә кыргыз төрекләре яши торган урыннарга русларның килеп утыруы һәм төркиләрнең кулыннан аларның җирләрен тартып алуга каршы сөйләнгән нотык-протест.

2. Төркестандагы авылларда аракы сата торган урыннар ачуга каршы сөйләнгән нотык-протест.

3. Рус хөкүмәте госманлы империясенә каршы алып барган тышкы сәясәтен һәм бугазларга карата дәгъвасын дәвам иттерсә Русия төркиләренең хөкүмәткә каршы бойкот оештырачаклары турында кисәтү нотыгы.[5]

4. Бер рус депутатының Русия төркиләре арасында пантюркизм идеяләре киң таралган, ә бу Русиягә сәяси куркыныч тудыра дигән раславына җавап рәвешендә С.Максудиның монда эш пантюркизмда түгел, ә бары тик төрки халыкларда берләшү хисе тууы турында гына бара. Моның исә табигать кануннары нигезендә булган бер күренеш икәнлеген фәнни һәм тарихи дәлилләр белән раслап ясаган чыгышы рус матбугатында бик көчле реакция тудырды.

5. Русия төркиләренең иң югары салым түләүләренә дә карамастан, төрки мәктәпләрне тоту буенча чыгымнарның мәгариф министрлыгы бюджетына кертелмәве турындагы чыгыш.

6. 1908 нче елда булып узган сайлауларда парламентка үткән Төркестан һәм Әзербайджан депутатларының күренүе аркасында «думада күзәтелгән чатнауны» чагылдырган чыгыш.

С.Максудиның парламенттагы көрәштә күрсәткән батырлыгы, аннан соң 20 еллар үткәч тә, хәтта коммунистик режим чорында да, легенда шикелле, бабайлардан оныкларга килеп иреште.

Шулай да С.Максудиның төп сәяси эшчәнлеге һәм сәясәттәге зур роле царизм җимерелгәч башлана. Башта, дәүләт башына Вакытлы хөкүмәт килгәч, С.Максудига Төркестан белән идарә итү өчен вилаят оешмалары төзүне җайга салу эшен тәкъдим итәләр. Яшь миллиятче зур Төркестандагы гомум валиләрнең берсе булу турындагы бу мактаулы тәкъдимне шатланып кабул итә. Бу вазыйфасын үтәү юлында ул урыс коллегаларының каршылыгын я җайлап-сыйпап, я бәхәс белән, я күндерү юлы белән җиңеп, Төркестанда күп кенә мәдәни оешмаларның нигезен салуга, ә кайберләренең үсеше өчен чараларны билгеләүгә ирешә.

Әмма бераздан яшь идеалист-сәясәтче үзенең руслар тарафыннан Мәскәү, Петроград, Казан шикелле сәяси үзәкләрдән ераклаштырылган гына икәнлеген аңлый. Вакытлы хөкүмәт патшалык дәвере парламентының бу кайнар йөрәкле, ялкынлы ораторының киң аренага кайтып үзләренә проблемалар тудыруын теләмиләр.

Ләкин тарихи агыш милләт өчен уңайлы вакыйгаларга да бай. Руслар белән бертигез идарә хезмәте алып бара алган кеше тагын да мөһимрәк хезмәт урыны дәгъваларга хаклы була. Нәкъ менә шул вакыт Мәскәүдә «Русия мөселманнары корылтае» исеме астында бер җыелыш уза. Үзенең анда катнаша алмавына да карамастан, Садри Максудига мөһим вазыйфа йөкләнә: ул корылтайның карары белән мәйданга килгән үзәк шура әгъзасы итеп сайлана.

Садри Максуди Төркестаннан кайтып икенче Милли корылтайны әзерләүгә зур көч куя. Патша хөкүмәте вакытындагы шикелле «мөселман» сүзе астына качуның кирәге беткәнлегенә ышанып, Садри Максуди Русия төркиләренә инде үз исемнәре

астында җыелырга вакыт җитте дигән фикергә килә. Ләкин аңа башкаларның фикере белән дә, шул исәптән тарихны белмәүчеләр фикере белән дә хисаплашырга туры килә.[6] Ахыр чиктә ул үзе яратмаган «татар» дигән сүзне кулланырга, үзе «төрек» исеме кертүне уңышлы дип санаса да, «Русия төрек-татарлары корылтае» дигән исем белән килешергә мәҗбүр була.[7]

Садри Максуди һәм аның тарафдарларың төп максаты Русиядәге 30 миллионлы төрки халыкларны бергә туплап, бәйсезлеккә бер адым ясау, яңа Русия эчендә куәтле бер милли мохтәррият төзү була.

Ләкин Русиядә ул елларда бик катлаулы сәяси хәлләр туа. Һәм, әгәр картага күз салсаң, бу максатның әле тормышка ашмастай бер хыял икәнен күрергә була.

Ул вакытта Русия төркиләре арасында иң укымышлы һәм мәдәниле Казан төркиләре була. Шуңа таянып, кызганычка каршы, казанлылар арасында башка төркиләргә карата баш булу, аларга түбәнсетеп карау, беренче чиратта башкортларның лидеры булу уе белән йөрүчеләр килеп чыга һәм алар бердәмлекне бетерә торган сәясәт үткәрәләр.[8] Бу тарихи вакыйга һәм аны игътибарсыз калдыру һич мөмкин түгел.

1917-елның 22-июлендә Казанның Зур театры бинасында ачылган Корылтайда Садри Максудиның мохтәрият (автономия) идеясен дәлилләп ясаган чыгышы тыңлаучыларның милли хисләренә нык тәэсир итә һәм аларны үкси-үкси елата. Корылтай карары белән, оештырылачак автономияле төрки дәүләтенең башкаласы итеп Конья кебек дини мәркәз булган, Уфа шәһәре кабул ителә. Бераз соңарак, сайлаулар үткәрелеп, 1917-елның 30-ноябрендә Конституциясе Садри Максуди тарафыннан язылган яңа дәүләтнең Милли мәҗлесенең беренче утырышы уздырыла һәм дәүләт башлыгы итеп Садри Максуди тәгаенләнә.

Боларның барысына да Русия эчендәге каршылыклар мөмкинлек тудыра. Тора-бара Русия сәясәте мәйданнына Ленин дигән бер зат чыга һәм ул «хезмәтчел сыйныфлар хакы, буржуазия, эксплуататор» кебек сүзләр белән 1972 — елга кадәр әле Төркиядә дә колакларны тондырган лозунглар яудырып, күпләрнең

акылын чүпли башлый. Әле Уфада Милли мәҗлес чакырылганга кадәр үк Ленин һәм рус хөкүмәте милли хәрәкәт эшенә тыкшынып карады. Әмма ул вакыт алар Русиянең барлык өлкәләрен дә әле үзләренә буйсындыра алмый иделәр. Русия әле гражданнар сугышы хәлендә иде. Кызыллар белән аклар сугышты. Башта үзен большевик, аннан коммунист дип атаган кызылларның лидеры Ленин, хәйләкәр тактика кулланып, үзенең нотыкларында Русия империясенә кергән бөтен милләтләргә дә хөррият һәм бәйсезлек вәгъдә итте. Садри Максуди тирәсендәге күңелләре саф, әмма беркатлы кайберәүләр дә, киләчәктә нинди кармакка эләгәчәкләрен белмичә, бәйсезлеге шикле булган территориаль мохтәрият дигән нәрсәгә алданып һәм, большевиклар вәгъдәсенә ышанып эш итә башладылар. Боларга эчтән оештырылган хыянәтләр дә өстәлде. Нәтиҗәдә автономияле төрек-татар дәүләте тезләндерелде.[9]

Коммунистларның диварларга ябыштырган игъланнарында Садри Максудины үле яки тере килеш тотып китергән өчен зур бүләк вәгъдә ителә. Җимерелгән дәүләтнең башлыгы, авылча киенеп, авылдан-авылга качып йөреп, ниһаять, Финляндиягә чыгып китергә мәҗбүр була. Аннан ул Парижга күчә. Шушы вакытларда Садри Максуди, I Бөтендөнья сугышы проблемаларын хәл итү өчен җыелган Тынычлык конференциясендә Русия төркиләренең хокукларын яклап чыгышлар ясый. Ләкин көнбатышлылык һәм христианлык белән сугарылган һәм субъективизм уйдырмаларына баткан бу Конференция, Русия төркиләренең тормышын аңлаткан озын һәм тәфсилле Меморандум тәкъдим иткәч, аны кире кага.

Шулай итеп, Садри Максуди тормышының сәяси һәм милли көрәш дәвере тәмамлана. Үзен биләгән идеалларның җимерелүен тойган Садри Максуди китапханә стеналары эченә бикләнә, шушы вакыттан аның тормышының фәнгә багышланган дәвере башлана.

Парижда ике ел, Берлинда ике ел яшәү мөмкинлекләре тудыру өчен Садри Максуди китапханәләргә эшкә урнаша һәм төрки халыкларның үткәнен бөтен нечкәлекләре белән һәм һәр яклап өйрәнергә тырыша; шуның өстенә үзе генә белер өчен

түгел, башкаларны да өйрәтер өчен. Чөнки ул Көнбатышның төрки халыклар турында бернәрсә дә белмәгәнен күрә. Хәтта университет профессорлары арасында да төрки кавемнәрдән булган аварлар, печенглар һәм куманнарны герман ыругына карыйлар дип бәхәсләшүчеләр дә була. Чөнки көнбатышның мәгърифәтле, юнан тарихына кагылышлы һәр нәрсәне белгән, Перикл этенең барлык хосусиятләренә кадәр хәбәрдар булган көнбатыш интеллигенциясе Улугбек белән Фарабины тудырган, Сөләймания белән Таҗ-Мәхәлне мәйданга чыгарган бөек төрки милләтне белми һәм алар көнбатыш аңлаган культура кысаларына кертелмәгән килеш калалар. Шунлыктан Садри Максуди тюркологиягә кагылышлы белемен киңәйтү өстендә эшли, Парижда югары мәктәптә төрки халыкларның тарихларын укытуны юлга салырга тырышып, уңга-сулга талпына.

Әтием Садри Максуди өчен 1919—1923 еллар сәяси көчәнешләре, милли омтылышлары җимерелеп, сәяси банкротлыкка китерсәләр дә, «бәхетле еллар» булып калалар. Бу елларда ул, Европаның бөтен җәмәгатьчелеге кебек үк, большевиклар режимы җимерелүен бер көнлек эш дип саный. Моны көткән арада ул яраткан эше белән шөгыльләнә, төркилеккә кагылышлы фәнни тикшеренүләреннән ләззәт алып яши. Аннары, өч ел элек, Русиядән качканда аерылып калган гаиләсе белән кавыша. Һәм, ниһаять, гадәттәгечә үзен тыныч тотарга тырышып, газетларны күзәтеп бара. Төрек-грек сугышы һәм Мостафа Кемал эшчәнлеге анда зур милли өметләр уята, аның уңай якка үсеше Садри Максудиның күңелен шатлык белән тутыра. Шуның өстенә 1923-елның язында ул сабырсызланып көткән хәбәр дә килеп ирешә: ул Сорбоннага бәйле бер институтта «Төрки кавемнәр тарихы»ннан дәресләр һәм профессор дәрәҗәсе бирелүе турындагы хәбәр була. Шулай итеп, аңа укыта башлау мөмкинлеге ачыла. Аның декабрьдә башланган бу дәресләренә французлар белән беррәттән Парижда яшәүче төркиләр дә йөри. Аларның кайберләре газета-журналларда милли горурлыкларын белдереп мәкаләләр дә бастыралар. Беренче лекцияне тыңлаганнан соң ук журналист һәм депутат Алаэтдин Җәмил Тупчибашев тарафыннан Париждан

җибәрелгән һәм 1923-елның 16-декабрендә «Вакыт» газетасында басылган мәкаләдән ике генә җөмлә тәкъдим итәбез:

«Беренче мәртәбә бер мөселман һәм бер төрек Сорбоннада курс алып бару шәрәфенә иреште. 1923-елның 4-декабрендә, сишәмбе көнне Садри бейнең Сорбоннада укылган һәм бик дикъкать белән тыңланган беренче лекциясе аңа карата тирән ихтирам хсләре уяты. Сорбонна профессорларыннан месье Хаумант университет исеменнән залның өчтән икесен тутырган тыңлаучыларга Садри бейне тәкъдим итте».

Бу көннәрдә Садри Максудиның куанычы эченә сыймый иде. Берничә атна гына элек Әнкарада Республика игълан ителде. Шулай итеп, дөнья йөзендә яңа бер Төрек дәүләте туды. Яңа Төркияне күрү теләге белән янган Садри Максуди 1923—24 уку елы тәмалангач, җәйге каникулда бу дәүләтнең үзәгенә ашыга.

Төркиянең бәйсезлеге өчен күтәрелгән яңа көчләр, яңа нигездә оешкан хәрби берләшмәләр алдында изге хисләрен һәм шатлыкларын уртаклашуга ихтыяҗы туган төрек кавемнәре тарихы профессоры ул вакытларда иң парлак дәверен кичергән «Төрек учаклары»ның Истанбулда һәм Әнкарада аның өчен махсус оештырылган конференциядәрдә чыгышлар ясый. Һәм төрекләрнең күрсәткән хезмәтләренә, дәрәҗәләренә, шулай ук йомшак якларына анализ үткәрә, үткәнне күз алдыннан кичергәч, тууы мөмкин булган нәтиҗәләргә туктала. 1924-елның 14-ноябрендә Әнкарада узган конференциядә ул түбәндәгеләрне сөйли: «Төрекләр һәрчак идарә ягыннан көчле һәм куәтле дәүләт төзеделәр. Бары тик бу дәүләтләрнең башында торучылар экономикага, культурага тиешле бәя бирә алмадылар, аларның кыйммәтен һәм әһәмиятен аңлый алмадылар...»

Әтинең бу конференцияләре илдә зур кызыксыну уятты һәм матбугатта үзенең чагылышын тапты. Олы миллиятче, үзенә гази исеме бирелгән Мостафа Кемал да Садри Максудины кабул итә һәм аңа зур илтифат күрсәтә.

Парижга кире килеп, яңа 1924—1925 уку елын башлагач, Садри Максудига Ататөректән чакыру килә. Төркиянең мөгариф министры Хамдуллаһ Сунки бей катнашы белән ачыла-

чак Хокук мәктәбендә төрек хокукы дәресләрен алып бару өчен Садри Максуди Төркиягә чакырыла. Ул бу чакыруга бик шатлана, ләкин аптраушта да кала. Парижда, Сорбоннада Көнбатышны төрки дөнья белән таныштыруны ул үзенең зур хезмәте дип саный. Шулай ук аның яшәү шартлары да җайга салынган була. Аның монда фикердәш дуслары һәм интеллектуаль тирәлеге да була. Аннан соң 1924 елда Әнкара тормыш шартлары ягыннан да Париждан бик нык аерылып тора.

Бер-ике атна уйлаганнан соң, ул: «Мине анда тарихи хезмәтләр көтә», — дигән фикергә килә һәм мәгариф министрлыгына уңай җавап җибәрә.

Әмма Әнкарага килгәч ул күп кенә җитешсезлекләр, шул хисаптан Хокук мәктәбенең бинасының төзелеп бетмәгәнлеген һәм кадрлар да тупланмаганлыгын күрә. Сорбонна профессорына соңыннан «Тәгълим һәм тәрбия һәйяты» исемен алачак «Килешү һәм тәрҗәмә комиссия»сенең вакытлыча әгъзасы булырга туры килә.

Әнкараның беренче югары уку йорты, ахыр килеп университетның нигезен тәшкил итәчәк Хокук мәктәбе, 1925 елда тантаналы рәвештә ачыла һәм Садри Максуди анда әле моңарчы дөньядагы бер генә университетта да, беркем тарафыннан да укытылмаган яңа бер фән — «Төрек хокукы тарихы» курсын укыта башлый.

Бер яктан ул бу яңа фәнне төзү белән шөгыльләнсә, икенчедән Париждан Төркиягә кайтканда үз алдына куйган ике максатын да онытмый: боларның беренчесе төркиләрнең үткәнен өйрәнү һәм моның нәтиҗәләрен чит телләрдә бөтен дөньяга таныту өчен Тарих Академиясен төзү, ә икенчесе, төрек телен гадиләштерү һәм чит сүзләрдән чистарту өчен Тел Академиясен мәйданга чыгару. Күренгәнчә Садри Максуди, төп юнәлешләре, әле 50 елдан соң гына билгеләнәчәк, бүгенге Тел җәмгыятенең һәм Тарих җәмгыятенең нигезләрен салырга тырышкан. Бу ике фикерен ул, һәр форсаттан файдаланып, язуында һәм сүзендә пропагандалаган. 1928 елда, мәсәлән, ул үзе өчен көтелмәгән хәрефләр революциясенә юлыга. Бары күп уйлаганнан соң гына, ул бу өлкәдә дә эшкә күмелә:

латин хәрефләрен төрекчәгә җайлаштыру өстендә эшләгән тел комиссиясе үзенең функцияләрен тәмамлагач, аны Тел Академиясе итеп үзгәртү мөмкинлеге турында уйлый башлый.

«Төрек учаклары» җәмгыятенең 1930 елда узган Корылтаенда Садри Максуди тәкъдиме белән «Төрек учаклары»на бәйле тарих буенча комиссия төзелә. Киң таралган Төрек учакларында бу комиссия Тарих җәмгыяте исеме астында мөстәкыйль рәвештә яши башлый.

Шушы елларда Шебинкараһисар депутаты итеп сайланган һәм ара-тирә Ататөрек мәҗлесләренә чакырылып торган Садри Максуди,[10] бу хөрмәтле затлар арасында үзенә күрә бер киңәшче буларак танылa һәм, шуннан файдаланып, форсат чыккан саен, Тел Академиясе оештыру кирәклеге турындагы фикерен әйтеп килә. 1930 елда ул төрле газеталарда басылган һәм телне төрекләштерү мәсьәләсенә кагылган мәкаләләрен туплап «Төрек теле өчен» исемле китап чыгара. Садри Максудиның бу китабы турында сүз алып барганда Ататөрекнең китапка кереш рәвешендә язылган мәкаләсеннән тел проблемалары белән бәйләнгән, бу проблеманы тикшергәндә чишмә башы, байрак булырдай фикерләрен эченә алган мәшһүр җөмләне искә төшереп үтү мәгъкул булыр.[11]

Ататөрекнең Садри Максудины еш кына үз янына чакыруы, һәрчак илтифат күрсәтүе, югары уку йортының университет исеме алуына кадәр үк аны башка укытучыларның мөдәррис итеп каравы, аңа профессор дип эндәшүе, аңа исемнең Сорбоннада бирелүен белмәүчеләр арасында бик табигый рәвештә көнчелек уяткан һәм аңа каршы торучы группа тууына сәбәп булган.

1938 елны Ататөрек янында узган бер мәҗлестә дошманнарының бер төркеме, Садри Максудиның Истанбулда булуыннан файдаланып, «Дәүләтнең тел турындагы сәясәтенә каршы сүз алып барды» дип әләк ирештерәләр.[12] Садри Максудины хөрмәт иткән һәм бу уңайдан бик борчылган Ататөрек «Сезнең арада моңа җавап бирүче юкмы соң?» диюеннән соң, радио иртәнге җидедән көндезге икегә кадәр Садри Максудига каршы сүз алып бара. Бу вакыйга «Денизбанк вакыйгасы» дип телгә кереп кала.

Ике көннән соң әтием Садри Максудиның хәлен белергә килгән җөмһүрият башканлыгының өлкән адьютанты Җәләл бей Ататөрекнең бу уңайдан тирән борчылуын белдергән һәм аның бу хатага этәргән кешеләргә карата бик ачулы икәнлеген дә өстәгән.

Бәлки Садри Максудига карата эшләнгән хаксызлык уңаеннан борчылу нәтиҗәсе булгандыр, бәлки очраклы гынадыр, әмма шуннан соң инде бу кичке мәҗлесләргә җыйналу бетә. Асылда исә Бөек Ататөрекне алып китәчәк авыру да инде көчәйгән була.

Ататөреккә һичнинди үпкә сакламаган әтием, радиодан аның үлеме турында ишеткәч, кычкырып елап җибәргән һәм: «Инде төреклек өчен бер дәвер тәмамланды», дип белдергән һәм тарихның бу мизгеленнән соң үзенең хезмәт вазыйфасын Истамбул университетына күчерү чараларын эзли башлый.

Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында рус-герман сугышын зур дулкынлану һәм борчылулар белән күзәтеп барган галим аның нәтиҗәләрен күреп һәм Кырым татарларының Себергә сөрелүләрен белеп бик кайгыра.

1946-елны Демократлар партиясе төзелгәч, дәүләтнең киләчәге өчен яңа өметләр белән янып, ул үзендә яңа бер көч тоеп, иң күп укылган кичке газета «Соң сәгатьтә» битләрендә һәр атнаны демократия, күппартиялелек, гражданлык хокуклары кебек темаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен тирәннән кузгаткан мәкаләләрен бастыра башлый. 1950-елгы сайлауларда Әнкарадан милләт вәкиле итеп сайланган ординар профессор Садри Максудиның күпчелеге үзенең шәкертләре булган бер төркем милләт вәкилләре тарафыннан җөмһүрият башканлыгына (премьер-министр) тәкъдим ителгәнлеге мәгълүм була һәм кайбер газеталарда аның исеме Җәлал бей Баяра һәм Али Фуат Җәбәсол исемнәре белән бер рәттән басыла башлый.

Сайлаулар нәтиҗәсен белгән һәм бу нәтиҗәне дөрес аңлаган Садри Максуди, мәмләкәттәге иң мөһим урынга тәкъдимнәрдә үз исемен күреп, моның Анатоли төрекләренең үзенә карата бер мәгънәви бүләге дип саный.

Ауропа Советы төзелгәннән соң аның идарәсенең рәисе яки әгъзасы буларак Ауропа Советында яки парламентара бердәмлек җыелышларында өлкән миллиятче даимән үз тормышының бөек максатына, миллият тойгысына тугры булып кала. Шул ук вакыт Аурופада сәяси бердәмлек яки федерализм урнашса дәүләтләргә үзләренең милли мөстәкыйльлекләреннан өлешчә баш тартырга туры килүе мөмкинлеген дә ул һәр кемнән алдан күрә алган. Соңыннан французлар бу нәрсәне «Де Голль докторинасы» исеме белән үзләштерәләр һәм тарихка кертеп калдыралар.

1953-елдан соң, үзенең 70-еллыгын билгеләп үткән Садри Максуди, Мәҗлес, партия һәм хөкүмәт эчендәге сәяси уеннарны үзе өчен ялыктыргыч санап, 1954 елгы сайлауларга үзенең кандидатурасын куймый.

Сәламәтлеге какшау сәбәпле, куркуга төшеп, ул инде күптән уйланылган, әмма дәрес китаплары бастыру аркасында тукталып торган «Милләт тойгысының социологик әсаслары» дигән хезмәтен бик тиз арада язып та бетерә һәм бастырып та чыгара.

Ул, бу якты дөньядан китәр алдыннан «Истәлекләр» язарга да уйлаган иде, тик моның 11 битенә генә өлгерде.

«Миллият тойгысының социологик әсаслары» асылда аның васыятедер.[13] Ырыкчылыкка якын бер милли хисе булган Садри Максудиның бу әсәрендә, ул заманга хас үз-үзен тыеп калырга тырышканлыгы сизелә вә миллиятчелек дошманнарына каршы хис һәм әдәби юл белән түгел, ә бәлки фәнни корал белән көрәш алып барганлыгы күренә. Әсәр ике нәрсәне бәхәссез рәвештә исбат иткән:

1. Милли хиснең, миллиятчелекнең бер романтик тойгы, бер буш хыял, бер субъектив халәт түгеллеген, ә инсанлыкның органик корылышы эчендә хәйяти һәм социологик функциясе булган бер объектив гамәли мотив булуы;

2. Милли хис һәм милли аңның, милләтләрнең үсешендә беренчел роль уйнаганы кебек, инсанлыкның да прогресска хезмәт иткәнлеге.

Бүгенге буын эчендә бу хакыйкатьне аңлаган яшьләрнең саны ни кадәр күбрәк булса, бөтен тормышын миллият

тойгысына багышлаган бөек миллиятче Садри Максудиның рухы шөбһәсез бу нисбәттә бик шат булачак.

Моны өмет итәбез һәм шуны телибез.

**Искәрмәләр:**

[1] Ю.Акчура — «Тюрк юрду» журналын оештыручыларның берсе. Төркия җөмһүрияте төзелгәннән соң. Бөек Милләт мәҗлесе вәкиле, сәяси тарих буенча профессор һәм Ататөрекнең якын дусларыннан берсе.

[2] Әхмәт Фәрит-тәк — Элеккеге министр һәм кече Емәл Еснинең әтисе.

[3] Төркиядә Конституция дип саналган нәрсә, чынлыкта, 1900 еллардан Урта Ауропаның төрле илләрендә башланып киткән, бер-беренә бәйләнгән һәм ватандашларга тигез хокуклар яулау өчен көрәшне алып баручы революцион хәрәкәттер.

[4] Русия төркиләре патша хокүмәтенең шиген уятмас өчен мөселман исеме астында гына җыелу уена килгәннәр.

[5] Бөтен Русия матбугатында давыл куптарган бу нотык кадетлар партиясе съездында сөйләнелә.

[6] Сергей Зенковский, үзе панславянист булган хәлдә, 1967- елда чыккан хезмәтендә, Россиядәге пантюркизм мәсьәләсенә кагылып болай дип язды: «Монгол басып алулары вакытында татар исемен күтәреп йөрткән бер монгол кабиләсе үзенең исемен шунда яшәгән төрки кабиләләргә тага. Соңгырак Русия идарәчеләре, мәсьәләнең асылын эзләп тормыйча, башка төрки халыкларга да татар исемен тагалар». (Pan-Turkism and Islam in Russia, Harwar University Press).

[7] Садри Максуди үзе Россия төркияләре корылтае дигән исем тәкъдим итә.

[8] Әле элегрәк тә Мәскәүдә уздырылган корылтай алдыннан ук уңга-сулга таркалаулар күренә, шул рәвешчә Русиянең төрки регионнарына җибәрелгән йөзләрчә хатларда бердәмлек фикеренә буталыш кертүләр башта Төркестанда, аннан соң Башкортостанда да «сепаратизм» идеяләре таралуга китерәләр. Кызгалычка каршы, төркичелекне таркатуга юнәлдерелгән бу эшчәнлек һәм тырышлык ахыр чиктә, соңыннан властька килгән большевиклар очен җирлек әзерләде.

[9] Автономия 1917 елның 22-июленнән 1918 елның 25-апрелеңә кадәр, ягъни 10 айга якын яши.

[10] Үзенә закон нигезендә бирелгән, ә соңыннан ныгып калган Арсал фамилиясен ул яратып кулланмый, имзасын Садри Максуди дип

дәвам итә.

[11] Бу җөмлә, дөресрәге, җөмләләр түбәндәгечә яңгырый: «Милли хис белән тел арасындагы бәйләнеш бик көчледер. Телнең милли һәм бик бай булуы милли хиснең үсешенә нык тәэсир итәдер. Төрек теле иң бай телләрнең берсе, шуңа күрә, бу тел акыл белән эшкәртелергә тиешле. Илен, бәйсезлеген саклый белгән төрек милләте телен дә чит телләр басылышыннан саклый алыр».

[12] Бу вакыт Мәҗлестә Диңгезчелек банкысың төзелеше турындагы канун проекты тикшерелә һәм бу проектта «Денизбанк» исеме кулланыла. С.Максуди, сүз алып, Диңгез банкы төшенчәсен, төрек теле кагыйдәләренә тулырак туры килә торганын куллана. Бары шул гына...

[13] Әсәрнең икенче басмасын әзерләгәндә теленең бик иске булуын искә алып, хәзерге буын әйбәт укый алсын өчен җиңелләштерелде, искерәк сүзләр урынына хәзергеләре алынды. Бу өченче басмада исә тел ягыннан үзгәрешләр кертелмәде.

*Гадилә Айда*

# КЕРЕШ

Милләтләрнең яшәешендә миллиятчелекнең әһәмиятле роленә бәйле рәвештә миллиятнең асылын социологик күзлектән карап тикшергән әсәр безнең телдә дә, Аурупа телләрендә дә әлегә юк диярлек. Булган әсәрләр исә миллиятчелекнең асылын объектив рәвештә тикшерүдән бигрәк йә агрессив ырыкчылыгы аңкып торган шовинистик характердагы әсәрләр, яки миллият тойгысының милләтләр тарихындагы роль вә әһәмиятен инкяр итү белән бәйләнгән космополитик пропаганда чарасы.

Бу китап миллиятнең асылына кагылышлы мәсьәләләрне һәрьяклап тикшерү нәтиҗәсендә тупланган фикер вә карашларның сөземтәседер.

Без бу китапта миллият мәсьәләсе буенча, хокук тарихы һәм социология җирлегендә туган позитив гыйльми бәямәләрдән аерылмыйча, тулысынча объектив булырдай тикшеренү үткәрергә тырыштык.

Кешелек җәмгыятенең һәм милләтләрнең хәйятында мөһим һәм уңай социологик фактор булган миллият асылы тирәсендәге эзләнүләр вә уйланулар безне шовнинистик миллиятчелек белән агрессив ырыкчылыкның да, миллият асылының ролен инкяр иткән комополитизмның да ялгыш вә зарарлы агым икәнлегенә тәмам инандырды.

Еллар дәвамында миллияткә кагылышлы мәсьәләләр тирәсендә алып барылган эзләнү һәм тикшеренүләр нәтиҗәсендә тупланган фикер вә карашларыбызны бу әсәрдә ачык вә самими бер телдә ачып салуны үзебезнең тарихи һәм вөҗдани вазифабыз дип санадык.

# I. ЫРЫК МӘСЬӘЛӘСЕ

## 1. ЫРЫК: АНТРОПОЛОГИК МӘГЪНӘДӘ

Миллият (милли идея) мәсьәләсе белән бәйле булган проблемаларның берсе — ырык мәсьәләсе. Бу мәсьәлә — катлаулы һәм бәхәсле проблема. Миллиятчелекнең* асылы хакында дөрес фикер йөртү өчен ырык белән милләт арасындагы мөнәсәбәтне һәм аерманы ачык рәвештә аңлау мөһим шарт булып тора. Без бу китапта «ырык» сүзен Европа телләрендәге: «раса» мәгънәсәндә, милләт сүзен исә «Nationalite»[1] мәгънәсендә кулланырбыз.

Ырык — нәрсә ул? Хайваннар турында сүз барганда көнбатыш телләрендә «ырык» кәлимәсе билгеле бер хайванның кайбер органнары һәм тышкы кыяфәте күзлегеннән башка хайваннардан аерылып торуын белдерүче бер сүз. Хайваннар турында сүз йөрткәндә без башлыча төрекчә «ырык» сүзе урнына ешрак «төр» төшенчәсен кулланабыз. Мәсәлән, атларның күп төре: гарәп аты, инглиз аты һәм башкалар. Шулай ук этләрнең дә шактый төрләре бар: бурзай (ау эте), бульдог һәм башкалар.

Кешеләр арасында да, бурзай белән бульдог кебек бер-берсеннән аерылып торган ырыклар бармы? Антропологларның фикере буенча, бүген дөньяда кешеләр арасында хайван төрләре кебек бер-берсеннән нык аерылып торган саф ырыклар юк.[2]

Һичкайчан бер генә ырык та башка ырыклар белән нинди дә булса мөнәсәбәткә керми яшәми. Шуңа күрә бүген бөтен ырыклар эчендә дә бутән ырыкларга хас физик[3] хосусиятләре булган кешеләр очрый. Ак тәнле, сары чәчле, зәңгәр күзле булган милләтләр эчендә каратутлы кешеләр, каратутлылар төркеменә караган милләтләр эчендә зәңгәр күзле, сары чәчле кешеләр очрый.

---

* Хәзерге татар телендәге милләтче дигән төшенчә китапта «Миллиятче» дип бирелгән.

Бәгъзе ырыкларның катнаш булуына карамастан, һәрвакыт күпчелеге физик хосуиятләре ягыннан бер-берсеннән аерылып торган кеше төркемнәренең, ягъни ырыкларның булуы мәүжүд (реаль) күренештер.

Беренче антропологлар кешеләрне ырыкларга бүлунең нигезе итеп аларның тәннәре нинди төстә булуны алганнар. Бу күзлектән карап, аларның берәүләре кешеләрне өч, ә икенчеләре дүрт төркемгә бүлгәннәр.[4]

1. Ак ырык (аурупалылар)
2. Сары ырык (азиялеләр)
3. Кара ырык (африкалылар)
4. Кызыл ырык (җирле америкалылар, ягъни индееңләр).

Ләкин расаларны классификацияләу өчен нигез буларак кабул ителгән тән төсенең төпле һәм тулы бер бәяләмә яки дәлил (критерий) була алмаганлыгы аңлашыла; чөнки тәннәре кара булган Африка негрлары арасында, мәсәлән, физик хосусиятләре күзлегеннән караганда бер-берсеннән аерыла торган төркемнәр булган кебек ак тәнлелеәр арасында да бер-берсеннән бөтенләй аерылып торган төркемнәр бар. Бүген тән төсенең климат шартлары һәм нәселчәнлек нәтиҗәсе булуы да исбат ителгән.[5]

Немец антропологы Блюменбах (1752—1840), ырыкларны классификацияләү өчен тән төсе белән бергә күп кенә башка хосусиятләрне дә игътибарга алып, ырыкларны бишкә булгән:

1. Кавказ ырыгы,
2. Монгол ырыгы,
3. Хәбәш ырыгы (эфиоплар),
4. Америка ырыгы (индеецлар),
5. Малайя ырыгы.

Болай биш төркемгә классификацияләү дә антропологларны канәгатьләндерә алмый. Бүгенге антропологлпр ырыкларны классификацияләүдә иң мөһим бәяләмә итеп баш сөяге шәкелен (формасын) кабул итәләр һәм бу күзлектән карап, кешеләрне башта ике төркемгә бүләләр.

1. Баш сөяге озын булган кешеләр,
2. Баш сөге кыска булган кешеләр.

Бу классификациянең нигезе түбәндәгечә: әгәр баш сөягенең озынлыгы киңлегеннән зуррак булса, мондый баш сөягенә ия булган кешеләр озын башлылар (долихоцефаллар) дип аталалар. Баш сөягенең киңлеге озынлыгыннан зуррак булса, мондый баш сөгенә ия булган кешеләр кыска башлылар (брахицефаллар) дип аталалар.[6]

Баш сөягенең озынлыгын һәм киңлеген фәнни аңлату антропологик атамаларга таянган озын шәрехләүләр белән бәйле. Без баш сөягенең озынлыгын һәм киңлеген схематик рәвештә болай аңлата алабыз: Озынлык-маңгай сөягенең иң калку урыннан җилкә сөягенә кадәр булган ара. Баш сөягенең киңлеге исә — баш сөгенең бер чигә сөягеннән икенче чигә сөягенә хәтле булган ара.

Кеше төркемнәрен классификацияләү өчен баш сөягенең формасы бәяләмә буларак кабул ителгәннән соң, Ауропаның төньяк өлешендә яшәгән милләтләрдә кешеләрнең күпчелеге озын башсөякле булуын күрсәтүче дәлилләргә таянып, озын башсөяклелекне югары мәдәният тудырган Аурупа халыкларына хас махсус бер хосусият итеп аңлау, баш сөягенең шәкеле белән кешенең зирәклеге вә фикер сәләтлелеге арасына туры мөнәсәбәт булуын раслаучы бер фикри агым барлыкка килгән иде. Ләкин хәзер бу расламадан ваз кичелде, чөнки озын башсөякле Аурупа милләтләре өчен генә түгел, ә бәлки Африканың кара ырыкка караган халыкларының күпчелеге өчен дә хас хосусият икенлеге ачыкланды; баш сөягенең шәкеле белән кешенең сәләтлелеге һәм һәвәслекләре арасында бернинди дә мөнәсәбәт булмавы да аерым дәлилләр нигезендә исбат ителде. Мәсәлән, бөек немец философы Кант, бөек француз галиме Лаплас, бөек француз әдибе вә мөтәфәккире Вольтер кебек даһиларның кыска башсөякле булганы исбат ителде.

Бүген бәшәри (адәми) төркемнәрне билгеләгәндә, тән төсеннән вә баш сөягенең шәкеленнән тыш, чәчләрнең төсе, күзләрнең төсе вә шәкеле, буй-сыны, борынның басынкы яки очлы, йөзнең түгәрәк яки озын, иреннәрнең калын яки нечкә, яңак сөякләренең төз яки калку, буйның озын яки кыска булуы кебек хосусиятләр дә күз алдында тотыла. Бәшәри төркемн-

әрне бер-берсеннән аерып торган хосусиятләр «физик хосусиятләр» дип атала.

Франциянең узган гасыр ахырларында формалашкан мәшһүр антропологларыннан берсе булган Жан Деникер җир йөзендәге кавемнәрне, аларның физик хосусиятләрен искә алып, нигездә 29 төркемгә аера.[7] Ул бу 29 этник төркемнең берсе буларак төркиләрне күрсәтә. Шулай итеп, физик хосусиятләре белән башка инсани төркемнәрдән аерылып торган төрки ырыкның барлыгы антропология галимнәре тарафыннан билгеләнгән вә расланган булып чыга. Хәлбуки, Ратцель кебек кайбер галимнәр «Төрки» исемле этник төркемнең барлыгын инкяр да итәләр.[8]

Деникер кавемнәрне ырыкларга бүлү өчен бер кавем эчендәге кешеләрнең бәдәнендә иң еш очрый торган соматик хосусиятләрнең бөтенесен яки күпчелеген үзендә туплаган кешеләрне билгеле бер ырыкның типик үрнәге итеп кабул итә. Бер кавем эчендә бу типта булган кешеләр күпчелек булса, Деникер ул типның үзенчәлекләрен билгеле бер ырыкның хосусиятләре буларак кабул итә һәм вакыт узу белән башкалар белән буталмаган хәлдә саклануын фараз итеп, бу ырыкка шул типтагы кешеләрдән торган кавемнең исемен бирә.

Милләтләрнең әле тарихка кадәрге дәверләрендә үк бер-берсе белән аралашуы һәм катнашуы сәбәпле бүген һичбер милләтнең дә бөтен әгъзалары ул милләткә кергән ырыкның хосусиятләренә тулаем ия түгелләрдер. Монда без фәкать бу ырыкка хас үрнәк типлар, ә кавем эчендә исә иң еш очрый торган типлар күрәбез.

Без үзебез җир йөзендә билгеле физик хосусиятләре булган бер төрки ырыкның булганлыгына ышанабыз, ләкин шул ук вакытта без бүген төрки телдә сөйләшкән, күңелендә төркилек рухы саклаган бөтен шәхесләрнең дә төрки этник төркемнәргә хас соматик хосусиятләргә тулаем ия булуын раслый алмыйбыз, чөнки төрки ырык та башка кайбер ырыклар белән, әйтик кытайлар, монголлар, иранлылар, гарәпләр, фин-угырлар белән азмы-күпме дәрәҗәдә катнашкан булган. Бу төрки ырыкның үзе эчендә күп кенә төрки булмаган

кешеләрне эреткән булуы белән аңлатыла. Шуңа күрә бүген төрки кавемнәр эчендә төркиләргә хас соматик хосусиятләре булмаган кешеләрнең байтак булуы табигый күренештер.

Деникер төрки ырыкның соматик хосусиятләрен түбәндәгечә билгели:

1) Тәннәре ак,
2) Буй-сын уртачадан озынрак,
3) Баш сөяге — кыска,
4) Чәч — кара,
5) Күзләр — кара, ләкин монголлардагыча кысык түгел,
6) Борын — нормаль (басынкы түгел),
7) Күкрәк — урта,
8) Йөз — озынчарак (овал),
9) Яңак сөякләре — аз гына калкурак,
10) Иреннәр — калын,
11) Муен — кыска.[9]

Деникер карашынча: «Бәшәри төркемнәренең үзара катнашкан булуына карамастан, һәр этник төркем эчендә ырыкның соматик хосусиятләрен алган типлар беркайчан да бөтенләй юкка чыкмыйлар. Һәр кавемнең эчендә күп кенә кешеләр кавемнең аралашуыннан элегрәк барлыкка килгән ыркый хосусиятләрне даимән саклап киләләр».

## 2. ЫРЫК: ЭТНОЛОГИК МӘГЪНӘДӘ

Ырык төшенчәсенең антропологик мәгънәсендән тыш этнологик[10] мәгънәсе дә бар. Этнологик мәгънәдә ырык — озакка сузылган тарихи дәвердә бер зур дәүләт эчендә бергә яшәгән һәм шул нигездә уртак тел, гореф-гадәтләр вә инанулар җирлегендә берләшкән, үз дәүләте җимерелгәннән соң да үзара кардәшлек хисен саклый алган милләтләр тупланмасыдыр. Икенче төрле итеп әйткәндә: «Ырык — ул бер-берсенә якын телләрдә аралашкан вә уртак рухи омтылышлары булган милләтләрнең җыелмасы». Тарих вә социологиягә караган хезмәтләрдә һәм, аеруча, әдәби язмаларда ырык төшенчәсе шушы мәгънәдә кулланыла да. Мәсәлән, латин ырыгы, гарәп ырыгы, герман ырыгы, кельт ырыгы, төрки ырык. Бу

мәгънәдәге ырык сүзе антропологик мәгънәдәге ырык сүзеннән ачыграк та, җиңелрәк тә аңлашыла торган төшенчә.

Этнологик мәгънәдә латин ырыгы латин теленең төрле юнәлешләрдә үсеп киткән шивәләренең берсендә сөйләшкән, уртак рухи сыйфатларга вә һәвәслекләргә, уртак гореф-гадәтләргә ия булган милләтләрнең җыелмасыдыр. Чөнки французлар, итальяннар, испаннар һ.б. үз заманында озын-озак гасырлар дәвамында Рим дәүләте эчендә яшәгән, шуның нәтиҗәсендә римлашып, латинлашып киткән кавемнәр. Шулай ук этнологик мәгънәдә төрки ырык та кайчандыр вә күп мәртәбәләр бер дәүләт эчендә яшәгән, бүгенге төрки тел шивәләренең берсендә сөйләшкән, гореф-гадәтләре вә рухи омтышлары күзлегеннән бер-берсенә охшаган кавемнәрнең тупланмасыдыр.

Ырык сүзенең анропологик һәм этнологик мәгънәләре кайчакта бер-берсенә туры килә, ә кайчакта бер-берсеннән аерылып тора. Этнологик мәгънәдә латин ырыгыннан дип саналган теге яки бу милләтнең аерым әгъзалары антропологик яктан бер үк ырыктан булмавы да мөмкин. Без милләтне вә миллиятне социологик вә рухи күзлектән тикшерүне максат итеп куйган бу хезмәтебездә «ырык» төшенчәсен башлыча этнологик мәгънәдә кулланачакбыз.

## 3. ЫРЫКЛАРНЫҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

Милләт төшенчәсе һәр ике мәгънәдәге ырык төшенчәсеннән аерылырга тиеш. Антропологик мәгънәдәге ырык — зоологик бер төшенчәдер. Милләт исә социологик һәм рухи нигезләргә таянган төшенчә. Хәзерге көндә милләтләрне классификацияләүдә вә миллиятне билгеләүдә антропологик мәгънәдәге ырык төшенчәсе дәлилләүче билгеләмә буларак кулланыштан төшеп калды.

Икенче яктан милләт төшенчәсе этнологик мәгънәдәге ырык төшенчәсеннән дә аерылып тора. «Милләт» сүзен түбәндәгечә аңлатырга мөмкин: Ул — бер телдә сөйләшкән, бер үк милли холыкка, уртак тарихка, уртак милли гамәлләргә ия булган халык төркемедер. Этнологик мәгънәдәге ырык исә — милләт төшенчәсеннән шактый киңрәк мәгънәдәге төшенчә.

Мәсәлән, славян ырыгына күз салыйк. Бу ырык кысаларында тарихлары, телләре, яшәгән урыннары вә сәяси вәзгыятьләре күзлегеннән караганда бер-береннән шактый аерылып торган милләтләр бардыр: урыслар, поляклар, чехлар, серблар һ.б. Шулай ук герман ырыгы эчендә дә бер-берссеннән аерылып торган милләтләр бар: немецлар, шведлар, норвегиялеләр. Төрки ырык эчендә дә бер-берсеннән аерылып торган шивәләрдә сөйләшкән төркемнәр бар: Анатолия төркиләре, Әзәрбәйҗан төркиләре, Гарби Төркстан төркиләре (үзбәкләр, төркмәннәр, кыргызлар), Көнчыгыш Төркстан төркиләре (кара кыргызлар, уйгурлар), Кырым төркиләре, Казан төркиләре һ.б. Болар барысы да этнологик мәгънәдәге төрки ырыкка керәләр.

Этнологик яктан бер ырыкка караган милләтләр бер-берсеннән аерыла торган шивәләрдә сөйләшергә мөмкиннәр. Славян ырыгына караган милләтләр телендәге сүзләрнең тамыры славянча булган хәлдә, алар бүген бер-берсеннән тәмам аерылган вә ераклашкан телләрдә сөйләшәләр. Бүгенге урыс, мәсәлән, махсус өйрәнми торып, чех телен аңлый алмас. Герман ырыгына караган немец, махсус өйрәнмичә торып, швед телендә аңлаша алмас.

Бу күзлектән караганда фәкать төрки ырык кына искитмәле бер чыгарма булып тора. Кешелекнең төрки төркеменә караган кавемнәр гасырлардан бирле тарих вә география күзлегеннән караганда бер-берсеннән аерылган булсалар да, бүгенгә кадәр ана теле булган бер үк телдә сөйләшәләр. Чөнки шивәләр аерым бер тел тәшкил итәрлек дәрәҗәдә бер-берсеннән ераклашып бетмәгәннәр.[11] Бүген истанбуллы бер төрек азәрбайҗанны узып Көнбатыш Төркстанга (Төрекмәнстанга йә Үзбәкстанга), Көнбатыш Төркстаннан Көнчыгыш Төркстанга (Кытай Төркстанына) күченсә һич тә тәрҗемәчегә мохтаҗ булмыйча төрекчә сөйләшеп Кытайга тикле сәяхәт кыла ала.[12] Чөнки бу җирләрдә яшәгән кавемнәр төрки телнең аерым шивәләрендә сөйләшкән кавемнәр.

Бу күзлектән караганда, төркиләр турында бәхәс чыккан тәкъдирдә аларга карата ырык вә милләт төшенчәләре бер үк диеп әйтергә була.

Ырык мәсьәләсе бүгенгә кадәр катгый вә фәнни рәвештә җавап биреп булмый торган бик күп сораулар тудыра. Бу сорауларның берсе ырыкларның килеп чыгышы мәсьәләсенә кагыла. Бөтен кешелек төркемнәренең килеп чыгышы бер чыганактанмы? Ягъни, дөньядагы бөтен кешеләр, бөтен кавемнәр бер үк атаныңмы, әллә аерым-аерым аталарның торуннарымы (оныкларымы)?

Мәгълүм булганча, «Бердәнбер нәсел башлыгы» теориясенә «моногенизм», ә «Төрле нәсел башлыклары» теориясенә «полигенизм» исеме бирелә.

Бөек диннәрнең бөтенесе дә кешенең килеп чыгышын бер башлангычка кайтарып калдыралар. Яһүди, христиан һәм ислам дине галимнәренең фикеренчә, бөтен кешеләр дә Адәм Галәйһиссәлам нәселеннәндер, аның торуннарыдыр (оныкларыдыр).

Бер төркем галимнәр вә антропологлар исә полигенизм тарафдарлары булып торалар һәм кешеләрне төрле атадан таралган кавемнәр дип исәплиләр.[13] Шуның белән бергә, бүгенге көндә галимнәр арасында моногенизм фикере дә әкренләп куәтләнә бара.[14]

## 4. ӨСТЕН ЫРЫК ТЕОРИЯСЕ

Ырык белән бәйләнгән бәхәсле мәсьәләләрнең берсе - ырыкларның тигезлеге мәсьәләсе. Бу мәсьәләнең хәл ителеше түбәндәге сорауларга бирелгән җавапларга бәйле:

1. Ырыклар арасында физик һәм соматик үзенчәлекләре ягыннан аермалары булган кебек, зирәклек вә фикри сәләтлекләре ягыннан да аермалар бармы?

2. Ырыкларның зирәклек һәм фикри сәләтләре арасында аермалары булса, бу күзлектән караганда ырыкларның бәгъзеләре башкаларыннан өстен буламы?

3. Мәдәни дәрәҗә белән ырык арасында мөнәсәбәт бармы?

4. Мәдәният диелгән нәрсә даимән билгеле бер ырыкларның җимешеме, әллә ырык әсасының тышкы күренеше генәме?

5. Ырыкларның бөтенесенең дә билгеле шартлар булганда югары мәдәният дәрәҗәсенә күтәрелүе өчен куәте бармы, әллә мондый куәттән мәңге мәхрүм булган ырыклар да бармы?

Унтугызынчы гасырның икенче яртысында югарыдагы сорауларга Аурупа мөәллифләренең әсәрләрендә өстен ырыклар барлыгын.раслаучы түбәндәгечәрәк җаваплар бирелә иде:

1. Әйе, ырыклар арасында физик, соматик аермалар булганы кебек, фикри сәләтләр һәм зирәклек дәрәҗәсе күзлегеннән караганда да аерма бар.

2. Зирәклекләре һәм фикри сәләтләре ягыннан өстен ырыклар (мәсәлән, арий ырыгы) һәм түбән ырыклар бар (мәсәлән, негрлар).

3. Мәдәни дәрәҗә белән ырыклар арасында тыгыз мөнәсәбәт бар: мәдәният ырыкларның фикри сәләтләренә бәйле рәвештә үсә.

4. Кешелек тарихында мәдәният барлыкка китергән ырык арийлар, һинд-аурупалылар ырыгы. Арийлар өстен бер ырык.

5. Югары мәдәният дәрәҗәсенә ирешү һәм мәдәниятнең югары формаларын тудыру кодрәтенә ия булган ырыклар бар, бу кодрәттән мәхрүм калган ырыклар да бар.

Аурупада мондый раслауларның һәм фикерләрнең таралуында зур роль уйнаган хезмәт — француз мөәллифләреннән Комте де Гобиноның (1816—1882) «Бәшәри ырыкларның тигезсезлеге турында тикшеренүләр»[15] исемле хезмәте. Бик кыю, әмма фәнни булудан ерак торган раслаулар белән тулган әлеге әсәр Аурупаның соңгы гасырдагы сәяси тарихына тискәре тәэсир иткәнлегеннән, әсәрдән кыска гына булса да өземтә ясау һәм аны укучыларга тәкъдим итү файдалы булыр дип уйлыйм:

Гобино карашынча, ырыклар зирәклек вә фикер сәләтлеге ягыннан тигез түгелләр. Кара раса зирәклек ягыннан иң түбән ырыктыр. Сары ырыкка караган кавемнәрнең дә фикри сәләтлекләре чикләнгәндер. Зирәклек вә фикри сәләтлек ягыннан иң югары ырык аурупалыларга нисбәтле арий ырыгыдыр. Бу ырыкның җир йөзендә саф булып калуы бер идеал булып тора. Ләкин, кызганычка каршы, бу ырык тарихтан әүвәлге чорлардан бирле бүтән расалар белән катнашкан. Бүген бу ырыкның тулысынча саф, башка ырыклар белән катнашмаган бер төркеме дә юктыр. Аурупа кавемнәрендә өч ырыкның катнашуы нәтиҗәләре түбәндәгечә: борынгы греклар вә рим-

лылар семит ырыгы белән катнашканнар (семитлар үзләре дә кара ырык белән катнашканнар). Бүгенге латин ырыгына караган французларда, итальяннарда вә испаннарда римлылар каны ташып торса да, бу милләтләрнең тамырларында кара ырыкның да каны бардыр. Инглизләргә исә тарихтан әүвәлге бер чорда сары ырыкның каны катнашкан. Герман расасы ак ырыкның бүтәннәр белән иң аз катнашкан саф вәкиледер. Милләтләрнең мәдәни яктан үсүгә сәләте каннарындагы ак ырык канының микъдарына бәйләнгән. Күп тапкыр кабатланган катнашулар нәтиҗәсендә тамырларында арий каны азайган милләтләр мәдәният мәйданында уңышсызлыкка дучар булып калалар.[16] Милләтләрнең мәдәният һәм сәясәт мәйданындагы уңыш яки җиңелүләренең сәбәбен ырык үзенчәлекләреннән, каннарыннан эзләү лязим. Димәк ки, милләтләрнең тарихлары тамырларындагы канның җенесенә бәйледер».

Гобино, Аурупа милләтләренең ата-бабалары «Арья» исемен йөреткән бер ырыктан килеп чыккан, дип раслый, шуңа нисбәтән бу ырыкка караган милләтләргә «Арьен» («Арьялы») дигән исем бирә. Шунлыктан Гобиноның «өстен ырык» теориясенә дә «Арьянизм» дигән исем бирелгән.

Гобиноның «арийлар» диелгән өстен бер ырыкның барлыгына һәм бу ырыкның иң саф торуннары (оныклары) германнар булганга бәйле фикерләре Алманиядә (Германиядә) зур популярлык казанды, чөнки бу теория немецларның милли горурлыгын үсендерә торган бер мәсләк иде. Алманиядә Гобино фикерләрен пропагандалау максатында «Гобино җәмгыяте» дигән бер оешма да барлыкка килде. Бу җәмгыятьнең әгъзалары Гобиноның фикерләрен немец милләтенең аңына сеңдерү. буенча көчле пропаганда алып бардылар. Немец галимнәренең, шагыйрьләренең вә язучыларының күбесе Гобино фикерләрен кабул иттеләр.[17] Һәм немецлар дөньядагы иң өстен милләт дип раслаучы мәсләкне әдәбият аша пропагандалый башладылар. Асылда, Германиядә Гобино теориясен кабул итү өчен рухи җирлек тә әзер иде.

Гобинодан 30—35 ел элек Алманиянең бөек философларыннан булган Гегель дә (1770—1830) үзенең «Хокук фәлсәфәсе-

нең ачкычлары»[18] исемле әсәрендә шундыйрак фикерләрне алга сөргән иде: «Галәм рухы» төрле чорларда, төрле дәүләтләрдә сизелеп торган.[19] Соңгы вакытта галәм рухы үзен немец дәүләтендә сиздереп тора.[20] Гегельдән элек философ Фихте дә (1762—1814) «Немец милләтенә мөрәҗәгать» дигән нотыгында немец милләтенең өстен булганлыгын раслый торган фикерләр белдергән булган.

Алманиядә Гитлерны һәм нацистлар партиясен тудырган әһәмиятле гамилләрнең (факторларның) берсе шушы Гегель фикерләре белән башланган һәм Гобино хезмәте нәтиҗәсендә тагын да көчәеп киткән ырыкчылык агымыдыр. Немец милләтенең гадәттән тыш сыйфатларга ия булганына һәм башка милләтләр өстеннән хакимлек итәрдәй бер милләт икәнлегенә кагылышлы фикерләр немец зыялыларына көчле тәэсир ясаган.

«Минем көрәш» дигән әсәрендә Гитлер үзенең төп мәсләген, Гегель һәм Гобино фикерләрен гамәли сәясәттә билгеле бер максатта (немец милләтен Европада хаким милләт итәр өчен) файдаланудан гыйбарәт, дип бәян итә. «Марксизм» белән көрәштә өстенлек алыр өчен Гитлер ырыкчыл социализм хәрәкәтенә нигез салырга тели һәм шул максатта «өстен ырык» теориясенә таяна. Гитлерның «Минем көрәш»тәге фикерләренең Гегель һәм Гобино фикерләренә нигезләнгәнлеге түбәндәге гыйбарәдән ачык күренә: «Принцип буларак ырыкчылык идеясе дәүләт алдында торган төп максатны тормышка ашыруның бер чарасы буларак барлыкка килә. Бу максат үзе дә инсани ырыкларны саклап калуга юнәлдерелгән. Ырыкчылык идеясе ырыкларның бертигез булулары белән килешә алмый. Киресенчә, аларның кайберләренең башкалардан өстен булуын кабул итә. Бу идеягә инану ырыкчылык идеясе тарафдарларына, дөнья белән мәңге идарә итү дәгъвасын файдаланып, иң өстенләрнең вә иң көчлеләрнең җиңүче булуын җиңеләйтү һәм түбәннәрнең вә көчсезләрнең буйсынуына ирешү вазифасын йөкли. Димәк ки, бу инану табигатьнең аристократик принцибын хөрмәт итә. Үзләренең өстен булуларына инанучылар бу канунның һәр сүзенә ышаналар. Ырыкчылык идеясе кавемнәрне аларның сәләтләренә карап

аеру белән генә чикләнми, ул шәхесләрне дә аларның сәләтләренә карап аерымлый.[21]

«Өстен ырык» теориясенең әсасын тәшкил иткән һәм аның чыганагы булган һиндларның борынгы дини әсәрләренең санскрит теле белән Аурупа телләренең охшашлыгыннан алынган «арьянизм»га мөнәсәбәтле фаразларны кыскача түбәнгәгечә итеп чагылдыра һәм йомгаклый алабыз:

Бүгенге Аурупаның мәдәни милләтләреннән күбесенең телләре белән Һиндстанның борынгы дини теле булган санскрит арасында күзгә бәрелеп торган охшашлык санскрит теленең дә, Аурупа телләренең дә чыганагы бер ана теле булганын күрсәтә. Мондый телнең булуы бу телдә сөйләшкән бер кавемнең дә булганлыгын фаразларга таяныч булып тора. Бу кавемнең исеме дә «Арья» булса кирәк, чөнки борынгы чорларга караган санскрит телендәге әсәрләрдә һиндлылар «затлы, чиста, пакь, ару» төшенчәләрен «арья» сыйфаты белән чагылдырганнар.

Арьялыларның ватаны, «Арьяна Ваежа» дигән җир булган дип фаразлана, чөнки «Арья» расасына караган кавемнәрдән саналган иранлыларның борынгы дини китабы Авестаның беренче өлеше булган «Вендидад»ның беренче бүлегендә Ахура-мазда тарафыннан яратылган илләр арасында «Арьяна Ваежа» («Чишмәләр иле») дигән бер гыйбарә очрый. Гобиноның карашлары менә шуларга нигезләнгән дә. Өстен ырык мәсләге — һичбер фәнни нигезгә таянмаган теория. Кеше төркемнәре, рухи сәләтлелек, фикри вә мәдәни эволюция (үсеш) кодрәте күзлегеннән караганда, бөтенесе дә тигез. Бүген Аурупада «Өстен ырык» легендасын (уйдырмасын) фаш итүче шактый әсәрләр язылган инде.

Бу «арья» мифы турында француз галиме Ж. Финот үзенең «Уйдырмаларга таянган өстен раса идеясе»[22] исемле әсәрендә түбәндәгеләрне яза: «Озак вакытлар бәхәссез бер хакыйкать булып саналган арьянизм (арьячылык) доктринасына килгәндә, аның төп элементлары күзлегеннән карасаң, аның бер «фантом» (өрәк) гына икәнлеге бик ачык күренә. Әгәр аңа объектив карасаң, бу «фантом» юкка чыга!»[23]

Өрәкнең вакытлы гына күренеш булуы сәбәпле аңа таянып корылган фикер йөртүләрнең дә, табигый ки, һич әһәмияте юк. Соңгы вакытта уздырылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә галимнәр түбәндәге фикергә килгәннәр: Кайчандыр булган дип саналган «арья» ырыгы һичкайчан да ырык яки кавем буларак яшәмәгән, ул фәкать өстәл башында гомер уздырган галимнәрнең иҗади фаразлау җимеше булып кына яшәгән (К. Хартман). Билгеле бер җирдә бердәнбер булып кына да мондый бер кавемнең яшәгәне исбатланмаган.[24]

Арьянизм мәсьәләсендә америкалы авторлардан Х. Ханкинс «Мәдәният күзлегеннән ырык» дигән әсәрендә түбәндәгеләрне яза: «Арья, риваятьләргә караган һәр нәрсә кебек хыялда тудырылган, аның өлкә вә хосусиятләре дә бүгенге көнгә кадәр ачылмаган бер сер буларак яшәп килә».

1876 елда Хартман «арий» кавеме бары тик галимнәр тарафыннан уйлап чыгарылган бер кавем генә»,—дип язган иде. 1889 елда француз галиме Г. де Мортиллет Антропология җәмгыятендә укыган бер докладында түбәнгеләрне әйтә: «Арийлар» турында һич нәрсә билгеле булмаганга күрә, бу кавем булмаган дип фикер йөртүдән башка чара калмый».[25]

Унтугузынчы гасырның мәшһүр лингвистларыннан булган немец белгече Макс Мюллер да, «Арийлар» дигән ырыкнын булмавын раслап, түбәндәгеләрне белдерә: «Этнология галимнәренең арий ырыгы, арий каны, арий күзләре, арий чәчләре турында бәхәсләшүе телчеләрнең «долихоцефаллар сүзлеге» яки «брахицефаллар грамматикасы» турында бәхәс куптаруы кебегрәк мәгънәсез бер сафсата гына булып күренә».[26]

Тәҗрибәле һәм мөстәкыйль фикерләре белән аерылып торган вә танылган Франция социологларыннан Бордо университетының социология буенча профессоры Гастон Ричард да «өстен ырык» теориясенең фәнни нигездән мәхрүм булганлыгын көчле дәлилләргә таянып исбат итә һәм мондый фикер белдерә: «Әгәр өстен ырыкның максаты башкаларны үз хакимияте астына алу кодрәтенә ия булган ырыкка кайтып калса, мондый бер ырыкнын булуы бик шикле нәрсә. Тарих безгә шуны күрсәтә ки, дөньяның бер өлешендә хаким булган

ырыкның дөньяның икенче бер өлешендә һәлакәткә дучар булуы мөмкин. Урыслар, мәсәлән. Себердә вә Аурупаның төньяк-көнчыгышында шактый гына төрки вә финн кавемнәрен славян хакимияте астына алуга ирештеләр, ләкин Македониядә славяннар өстеннән төркиләр, Дунай бассейнында исә маҗарлар хакимлек итәләр».[27]

Фактларга таянган бердәнбер хакыйкать исә, бары тик борынгы һинд вә Иран телләре белән Аурупа милләтләреннән бәгъзеләренен телләре арасындагы охшашлыкка гына кайтып кала. Шуңа курә «арий» тәгъбире фәкать бу телләргә карый торган бер сыйфат буларак кына кулланыла ала,[28] ә бу исә булганлыгы исбатланмаган ырыкның сыйфаты булып санала алмый.

Өстен ырык» теориясенең фәнни вә тарихи күзлектән ялгыш булганы кебек, милләтләрнең бу теориягә таянган сәяси позицияләре дә, әлбәттә, ялгыш. Аерым кешегә карата да, милләтләргә карата да, үз яшәешләрен дәвам иттерү вә тормышларын камилләштерергә омтылу—ул аларның биологик асылларына нигезләнгән хаклары, һәр аерым кешенең вә һәр милләтнең «җир йөзендә мин дә бар һәм бар булып калачакмын» дип раславы аларның «барлыгының» иң табигый чагылышы. Ләкин бер милләт, үзенең башка милләтләрдән өстен булуын раслап: «Дөньяда хаким булырга лаек бердәнбер милләт мин, башка милләтләр миңа буйсынырга, минем хакимиятем астында яшәргә тиеш, минем тирәдә башка милләтләр яшәгән территорияләр минем яшәү мәйданым»,—дип әйткән көнне бөтен дөнья милләтләренең берләшеп аңа каршы чыгуы зарури вә табигый бер күренеш.

Көнбатыштагы бәгъзе авторлар Гобиноның германнарның иң югары ырык булуын раслый торган фикерләрен катгый рәвештә кире каккан хәлдә, үз милләтләренең Азия вә Африка милләтләреннән өстен булуын һичшиксез кабул итәләр.[29]

Күп кенә аурупалыларның күңелендә үзләренең мәдәният дәрәҗәсе күзлегеннән генә түгел, ә бәлки табигать, холык, зирәклек күзлегеннән дә башкалардан өстен булуларын раслаучы бер фикри агым булганлыкны да әйтү кирәктер. Бөтен

Аурупа әдәбияты көнбатышлы булмаган ырыкларга караган инсаннарның югары мәдәният дәрәҗәсенә күтәрелү сәләтеннән мәхрүм булуына ишарәләр, кинаяләр яки ап-ачык раслаулар белән тулы. Дөрес, билгеле бер чорларда билгеле ырыкка караган бер яки берничә милләтнең башка милләтләрдән вә дәүләтләрдән мәдәният, сәяси кодрәт күзлегеннән караганда өстенлеккә ирешүе тарихи бер чынбарлыктыр. Ләкин кешелек тарихын объектив рәвештә күздән кичергәндә, бу сәяси вә мәдәни өстенлекнең «ырык өстенлеге» нәтиҗәсе булмыйча, табигать, климат кебек гамилләрнең, тарихи, географик, икътисадый вә сәяси шартларның мәдәният үсешенә уңай тәэсир итүе нәтиҗәсе икәнлеге күзгә ташлана.

Бүгенге Аурупа милләтләренең мәдәният күзлегеннән караганда Азия вә Африка кавемнәренең күбесеннән өстен булуы хакыйкый бер күренештер. Ләкин бу һәрвакыт шулай булмаган бит.[30] Миладига кадәр берничә мең ел әүвәл Мисырда, Гыйракта югары мәдәниятләр барлыкка килгән вакытта, Көнбатыш Аурупадагы кавемнәр чын мәгънәсендә варвар иделәр. Аурупа кавемнәре арасында хәтта мәдәният үзәкләре дә урыннарын туктаусыз алмаштырып торганнар. Миладига кадәр римлылар бүгенге Аурупаның иң мәдәни милләтләреннән саналган британлылар белән германнарны мәдәниләшү куәтеннән мәхрүм кавемнәр дип исәплиләр иде. Шундый карашларның нәтиҗәсе буларак, император Каракалла тарафыннан Рим ватандашлыгы хокукы империя эчендәге шактый милләтләргә бирелгән хәлдә, британлылар вә германнар, варварлар дип саналып, бу хокуктан мәхрүм ителгәннәр иде.

Бүгенге французларның мәдәни яктан гарәпләргә караганда алга киткәннәрен инкарь итү мөмкин түгел. Хәлбуки, сигезенче гасырның соңгы яртысында һәм тугызынчы гасыр башларында, Габбаси хәлифәләрдән Һарун әр-Рәшит (765—809) вә аның уллары дәверендә, Габбасилар дәүләте мәдәниятенең Франк дәүләте мәдәниятенә караганда чагыштыргысыз дәрәҗәдә югары булганы, Багдадның дөньядагы иң югары мәдәният үзәге булганы да тарихи бер хакыйкатьтер. Һарун әр-Рәшитнең франклар короле Шарлманга бүләк итеп җибәргән

сәгатенең франк дәүләтендә ясаган тәэсирен бүген Африкадагы кечкенә бер кабилә башлыгына җибәрелүе фараз ителгән телевизор тәэсиредәй күз алдына китерергә мөмкин. Кануни Сөләйман дәверендә финляндиялеләр мәдәни яктан төрекләр белән чагыштырганда нык артта калган милләт иделәр. Бүген исә алар иң мәдәни милләтләр арасында лаеклы урын билиләр.

Мәдәни яктан түбән дәрәҗәдә булган теге яки бу милләтнең билгеле шартлар туганда мәдәни милләтләр хәленә күтәрелүе бик мөмкин, бу, тарихта күп тапкырлар күренгән хәл. Моннан йөз елдан элегрәк «сары ырыктан булганлыктан» югары мәдәнияткә ирешә алмаган дип саналган японлылар бүген техник фәннәр ягыннан Аурупа милләтләре дәрәҗәсенә чыктылар. Бүгенге японнар мәдәният, фән вә фәлсәфә өлкәсендә дә аурупалылар дәрәҗәсенә күтәрелә баралар.

Мәдәният үзәкләре күченеп торалар. Моннан сиксән еллар элек Төньяк Америка мәдәнияте Аурупаныкы белән чагыштырганда шактый түбәнрәк иде. Бүген исә Америка Кушма Штатлары һәр яктан Аурупа дәрәҗәсендә, кайсы бер яклардан югарырак та.

Мәдәниятне билгеле бер кыйтганың яки билгеле бер милләтнең генә мәңгелек монополиясе итеп санау фәнни караш була алмый. Югары мәдәнияттән мәхрүм булган милләтләрнең үсеш юлына баса алулары кебек үк югары мәдәниятле милләтләрнең дә мәдәни дәрәҗәләрен югалтулары мөмкин. Бүген мәдәниятне үзенең монополиясе дип санаучы Аурупа да моны үз кулында мәңге тота алмаячак. Заманыбызның фикер ияләреннән кайберләре хәзер үк инде Аурупа мәдәниятенең көчсезләнү дәверенә керүе турында бәхәсләшә башладылар. Мәсәлән, Освальд Шпенглерның Беренче бөтендөнья сугышыннан соң басылган «Көнбатышның түбәнгә йөз тотуы»[31] исемле әсәре нәкъ менә шушы темага багышланган. Шпенглер, төрле дәлилләр китереп, Көнбатыш мәдәниятенең көчсезләнә баруын исбатларга тырыша. Без Шпенглер фикере белән тулаем килешә алмыйбыз. Безнең фикеребезчә, Аурупаның мәдәни куәте бетмәгән һәм аның кешелек тарихында

уйнаячак роле дә саклана әле. Шул ук вакытта бүген Аурупаның мәдәни кризис кичергәне дә шөбһәсез. Бер үк вакытта бүген Азия вә Африка илләрендә мәдәниләшүгә таба җитди һәм нәтиҗәле омтылышлар ясала. Аурупа мәдәнияте диелгән мәдәният чынлыкта бөтен инсаниятнең уртак байлыгы. Бу мәдәниятнең үстерелүендә Азия һәм Африка милләтләренең дә роле вә өлеше бардыр. Көнбатыш мәдәнияте бүген чыннан да бөтен дөньяга тарала һәм Көнбатыш милләтләренең генә «монополиясе» булудан чыгып бара. Моның нәтиҗәсендә Көнбатыш милләтләренең башка милләтләр өстеннән сәяси вә икътисадый хакимлеге дә юкка чыгып, кешелек дөньясы сәяси яктан да, мәдәни яктан да тигез вә хөр милләтләрдән гыйбарәт булачак. Хаким милләт, мәхкүм милләт төшенчәләре әкренләп юкка чыгачак.

Аерым кешеләр арасында тигезлек инсаниятнең үсеше һәм тәрәккыяте өчен никадәр хәерле һәм уңай нәтиҗәләр тудырган булса, милләтләр арасындагы бертигезлелекнең җиңүе дә кешелек җәмгыяте тормышында шундый ук олы вә уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

Көнбатышның өстенлеге мифына таянган теорияләрнең фәнни, социологик кыйммәттән мәхрүм булганлыгы хакыйкый бер нәрсә.[32]

**Искәрмәләр:**

[1] Nation һәм Nationalite төшенчәләре күп кенә авторлар тарафыннан берсе урнына икенчесе куелып ялгыш кулланыла.

Әмма аларның берсен икенчесеннән аерырга кирәк. Бүгенге көндә сүз һәм атамаларны игътибар белән сайлап бары үз урынында гына кулланган авторларның фикеренчә бу ике сүзнең мәгънәләре бер-берсеннән аерылып тора. «Nation», мәсәлән, бер дәүләт эчендә яшәгән халык төшенчәсен белдерә. «Nationalite» исә теге яки бу дәүләтнең гражданы булуы-булмавына карамастан, бер үк телдә сөйләшкән, уртак тарихы вә мәдәнияты булган һәм мөстәкыйль бер сәяси көч буларак яшәү теләгендә торган кешеләр тупланмасы. Дәүләтара хокук күзлегеннән караганда, мәсәлән, Советлар берлеге дәүләтендә яшәгән халыклар бар Nation тәшкил итә. Шушы сыйфаты нигезендә ул бүген Берләшкән милләтләр оешмасы әгъза-

сы. Ләкин бу «сәяси» «Nation» эчендә тарих, тел, мәдәният, милли теләк һәм идеяллар күзлегеннән караганда бер-берсеннән аерылып торган бик күп милләтләр (этник төркемнәр), ягъни «Nationalite»ләр яши: 60 миллион торкиләр, 35 миллион украинлылар, 3 миллион грузиннар һ.б. «Nation» һәм «Nationalite» төшенчәләренең берсенең икенче урына куллануы ялгыш. Шул ук вакытта «Nationalite» төшенчәсенең бүгенге Европа телләрендә милләт мәгънәсеннән бөтенләй аермагы буларак башка бер мәгънәдә, билгеле бер дәүләтнең «ватандашлыгы» мәгънәсендә кулланылуын да искә төшерергә тиешбез. Мәсәлән Чехословакия ватандашлыгы (гражданлыгы) булган бер алманның (немецның) паспортында французча «Nationalite Tcheko-Slovaque» сүзе милләт төшенчәсен түгел, тик ватандашлык мәгънәсен белдерә. Чехословакия ватандашлыгы булган алман чехословак миләтеннән түгел, ул Чехословакия ватандашы (гражданы) гына.

[2] Paul Lopinard, L'homme dans la nature, p.345. Gustave Le Bon, les Lois psychologiques de l'Evolution des peuples, Ch.V, p.57.

[3] Мин монда, «физик» сыйфатның аурупа телләрендәге антропологиягә караган хезмәтәләрдә кулланылган «соматик» сүзе урнына кулланам.

[4] Мәсәлән, Linne (1707—1784).

[5] A.Quatrefages, l'Espitce Humaine. ch.IV, VI.

[6] Антропологлар озын баш белән кыска баш арасындагы аерманы математика ысулы белән чагылдырыр өчен озынлыкны 100 саны белән, киңлекне дә бу 100 санының вакланмасы рәвешендә күрсәтәләр. Баш сөягенең киңлеге озынлыгының дүрттән өч (0,75) булган яки киңлек саны дүрттән өчкә караганда азрак булган (0,77—0,67) баш сөякләре озын баш сөякләре (долихоцефал) дип саналалар. Баш сөясенең киңлеге озынлыгының дүрттән өченә караганда артыграк булганнар (0,80—0,87) кыска баш сөяклеләр (брахицфал) дип саналалар.

Баш сөягенең шәкелен чагалдырган 0,75 яки 0,80 кебек формулаларга баш билгесе (indice cephaliqua) яки күрсәткече дигән исем берелгән. Озын баш сөяклеләрдә бу күрсәткен 0,67 гә кадәр төшә ала, кыска баш сөяклеләрдә исә 0,87 гә кадәр күтәрелә ала.

[7] Jean Deniker, les Races et les peuples de la terre. Ch.VIII, Paris 1929.

[8] Ratzel, Vфlkerkunde, II. S.S.526 und Volg.

[9] Deniker, op.cit.editions de 1900 et 1926, p.459.

[10] Билгеле булганча, грек телендә «этнос» — кавем, халык дигән сүз. «Этнология» — кавемнәрне, аларның гореф-гадәтләре, җәһәтеннән карап өйрәнүче фән. «Этнография» дә кавемнәрне өйрәнүче фән.

«Этнологик», «этнографик» сүзләре бу фәннәргә бәйле сыйфатларны белдерә. Без биредә «этнология» төшенчәсен «этнография» сүзенең дә мәгънәсен эченә алган киң мәгънәдә, немецларда «халыклар турында мәгълүматлар» дип аталган фән мәгънәсендә кулланабыз.

[11] Бу җәһәттән төрки ырыкка караган якутларның һәм чувашларның теле генә чыгарма булып тора. Бу ике кавемнең сөйләү рәвеше башка төрки шивәләрдән мөстәкыйль бер тел исәпләнерлек дәрәҗәдә ераклашкан инде.

[12] Кытай дәүләте эчендә дә төркичә сөйләшкән, ана теле төрки тел булып саналган төркемнәрнең яшәве мәгълүм бер факт.

[13] Karl Vogt, Verlesungen uber der Manchen-Gissen 1863. Tome I. P.284, L.Gumplowicz, Precis de Sociologie, Liv.II, Ch.IV. Моннан башка Cuvier, Buffon кебек мәшһүр галимнәр дә «күп санлы тамырлар» фикерендә иделәр.

[14] J.Finot, Op.cit. Chap.V. Paris, 1921. Бу автор үз әсәренең монда күрсәтелгән бүлегендә тамырлар берлеген яклаучы күп дәлилләрне күрсәткән.

[15] Le comte de Gobineau. Essai sur l’inegalite des races. Cinquieme edition. Paris, 1884. Ике том.

[16] Комте де Гобиноның китабы аеруча Германияда кызыксыну уяткан.

[17] Мәсәлән, мәшһүр һәм бөек композитор Рихард Вагнер (1813—1883).

[18] Hegel, Grundlinien der Philosophie des Rechts. Leipzig, 1930.

[19] Гегельнең «Милләт рухы» әсәре турындагы фикерләрен дә алда махсус аңлатып бирербез.

[20] Гегельдән элек философ Фихте (1762—1814) дә «Немец милләтенә караган нотыгы белән немец милләтенең өстенлеге фикерен популярлаштырган». Rede an die Deutsche Nation (Немец милләтенә юнәлтелгән нотык). Фихте әсәрләре, Том VII.

[21] Hitler, Mein Kampf (Минем көрәшем), Том II, б.313., Х.Җаһит Ялчын тәрҗемәсе. Гитлерның доктринасы һәм сәясәтенә бирелгән исем «ырыкчылык» (расизм) дип атала. Зарарлы булган ырыкчылык, ул, башка милләтләрнең хөррият һәм бәйсезлегенә һөҗүм итүне яраган эш итеп санаучы, башка милләтләр өстеннән хакимлек итү һәвәсен тәрбиятләүче агрессив бер милләтчелек кенә. Бу, милләтчелекнең деградацияләнгән (рәвеше).

[22] J.Finot, Le prejuge des races. («Prejuge» төшенчәсен мин «уйдырма фикер» гыйбарәсе белән чагылдырам. «Алдан ук тискәре мөнәсәбәт» дигән гыйбарә, ул, сүзгә-сүз тәрҗемә генә һәм ул, ялгыш).

[23] J.Finot Le Prejuge des races, p.355—356.

[24] Vircoff.
[25] F.H.Hankins, La race dans la civilisation, Ch.II., P.41 Paris, 1935.
[26] J.Finot, op. cit. p.369.
[27] G.Richard, Sociologie generale, Partie III. Ch.III, 143
[28] «Арий» дип йөртелгән телләрнең таралуы да, ырыкның бердәмлеге аркасында түгел икәне, ә антропологик мәгънәдә ырык белән мөнәсәбәте булмаган факторларның бер җимеше икәне бүген исбат ителгән инде. (Frank H., Hankins, op.cit.Ch.II).
[29] Немецларның «өстен ырык» булуына караган Германиядагы хаким итүче фикергә параллель рәвештә без франциядә «кельтизм», Англиядә «англосаксонизм» дигән күренешләрне дә күрсәтә алабыз. Димәк, башка илләрдә дә үз милләтләрен «өстен ырык» итеп күргән фикри агымнар һәм даирәләр бар.
[30] Немец милләте әле бер варвар милләт булган чакта, безнең Урта Азиядәге ата-бабаларыбызның бик күп галимнәрне һәм Фараби кебек бөек философларны үстергәне мәгълүм бер факт. Моны фән тарихы белән шөгелләнгән белгечләр раслый (Садри Максуди, хокук фәлсәфәсе тарихы, 22, 44, 45).
[31] Oswald Spengler, Untergang des Abendlands. (Французчага «Declin de l'Occident» сүзләре белән тәрҗемә ителгән. Париж, 1931).
[32] Аурупа телләрендә ырык мәсьәләсенә караган әдәбият бик бай. Бу мәсьәләгә мөнәсәбәте булган укучыларага без шундый әсәрләр тәкъдим итә алабыз: Jean Deniker, Les races et les peuples de la terre. Paris, 1900 ve 1926. Paul Topinard, Elements d'Anthropologie generale, 1885, Paris. Paul Topinard, L'homme dans la nature. Paris, 1891. Eugene Pittard, Les races et histore. Paris, 1924. Frank H.Hankins, La race dans la civilisation. Paris, 1935. A.C.Haddon, Les races humaines et leur repartition geographique. Paris, 1930. Louis Figuier, Les races humaines et l'Homme primitif. Paris, 1876. Quatrefages et Hamy, l'Espece humaine. Paris, 1878. J.Finot, Le prejuge des races, Paris, 1921. Ratzel, Volkerkunde, Tome II. A.Ivanovski, La composition ethnique de la population de la Russie.

# II. МИЛЛӘТ ВӘ МИЛЛИЯТ

## 1. МИЛЛИЯТ ТОЙГЫСЫНЫҢ СОЦИОЛОГИК ВӘ БИОЛОГИК ӘСАСЛАРЫ

Социологларның һәм хокук тарихчыларының күпчелеге кешеләр бер атадан таралган (моногенизм) дигән фикердә торсалар да, берничә атаның балалары дигән теорияне (полигенизм) якласаларда, түбәндәге уртак фикерләрне хуплыйлар:

1. Мәдәният баскычында торган җәмгыятьнең нигезе ата җитәкчелегенә корылган, ата, ана вә балалардан торган гаиләдер. Дөрес, галимнәр ана җитәкчелегендә булган гаиләләр булганлыгын да раслыйлар. Мәсәлән Ж.Ж.Бахофен ата җитәкчелегендәге гаиләдән (патриархат) элек ана җитәкчелегендәге гаилә (матриархат) дәвере булган дигән фикерне үткәрә. Гаиләнең беренче үрнәге турында хокук тарихы һәм социология галимнәре арасында фикер берлеге юк. Шул ук вакытта, күпчелек галимнәрнең фикеренчә, мәдәният югарылыгында торган җәмгыятьләрдә ата җитәкчелегендә корылган патриархаль гаиләләргә өстенлек бирелә. Бу теориянең иң күренекле вәкиле — хокук тарихы өлкәсәендә үзенең төпле тикшеренүләре белән танылган инглиз галиме Сумнер Майнедер.[1] Бөек француз галимнәреннән булган Н.Д.Фустел де Голангизин да үзенең «Ла Ките Антик» дигән мәшһүр әсәрендә, мәдәният югарылыгында торган җәмгыятьнең башлангычы ата җитәкчелегендәге гаиләгә барып тоташа, дигән фикер үткәрә.[2]

Финляндия галиме Э.Вестемарк та, беренчел гаилә ата гаиләсе булган, дигән фикердә тора.[3]

2. Бер ата-ана балаларыннан таралган төркемнән заманнар үтү белән ыруг хасил була. Алмания галиме В.Вундтун фикеренчә, кешелек җәмгыятенең беренчел нәсел баскычында ыруг тора. Ыругтан алдагы заманда кешелек җәмгыяте юктыр. Ул вакытта фәкать хайваннарга хас көтү инстинктлары гына күзәтелә.[4]

Ыруг барлыкка килү кешеләрдә бергә яшәүгә ихтыяҗ вә моңа сәләт тә туу нәтиҗәседер. Һәр ыругның башлыгы, хокукый вә әхлакый кануннары, ягъни гомум тәртип кагыйдәләре бардыр. Әхлакның иң мөһим кагыйдәсе — ыругка бирелгәнлек вә тугрылыктыр.

Заманнар үтү белән ыруглар ишәяләр, тармакларга аерылып, яңа ыруглар туугa китерәләр. Соңыннан бу ыругларның да тармакларга аерылуы нәтиҗәсендә ыруглар үзләре дә күбәяләр һәм төрле җирләргә таралып, бер-берләреннән ераклашалар.

Кешеләр шулай ишәеп вә таралып, акрынлап яңа мохитка яраклашалар һәм төрле җирләргә урнашалар. Билгеле бер төбәктә ыругларның саны күбәйгәннән соң, алар арасында ыгы-зыгылар башлана. Куәтлерәк ыруглар көчсезрәк ыругларны кысрыклый башлыйлар: аларны моңа кадәр яшәгән бай вә уңдырышлы җирләреннән куалар, тору урыннарын басып алалар, ыруг җыйган байлыкларны талау өчен һөҗүмнәр оештыралар. Көчсез ыруглар исә яшәү вә дошман ыруг тарафыннан үзләренең юкка чыгарылуына юл куймау өчен бөтен көчләрен туплап көрәшергә мәҗбүр булалар. Чөнки фәрдләр (индивидлар), гомумән инсани төркемнәр, бөтен җанлы мәхлукатларга хас «яшәмәк — көрәш ул» мәсләгендәгечә, «хәят өчен көреш» канунына буйсынырга мәҗбүрләр. Бу канун яшәешнең нигезендә ятучы мөһим бер биологик[5] закондыр.

3. Шулай итеп, дошмани ыруглар һәм төркемнәр белән көрәш зарурияте бер-беренә якын төбәкләрдә яшәгән ыругларда берләшү ихтыяҗы тудырган. Моннан исә ыруг берләшмәләре, ягъни оймаклар[6] барлыкка килмештер.

4. Шушындый ук сәбәпләп аркасында, ягъни көрәштә көчле булу максатында, оймаклар да берләшергә мәҗбүр булалар, нәтиҗәдә кабиләләр барлыкка килә. Кабилә барлыкка килгәч, ыруглар вә оймаклар арасындагы гауга вә ызгышлар кабиләләр арасындагы көрәшкә әверелә.

5. Кабиләләр шушы сәбәпләр аркасында кабилә берлекләре (конфедерация) тәшкил итәргә мәҗбүр булганнар. Кабилә берләшмәләре барлыкка килү нәтиҗәсендә кабиләләр арасын-

дагы бәрелешләр азайган, әмма хәзер бу берләшмәләрнең үзләре арасында көреш башланган.

6. Билгеле бер урында яшәгән кабилә берләшмәләре арасындагы гауга вә бәрелешләр фәкать куәтле төркемнәрнең берсе бөтен кабиләләрне бер үзәк хакимият кул астында туплагач кына, ягъни бердәм дәүләт барлыккак килгәч кенә тынычланыр.[7] Кабиләләр арасында тынычлык вә тәртип тәэмин итү өчен куәтле бер хакимият, ягъни дәүләт барлыкка килү кешелек җәмгыяте тарихында күзәтелгән мөһим вә хәлиткәч закончалыктыр.[8] Дәүләт эчендә яшәгән кабиләләр дәвамлы рәвештә билгеле бер тәртипкә буйсынып тору нәтиҗәсендә милләт булып оешалар.[9]

Ырык, оймак, кабилә, кавем — барчасы да үзенә каршы төркемнәрдән саклану өчен кирәк иде. Бу берләшмәләр һәркайчан килешү юлы белән оешмадылар. Күп очракта берләшмәне барлыкка китерү өчен көчле бер төркем башка төркемнәргә каршы көч кулланырга мәҗбүр була. Фәкать яңа берләшмә оешудан соң күпмедер вакыт үткәч кенә берләшүгә каршы торучыларда, кешеләрнен рухындагы иҗтимагыйлык омтылышы басымы астында, үзара бәйлелек вә бердәмлек хисе җиңә. Чөнки фәрдләр үз яшәешләренең барлыкка килгән яңа төркемгә бәйләнгән булуын инстинктив рәвештә сизә башлыйлар.

Тарихтан элек яшәгән кавемнәр арасында кабатлана торган ыгы-зыгыларның сәбәпләре хәзерге заманда милләтләр арасындагы ызгышларны тудыручы сәбәпләрдән әллә ни аерылмый. Алар нигездә түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Кавемнең икътисади тормышын тәэмин итү зарурияте.

2. Бер кавемнең икенче кавемнәр тарафыннан юк ителүе яки әсир хәленә төшүе куркынычы.

Халык гаммәсе тәүге дәверләрдә җир йөзендәге кешеләр саны ягыннан бүгенге белән чагыштырганда телгә дә алмастан аз булган. Халык гаммәсе (кавемнәр һәм милләтләр) яши торган җирләрен җиңел һәм еш алмаштырганнар. Ниндидер сәбәп аркасында яшәгән урыннарын алыштырган тәкъдирдә, алар табигый шартлары яхшырак булган җирләргә күчәргә

тырышканнар. Әмма тормыш шартлары яхшырак җирләргә күчү һәрчакта да тыныч кына, бәрелешләрсез генә мөмкин булмый. Чөнки «А» кавмеме урнашырга теләгән урынга алардан элегрәк «В» кавеме килеп урнашкан була. Яки «А» лар белән «В» лар бу җиргә бер үк вакытта киләләр. Нәтиҗәдә үзара бәрелеш чыга. Бу бәрелеш вакытында ике төркемнең көчлерәге көчсезен йә юк итәр, йә бу урынны ташлап китәргә, качарга мәҗбүр итәр, яки дошман кавемнең исән калган өлешен әсир кылыр, яисә өлкәнең берәр төбәгендә урнашып калырга рөхсәт итәр.

Шулай итеп, кабиләләрнең, кавемнәрнең хәяте даими рәвештә сугышларда узган. Бары куәтләре бер чама булган кавемнәр генә янәшә тыныч мөнәсәбәтләрдә яши алганнар. Кеше төркемнәренең, кабилә вә милләтләрнең төрле кыйтгаларда вә төбәкләрдә урнашып калулары һәм утырган җирләрендә яшәү өчен рәхимсез сугышларда кырылулары ачы бер хакыйкаттер.[10]

Шулай да көндәш кавемнәр арасындагы каршылык вә дошманлык, шулар нәтиҗәсендә туучы ызгыш вә бәрелешләр белән бер ук вакытта ул кавемнәрне тәшкил иткән аерым фәрдләр арасында иҗтимагый зарурият басымы астында инсани теләктәшлек вә бәйлелек хисләре дә туадыр. Бу хисләрнең ныклыгы дошмани төркемнәр арасындагы капма -каршылыкларның вә нәфрәтнең ни дәрәҗәдә булуына бәйле. Бер-берсенә чит булган төркемнәр арасындагы мөнәсәбәт никадәр дошмани булса, бу төркемнәрне хасил итүче фәрдләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә шундый ук нисбәттә кешелекле булыр. Һәр төркемгә кергән фәрдләр үзләре бәйләнгән төркем, кабилә, кавем яки милләт рухына багланмышлар. Чөнки инсаннарның хәяттагы урыннары төркемнең хәятына бәйләнгән. Төркем эчендә урнашкан теләктәшлек мөнәсәбәтләре алардагы иҗтимагый максатлдарның вә һәвәслекләрнең ачылуына мөмкинлек, үзара ихтирамлылык, бер-беренә ышану вә иминлекне саклардай җайлы мохит тудыра.

Бүген социологлар вә хокук тарихы белгечләре исбат иткәнчә милләтләрнең яшәешендә вә тотрыклыгында иң мөһим, иң зарури шартларның берсе — аларны хасил итүче фәрдләрнең

үз милләтләренә нык бәйләнгән һәм тугрылыклы булуы.[11] Социологлар фәрдләр тупланмышы булган кабиләләр, кавемнәр, милләтләр сиземләвенә бәйле рәвештә туган тойгыны «төркем акылы», «төркем хисе»[12] яки «төркем зиһенияте» дип атыйлар.[13] Бер-беренә шушы хисләр белән бәйләнгән инсаннардан вә гаиләрдән торган төркемнәрнең кавем вә милләтләр булып җыйналуы, хәят мәйданында туган зарури вә табигый бер кагыйдә[14] буларак, кешеләрнең мәдәният юлына тартылуының бер шартыдыр.

Шулай итеп, миллият тойгысының чыганагы беренчел җәмгыятьләрдә дә, мәдәни җәмгыятьләрдә дә, аерым очракларда хәтта хайваннар дөньясында да күзәтелгән шушы гомуми социологик күренештер, ягъни инсаннарның үзләренә хас тойгылары нәтиҗәсендә туган бер-берләренә бәйлелек хиседер.

Димәк ки, миллият тойгысының чыганагы, бер яктан ин мөһим хәят кануны булган яшәү өчен көрәш вә көрәш өчен төркемнәргә туплану мәҗбурияте булса, икенче яктан, инсаннарның үзара иминлектә яшәүгә ихтыяҗы вә эчке сиземләведер.

Милләтләрнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүче, башка милләтләр арасында йотылып юкка чыгудан саклаучы да нәкъ менә шушы куәтле тойгыдыр, ягъни милли хистер. Нинди дә булса сәбәп аркасында шәхесләрне милләт итеп берләштерә торган шушы җепләрнең өзелүе милләтнең инкыйразына китерәдер. Күренә ки, милли хис хәят өчен көрәшнең. яшәү омтылышының вә ихтыярының асыл күренешедер.

**Фәрдләрнең яшәүгә омтылышына вә ихтыярына «үзүзеңне саклау инстинкты» диләр; милләтләрнең яшәүгә омтылышы вә ихтыяры исә «милли сиземләү», «миллият тойгысы», яки «миллиятчелек» дип атала**.

Аерым инсаннар өчен дә, иҗтимагый бергәлекләр өчен дә яшәү омтылышы вә ихтыяҗы биологик кануннарга барып тоташкан социологик бер күрнештер.

## 2. МИЛЛӘТЛӘРНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Милләтне нәрсәләр тәшкил итә? Теге яки бу кавем ничек итеп милләт дәрәҗәсенә ирешә? Бу бүлектә шушы мәсьәләләргә ачылык кертелер.

Беренче чиратта кавем белән милләт тәгъбирләре арасындагы аерманы күрсәтеп үтәргә кирәктер. Без бу очракта кавем тәгъбирен билгеле бер халык (этнос) мәгънәсендә, милләтне исә Аурупа телләрендәге «националите» тәгъбире рәвешендә кулланабыз.

Бу ике тәгъбир арасындагы мөнәсәбәт шундыйрак: тарихи вә сәяси үсеш нәтиҗәсендә формалашуы тәмамланган һәр кавем-милләттер. Кавемнәрнең милләт хәленә килүе һәркайда мөстәкыйль бер дәүләт эчендә башкарыла. Һәр милләт ниндидер бер кавемнең үсеп җитүе куренешедер. Биредә «кавем-милләт» исемен ыруг-кабиләләрнең бер дәүләттә берләшүе нәтиҗәсендә туган этник бердәмлек итеп күз алдына китерәбез.

Кавем-милләтләрдән башка тагы тарихи милләтләр бардыр. Болары бер кавем-милләт тарафыннан башка кавем-милләтләрнең йотылуы вә берләштерелүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән милләтләрдер. Мәсәлән, римләннәр. Бу милләт римлән булмаган һәм рим телендә сөйләшмәгән күп кенә кавем вә милләтләрне берләштерү нәтиҗәсендә хасил булды. Француз милләте галлиялеләр, римлеләр, франклар, бургундлар, весготлар вә норман кабиләләре аралашып кушылудан хасил булган милләттер. Тарихи милләтләр башлыча империя буларак оешкан дәүләтләрнең мирасы.

Бер кавем-милләтне тәшкил иткән төркемнәрнең тел, гореф-гадәтләр, рухи мөнәсәбәтләр нигезендә берләшүендә вә бер милләт хәленә килүендә иң мөһим нәрсә — ихтыяри омтылыштыр. Тарихи милләтләр формалашуында исә бер-берләреннән аерылып торган милләтләрнең хаким төркемгә буйсындырылуында иң мөһим нәрсә — көч кулланудыр; ягъни бу дәүләттәге хаким төркемнең башка төркемнәрне берләштерү өчен басым ясавы вә җәбер-золым куллануыдыр.

Без бу әсәрдә башлыча бер тамырдан чыккан хакыйкый милләтләр, ягъни кавем-милләтләр турында сүз алып барабыз.

**Кавем-миллəт билгеле бер җир-мəйданда (территориядə) яшəгəн, этнологик яктан бер тамырдан чыккан оймак вə кабилəлəрнең иң куəтлесе җитəкчелегендə дəүлəт булып берлəшүе нəтиҗəсендə туган һəм бер телдə сөйлəшүче, бер үк дингə инанучы, уртак гореф-гадəтлəре вə үзенə генə хас милли холкы булган, бер-беренə телəктəшлектə торучы охшаш кешелəр гаммəседер**.[15]

Кавем-миллəт оешуының төп гамиллəре (факторлары) вə шартлары, башкача əйткəндə, тəшəккел итүче гонсырлар (элементлар), түбəндəгелəрдəн гыйбарəт:

1. Миллəтне тəшкил иткəн инсаннарның бер дəүлəттə яшəве яки яшəмəве;
2. Халкы (нөфус);
3. Географик урыны (җир-мəйданы);
4. Бəйсезлеге;
5. Тел берлеге;
6. Гореф-гадəтлəр берлеге;
7. Гомуми дини иманулар;
8. Милли холык;
9. Миллəтнең күпчелегенең бер ырыктан, ягъни этник бер тамырдан булуы.

Инде бу гамиллəрне вə гонсырларны берəм-берəм карап үтик:

1. **Хокук вə дəүлəт тəэсире.** Миллəт оешу өчен кирəк булган шартларның берсе — берлəшүче гаммəнең озак заманнар буе бер үк дəүлəттə, бер ук тəэсир тоеп, бер ук хокукый кагыйдəлəргə буйсынып яшəве. Миллəтлəр оешуы һəркайда аерым дəүлəтлəрдə барадыр. Дəүлəт исə фəрдлəр мəҗбүри рəвештə буйсынырга тиешле хокукый тəртиплəр урнаштырылу дигəн сүз.

Кабилəчелек дəверендə иҗтимагый мөнəсəбəтлəр өлкəсендəге гореф-гадəтлəр билгеле бер тəртипкə куелыр. Бу дəвердə гореф-гадəтлəрдəн торган иҗтимагый тəртип кагыйдəлəрен үтəүдəн башка ниндидер көч вə тəшкилəт юктыр. Хокук исə дəүлəт көченə таяна. Димəк, дəүлəтчелек чорында хакимият хокукыйдыр.[16]

2. **Халык** (нөфүс). Билгеле бер кавемнең милләт булып оеша алуы өчен, аның составында җитәрлек санда халык гаммәсе булу шарт. Чөнки хәзерге замандагы кебек камил кораллар булмаган дәверләрдә һәр кавемнең үзе тереклек иткән җирләрне басып алырга омтылучы төркемнәргә каршы тора алуы өчен сугышта катнашырдай күп санлы булуы кирәк.

3. **Өлкә берлеге.** Ыруг берләшмәләреннән, кабиләләрдән мәйданга килгән халык гаммәсенең милләт булып оешуе өчен берләшүче кабиләләрнең бердәм утрак җирләре булуы шарт. Шуның өстенә берләшкән кабиләләрнең бер үк җирдә, бер үк ил-йортта озак вакытлар бергә яшәве кирәк. Ил-йорт берлеге милләт оешу шартларының берседер. Бөтен милләтләр үзләреннең барлыкка килүләрендә вә мөстәкыйль рәвештә яшәүләрендә мөһим роль уйнаган ил-йортка (ватанга) мөкатдәс бер нәрсә итеп карыйлар. Бөтен милләтләр ватанга бәйле милли бердәмлекне бер изге нәрсә буларак кабул итәләр. Ватаныңны сөю милли хиснең, миллиятчелекнең мөһим бер өлешедер. Үзеңнең ил-йортыңны олылау вә хөрмәтләү милли холык формалашуда да зур роль уйный.[17]

Табигатьләре белән күчмә булган төркиләр вә җиһангир милләтләр өчен өлкә берлеге икенчел дәрәҗәдәге әһәмияткә генә ия.

4. **Бәйсезлек.** Милләтнең оешуы өчен бер дәүләт эчендә укмашкан кавемнәрнең шул өлкәдә озак вакытлар бәйсез булып яшәүләре дә шарттыр. Чөнки кавемнәрнең тел, гореф-гадәтләр ягыннан берләшүе озак заманнарга сузылучы тарихи күренештер.

5. **Тел берлеге.** Милләт формалашу шартларыннан вә аның хәзерге замандагы нәтиҗәләреннән берсе — тел берлегедер. Бер кавемне тәшкил итүче кабиләләр бер телдә сөйләшә башлаганнары кебек милләт формалашу да шундый ук нәтиҗә белән тәмамланыр. Кешелек җәмгыятенең кабилә дәверендә ыруг вә оймакларның аралашу чаралары беренчелдер. Аларда әле сүзләр аз, грамматика башлангыч чорын гына кичерә, аның кагыйдәләре дә камил түгел әле. Шулай да бу

заманда һәр оймакның инде үз теле бар: төрле оймакларга кергән кешеләр бер-берләрен авыр аңлыйлар.

Римле авторлардан Плиний риваятенә караганда, антик чорда Анатолиянең көнчыгышында, Кавказның көньягындагы Колхида төбәгендә 300 дән артык тел булган. Төньяк Американың кызыл тәнле һурон кабиләләре арасында да уртак тел формалашмаган, һәр авылның үзенә генә хас аңлашу ысулы бар.

Уртак тел фәкать озак вакытлар бер дәүләттә яшәү, үзара бәйләнештә булу, аралашу, бер үк сүзләрне күп мәртәбәләр кабатлау нәтиҗәсендә генә мәйданга килер. Бу аралашулар вакытында, бер яктан, төрле шивәләр берләшер, кулланыштагы сүзләрнең күләме артыр; икенче яктан, кавемнең мәдәни үсеше белән бергә яңа сүзләр туар, шул ук вакытта телнең грамматик кагыйдәләре камилләшә барган шәкелгә килер. Шушы рәвешчә бөтен кавем өчен гомуми бер тел хасил булыр.[18]

Һәр милләтнең теле белән рухи халәте арасында ныклы бәйләнеш бардыр.[19] Чөнки аңлашуның нигезендә яткан тел берлеге милләт булуның иң мөһим өлешен тәшкил итәдер.[20]

Тарихтан күренгәнчә, кайда милләт оеша, шунда ук милли тел дә хасил була. Кайда да булса зур бер гаммәне эченә алган уртак тел барлыкка килсә, шунда билгеле бер милләт вә шушы милләткә бәйлелек тойгысы белән яшәгән кешеләр дә булыр.

**Һәр милли телгә бәйләнешле рух та бардыр.** Диннәренә бәрабәр милли телләр дә милләтләрнең дәрәҗәсен күтәрә, милли кыйммәтләрне арттыра. Милли телләрнең яшәве миллиятне яшәтүнең иң әһәмиятле алшарты булып тора.

6. **Гореф-гадәтләр берлеге.** Милләт вә миллиятне тәшкил иткән гамилләрнең тагы берсе — гореф-гадәтләр берлеге. Тел берлеге кебек үк гореф-гадәтләр берлеге дә озак вакытлар бер урында вә бер дәүләттә яшәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән төрле мөнәсәбәтләрдән туар. Милләт яшәеше дәвамында туган гомуми бәйрәмнәрнең, милли үзенчәлекләргә таянган мәрасимнәрнең милләт үсеше өчен бик куәтле берләштерүче роле бардыр.[21]

7. Дини инанулар. Милләтләрнең формалашуында дини инануларның да роле бик мөһимдер. Кешелек тарихында дине

булмаган бер милләттә күзәтелми. Шулай да милләтләр яшәешендә милли тел барлыкка килү белән дини ианулар хасил булу арасында шактый аерма да бар: милли тел - милли бер казаныштыр, һәм ул милләт белән бергә барлыкка килә.[22] Дини ианулар исә милли тугелләрдер. Алланың асылы, инсанның (кешенең) вә галәмнең барлыкка килуе, кешеләрнең җирдә башкарасы гамәлләре хакындагы ианууларның, ягъни диннәрнең бер милләттән икенчесенә бик җиңел күчә алганын күрәбез.

Милли дине, ягъни үз милләте эчендә генә зоһур булган (барлыкка килгән), бер пәйгамбәр тарафыннан гына таратылган дине булган милләтләр сирәктер. Мәгълүмдер ки, тотемизм дигән беренче дин Австралия белән Американың кайбер җирле кавемнәре арасында таралгандыр.[23] Ислам динең кабул иткәнгә кадәр күпчелек төрки кавемнәрнең иске дине булган шаманизм да шәркый Азиядәге шундый диннәрнең берсе иде.[24]

Әмма дин милли булса да, башка милләттән кабул ителгән булса да, — милләтнең билгеле бер күрсәткечедер. Француз милләтенең барлыкка килүендә католик дине, бүгенге төрек милләтенең барлыкка килүендә исламият мөһим бер фактор булдылар.

8. **Милли холык** (сәҗийә). Милләт формалашуының югарыда күрсәтелгән шартлары гамәлләштерелгәннән соң бөтен милләткә хас бер милли холык барлыкка килә. Милләтнең бөтен гаммәсе арасында таралган уртак рухи максат вә бу максатлардан туган гамәл вә төшенчәләр рәвешенә милли холык диләр.

9. **Ырык.** Һәр милләтнең формалашуында этнологик мәгънәдә кулланылган ырыкның да роле бардыр. Ырык билгеле бер нәсел үзлегенең чагылышыдыр.

Милләтләр дәүләттә күпчелекне тәшкил иткән ырыктан укмашалар. Әмма кайвакыт хәрби яктан көчле булган кечерәк кавемнең дә үзенә караганда күбрәк санлы кабиләне буйсындырып яңа бер милләтнең барлыкка килуенә нигез салуы мөмкин. Тора-бара бу аз санлы кавем яңа милләткә үзенең телен дә иңдерә. Мондый очракларда милләт үз хакимлеген

урнаштырган төркем ырыгыннан саналыр. Шул ук вакыт моның киресен күрсәткән мисаллар да очрыйлар.[25]

Милади белән VI гасыр башларында алман ырыгына караган франк кавеме үзе яулап алган Галлиядә (бүгенге Франция) бер дәүләт корды. Әмма җиңүче франклар үзләре корган дәүләттә алман телен хаким итеп куймадылар, ягъни аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрмәделәр.

Икенче мисал: милади белән VII гасырда (680 ел) көчле гаскәре булган һәм болгар исемен җөртүче бер төрки кавем Кара диңгезнең көнбатышында, Дунай өлгасы буенда, славян кабиләләре яшәгән җирдә дәүләт корды. Әмма дәүләт корылганнан соң бу өлкәдә тел итеп төркичә сөйләшкән болгар теле алынмады. Болгар төркиләре яңа милләткә үзләренең исемнәрен бирделәр, әмма үзләре төрки милләт буларак юкка чыктылар.

Бүген кельт ырыгы, герман ырыгы, славян ырыгы, төрек ырыгы исемнәре белән мәгълүм булган инсани кавемнәрнең һәрберсе борынгы бердәм дәүләтләрдә аерым-аерым милләт тәшкил иткән гаммәнең таркалган өлешләредер.

Бер милләтнең этнологик яктан үзенең бер ырыкка караганын аңлавы вә шушы кабул итүе, үз телендә аралашкан кавемнәрне башка дәүләтләрдә яшәгәндә дә үз ырыгыннан санавы «ырыклык» түгелдер. Бу бары чынбарлыкны тәсдыйклаучы нәтиҗә генәдер.

Һәр кеше дөньяда этнологик яктан нәсел үзенчәлекләрен чагылдырган ырыкларның булуын вә үзенең дә шуларның берсенә керүен тануга бәйле бер фәнни позициягә басарга мәҗбурдер. Сәләмәт акыл вә хокук хакимлек иткән дәүләттә бу гыйльми хакыйкатьне кабул иткәне өчен кемне дә булса гаепле санау, моның өчен кемне дә булса эзәрлекләү һичкемнең дә башына килмәс.

Кавемнең милләт дәрәҗәсенә ирешү шартларын вә гамәлләрен шушы рәвешчә тасвирлаганнан соң, искә алынган аңлатмалар нигезендә милләт төшенчәсен яңадан күз алдыннан үткәрик.

**Милләт — ерак үткәндә күп очракта тарихтан элгәре дәвердә үк бер урында дәүләт корган, шушы**

**дәүләттә озак вакытлар мөстәкыйль булып яшәгән, үзара аралашып, бердәм гореф-гадәтләргә тугрыклы булып, бер телдә сөйләшүче фәрдләрдән вә гаиләләрдән оешкан бәшәри гаммәдер**.[26]

Милләтләрнең формалашуына кагылышлы фикер вә карашларның күбесе хокук тарихына һәм социологиягә караган әсәрләрдә һәрьяклап яктыртылган. Теге яки бу милләтнең барлыкка килү шартлары да белгечләр тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән.

Белгечләрнең кайберләре милләт оешуының нигезе итеп дини өйрәтмәләрне,[27] кайберләре телне,[28] кайберләре географик урынны,[29] кайберләре ырыкны,[30] кайберләре икътисади шартларны күрсәтәләр. Әмма милләтләр хасил булуда әйтелгән бөтен гамәлләрне туплап яктырткан бер әсәр юктыр. Шунлыктан бу очракта бөтен гамәлләрне бергә туплап һәм һәркайсының үзенчәлекле ролен вә әһәмиятен аерым-аерым тикшереп чыгу зарури табылды. Чөнки бу гамәлләр бер-берсенә каршылыклы мөнәсәбәтләрдер. Бу каршылыклар түбәндәгеләрдер:

1. «Теге яки бу милләтнең барлыгы өчен дин берлеге һич тә зарури түгелдер. Мәсәлән, французлар бер милләттер, әмма аларның бер өлеше католиклар, ә бер өлеше протестантлар». Әмма бу каршылык француз милләтенең нигезендә ятмыйдыр. Чөнки протестантлык француз милләте оешканнан соң гына барлыкка килгән.

2. «Милләтнең оешуы өчен тел берлеге дә зарури түгелдер. Щвецария милләте, мәсәлән, өч аерым телдә сөйләшә». Бу каршылыкта да бер аңлашылмаучылык күренә. Швецария без әйткән мәгънәдәге милләт түглдер. Швецария хокук күзлегеннән караганда бер федератив дәүләткә берләшкән милләттер, ләкин этнологик күзлектән караганда бер милләт саналмас. Швецария дәүләтендә бер-берсеннән аерылып торгач өч милләт — французлар, итальяннар, алманнар бардыр.

3. «Милләтнең барлыгы өчен урын берлеге дә мәҗбүри тугелдер. Билгеле булганча, яһуд милләте гасырлар дәвамында милли туфрагы булмаса да, бөтен дөньяга таралган бер милләт буларак яши. Әмма яһуд милләте формалашкан мәгълүм бер

заманда аларның дәүләте дә, туфраклары да булган. Билгеле булганча Палестинада яшәгән яһуд дәүләтенең иң куренекле дәвере — пәйгамбәрләр тарихында искә алына торган Давыт һәм Сөләйман исемле хөкемдарлар дәвердер. Яһуди милләтенең дөньяның төрле тарафларына таралуы милләт буларак формалашуы тәмам булганнан соң гына күзәтелә. Димәк ки, яһуд милләте дә билгеле бер дәүләттә формалашкан булып чыга.

Югарыда күрсәтелгән сыйфатлар — кавемнәрнең милләт буларак оешу шартларыдыр. Формалашуы тәмамланган милләтнең миллиятте тотрыклыга әверелә һәм ул киләчәктә дә үзен милләт буларак саклый ала.

## 3. МИЛЛИ ХИСНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Билгеле бер төбәктә яшәгән инсани төркемнәрнең бер ук хакимият астында берләшүе, бер милләт булып оешуы уңай нәтиҗәләргә китерә. Өлкәдә урнашкан хокукый тәртипләр тәэсирендә икътисади тормышның үсүе, мәдәни тәрәккъыят мәмкинлекләре киңәю, милләтнең яшәүгә һәвәслеге, мөстәкыйль бер сәяси берлек буларак яшәүгә омтылышы, милли яшәешкә нинди дә булса куркыныч туганда аңа каршы тора алуга ышаныч арту, бөтен шәхесләр рухының чагылышы буларак бу милләткә караган фәрдләр тормышының биологик вә психологик динамизмының көчәюе, яшәугә һәм иҗатка сәләт вә омтылышларның үсә баруы — бу нәтиҗәләрнең иң мөһимнәреннәдер.

Милләт формалашуның психологик нәтиҗәләреннән берсе — фәрдләрдә милләткә бәйлелек хисенең, ягъни миллият тойгысының тууы, көчәюе вә милләт гаммәсенә таралуыдыр. Бу тойгы нәселчәнлек кануннары нигезендә туктаусыз куәтләнә барыр.[31]

Миллият тойгысының мәгънәсен түбәндәгечә аңлатырга мөмкиндер: **миллият тойгысы инсаннарның үз милләтенең үткәненә, киләчәгенә, теленә, мәдәниятенә, җир-мәйданына, ил-йортына кагылышлы карашларның тирәнәюе, нәселдән нәселгә кучуе белән бәйле рухи бер халәттер.** Бу рухи халәт милләтне тәшкил итүче бөтен гаммәне колачлаганлыктан, шәхси булудан бигрәк, «коллектив» бер тойгыдыр.

Миллият тойгысы нинди генә шәкелдә булмасын, башлыча ике юнәлештә күзәтелә:

1. Миллият тойгысы беренче чиратта теге яки бу милләткә караган кешеләрнең үзләренең милли тарихларына, милләтләренең үткәндәге уңышларына яки бәхетсезлекләренә изге бер нәрсә итеп караулары рәвешендә сиземләнә. Миллиятче инсан милләтенең тарихта шанлы булган дәверләрен, тәрәккыйлеккә илткән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алыр. Караңгылык чорлары, бәхетсезлекләре вә газап китергән заманнар исә аңарда кайгы хисе уятыр.

Милләт психологиясендә игътибарга лаек бер рухи күренеш күзгә ташлана. Теге яки бу милләт тарихта никадәр күбрәк кайгы вә газаплы дәверләр кичергән булса, башка милләтләрнең һөҗүменә, золым вә изүнә никадәр кубрәк дучар ителсә, аның уллары вә кызлары шул нисбәттә ук үз милләтләренә багланган булырлар, шул ук нисбәттә миллиятче булырлар. Милләтләрнең тарихта кичергән фәлакәтләре, өсләренә төшкән җәбер, золым вә хаксызлыклар, аларның үз бәйсезлекләре өчен алып барган көрешләре вә фидакярлекләре милли хисләрен тетрәтүче этәргеч булган. Болар барысы да милли хисләрне куәтләндергән вә тирәнәйткән бөек гамилләрдер. Поляклар вә яһудлар — моның ачык мисалы. Миллиятләре аркасында гасырлар буе җәбер вә бәхетсезлекләр кичерүләренә карамастан бу ике милләт — поляклар вә яһудләр — дөньяның иң миллиятче милләтләредер.

Милләтләрнең үз үткәннәренә багланганлыгы аларның милли мәдәниятләренә, телләренә, диннәренә, милли аңнарына, милләтнең олы затларына вә каһарманнарына хөрмәт рәвешендә дә чагыладыр. Җир йөзендәге барлык милләтләр кыю вә батыр затлар һәм бөек шәхсиятләр тудыралар. Милләтнең хәятендә, тәрәккыяте өчен көрәшләрдә фидакярлек күрсәткән, Ватанга гадәттән тыш хезмәтләре белән дан алган кешеләргә каһарман исеме бирелер. Мондый бөек шәхсиятләр милләтнең хәтерендә онытылмас эз калдыралар. Үз милләтен сөйгән халык шагыйрьләре бу каһарманнар истәлегенә мәдхияләр вә җырлар иҗат иткәннәр, алар хакында дастаннар язганнар.

Шул рәвешчә каһарман үз милләтенең хәтер хәзинәсендә куренекле урын алган.

Каһарманнар тудыру милләтләрнең бик кыйммәтле сыйфатыдыр, аларның яшәүчәнлек кодрәтен күрсәтүче мөһим гамилдер. Без, төркиләр, тарихта бихисап каһарманнар тудырган бер милләттер. 3000 еллык тарихыбызда үзебезне инсани мәйданда мөстәкыйль итеп саклый алуыбыз да бөек каһарманнар тудырырга сәләтле булуыбыз аркасындадыр.

Борынгы грекларның Тесей[32] вә Милтидасы,[33] римлеләрнең Муций Сцеволасы, Юлий Бруты[34] вә Фабий Максимусы,[35] алманнарның Зигфриды,[36] французларын Роланд[37] вә Жанна д'Арклары,[38] без төркиләрнең Огуз Хан, Бумин хан, Билге хан, Культегин, Тогрул, Алпаслан, Эртогруд, Осман вә Ататөрек кебек тарихи шәхесләре милли каһарманлыкның ачык үрнәкләредер.

Милли каһарман исеменә лаек булу өчен милләтенә югарыда телгә алынган каһарманлыклар күрсәтү генә шарт түгелдер. Каһарманлыкның мәгънәви кыйммәте башкарылган гамәл нәтиҗәсенә күрә генә түгел, бәлки милләтнең мәнфәгате өчен курсәтелгән фидакярлекнең дәрәҗәсе белән дә билгеләнәдер. Милләтнең бәйсезлегенә куркыныч янаганда яки бүтән бер очракта милләт мәнфәгатен саклау өчен үзен фида кылган яки фида кылырга әзер булган шәхес милли каһарман буладыр.

2. Миллият тойгысы фәкать милләт язмышына бәйле рәвештә генә тумыйдыр. Миллият хисенең чагылышы кайбер очракларда киләчәккә юнәлгән милли гамәл, максат вә фикер булуы да мөмкин. Миллият хиснең киләчәккә юнәлеше мөстәкыйль булган милләтләргә киләчәктә дә мөстәкыйль булып калу теләгеннән, бәйсезлекләрен югалткан милләтләрдә исә бәйсезлекләрен яңадан тогызуга тырышудан гыйбарәттер. Бу ике хәлдәге милләт тә үз ватанында, үз телендә сөйләшеп, үз гореф-гадәтләренә таянып яшәү, мәдәнилек вә мәгърифәтлелек җәһәтеннән тәрәкъкый итү теләген вә карашын даими үстерү өмидендә булырлар.

Миллият тойгысының ачылуы, үсүе вә камиллекә ирешүе шушы киләчәккә омтылган теләк вә максат аркасындадыр.

## 4. МИЛЛИ ХОЛЫК

Милли холык дип без милләтнең бөтен вәкилләренә хас булган гомуми һәм уртак үзенчәлек вә һәвәслекләрне атыйбыз. Шул ук вакыт нинди дә булса бер милләтнең бөтен вәкилләренең дә аны һәр кайчан һәм һәр хосуста бер үк рәвештә аңлавы һәм бер үк рәвештә эш итүе дә күзәтелмидер. Чөнки теге яки бу җәмгыятьтәге бар кешенең дә рухи хәләте бер үк дәрәҗәдә ачыла алмаганы кебек, алар бер үк нәселчәнлеккә һәм кабилияткә (сәләткә) дә ия була алмыйдыр. Шулай булмаса кешелек җәмгыятенең тәрәкъкыяты һәм үсеше мөмкин булмас, милләтләр эчендә Сократлар, Фарабилар, Лейбницлар, Ньютоннар, Галилейлар, Эдисоннар, Пастерлар тумас иде.[39]

Шул ук вакыт тәҗрибә һәм күзәтүләр шуны раслыйдыр ки, ныклы тамырлары булган милләтләрдә аерым кешеләр арасында акыл дәрәҗәсе ягыннан аермалыклар булса да, бер үк вакытта бөтен милләт әгъзаларына хас булган гомуми рухи чалымнар да бар. Менә шуларны без милли холык, милли характер дип атыйбыз. Милли холык билгеле бер хәлдә бер үк рәвештә хәрәкәт итү, билгеле бер очракны бер үк рәвештә сиземләү, билгеле бер нәрсәне бер үк рәвештә бәяләүдә үзенең чагылышын таба.

Мәсәлән, бүгенге инглиз милләтен тәшкил итүче индивидларның һәммәсенең аларны бер-береннән нык кына аера торган бик күп шәхси үзенчәлекләре, хосусиятләре вә рухи һәвәслекләре бар. Шулай ук һәр французның башка французлардан аеры бер рухи дөньясы (теләк, омтылыш, сөю вә нәфрәт тойгылары) бардыр. Шул ук вакыт һәрбер инглиз үзенең эш итү рәвеше, гадәтләре, теге яки бу нәрсәгә реакциясенең төсмерләре белән француздан аерылып торадыр. Инглизләр арасында таралган хосусият вә үзенчәлекләр инглизләрнең милли холкын тәшкил итә. Французлар да күзәтелгән хосусиятләр исә французларның милли холкын тәшкил итәдер (милли характердыр).[40]

Кайсы телдә сөйләшкәннәрен белмәгән тәкъдирдә дә корабльдә очраган ике юлчының берсенең инглиз, ә икенчесенең француз

булганлыгын аларның күз карашларыннан, йөрешләреннән, хәрәкәтләренең тәртибеннән үк аңлау артык авыр түгел.

Гадәти тышкы күренешләрендә генә түгел, милләтләрнең зиһениятләрендә, вакыйгаларга карата реакцияләрендә дә аермалык бардыр.

Милли холыкның барлыкка килүендә милләт яши торган җәгъръәфи киңлектәге табигый вә икътисади шартларның, мадди тормышны тәэмин итү юллары һәм ысулларының, милләт эчендә хакимлек итүче инануларның, күрше милләтләр белән булган дуслык яки дошманлык мөнәсәбәтләренең, тарихи вакыйгалар белән бер рәттән бөек шәхсиятьләр калдырган эзләрнең, кыскача гына итеп әйткәндә милләтнең формалашуында һәм яшәешендә тәэсире булган бөтен әмәлләрнең роле бардыр.

Бер формалашкан милли холык вә аның нәтиҗәсе булган милли карашлар миллият тойгысы вә теле кебек үк, милләткә хас җайлашу һәм нәселчәнлек тәэсире астында буыннан буынга күчеп куәтләнер һәм миллиятнең аерылгысыз үзенчәлегенә әйләнер.

Барлыкка килгән вә буыннан буынга күчә барган милли холык, сәяси тетрәнүләр аркасында милләт үзенең мөстәкыйльлеген җуйса һәм таркаланулар кичерсә дә, ә индивидлар һәм төркемнәр бер-береннән аерылып галәми киңлекләрдә таркалып яшәргә мәҗбүр булса да, үзенең яшәешен саклый ала һәм юкка чыкмый.[41]

Бүгенге яһуди милләтне тәшкил итүче инсаннар дөньяның төрле тарафларына таралганнар һәм төрле телләрдә сөйләшәләр. Шуңа карамастан бу милләт хәзергә кадәр милли холкын, милли һәвәслекләрен вә инануларын югалтмаган. Гасырлар дәвамында яһүдиләр милли характерларын саклап калдылар, вә үзләренең яһүдилекләре белән горурланалар.

Шуның белән бергә һәрбер шәй кебек милли холык та тирәлеккә яраклашу кануннарына буйсынганлыктан, бүгенге Аурупада яшәгән мәдәниятлы һәм укымышлы яһудинең дөньяга карашы Сөләйман пәйгамбәр заманындагы яһудиның карашларыннан әлбәттә аерылып тора.[42]

Ырык белән бәйләнгән, соң дәрәҗәдә миллиятче булган, гореф-гадәтләрен вә үзара бердәмлек идеясен саклый алган, үткәннәре белән тыгыз бәйләнгән яһудиләр бүген дөньяның дүрт тарафына да таралып яшәүләренә карамастан милли холыкларын саклап кала алдылар.

## 5. МИЛЛИ ХОЛЫКНЫҢ ФОРМАЛАШУЫНДА БӨЕК ШӘХСИЯТЛӘРНЕҢ ВӘ ТӘКЪЛИТ КАНУНЫНЫҢ РОЛЕ

Барча мөһим тарихи вакыйгалар һәм иҗтимагый үзгәрешләрнең тууында ихтияри куәт, акыл, зиһен, белем ягыннан югары торган шәхсиятьләрнең роле шөбһәсез булганлыгы кебек үк милли холыкның барлыкка килүендә вә милли мәдәниятнең ачылып китүендә дә бөек шәхсиятләрнең мөһим бер сәбәп икәнлеге инкар ителмәстәй бер хакыйкатьтер.

Дәүләт эчендә яшәгән индивидлар арасында гомуми бер рухи халәт һәм милли холыкның барлыкка килүе, милләтнең мәдәният мәйданындагы казанышлары, миллият тойгысының тирәнәя баруы — болар барысы да бөек шагыйрь, әдиб, галим вә мөтәфәккирләр эшчәнлеге нәтиҗәседер.[43]

Инглиз милләтенең бүгенге милли холкы формалашуында Чосер, Шекспир, Милтон вә Байрон кебек язучы вә шагыйрьләрнең тәэсире булганы кебек Бэкон, Гоббс, Локк, Бентам, Стуарт Милл кебек мөтәфәккирләрнең дә тәэсире булуы хакыйкый нәрсәдер.

Шулай ук бүгенге французларның милли холкы вә психологиясе мәйднга килүендә Ронсард, Корнелл, Расин, Декарт, Монтескье, Кондорсе, Вольтер кебек әдиб вә мөтәфәккирләренең тәэсире шөбһәсездер.[44] Мәсәлән, без бүгенге француз интеллигентларының гомумән каһарманлык, инсанлык, хөррият вә гаделлекне яраткан йөрәкләренең бер почмагында булган һәм аек акылга нигезләнгән скептицизм тенденциясе, ягъни шөбһәчелек вә шикләнеп карау күренеше, Монтескье, Вольтер кебек әдипләрнең әсәреннән килгән дип, уйлыйбыз.

Инглиз мөтәфәккирләреннән Томас Корлил «Les heros et le Culte des heros»[45] исемле әсәрендә бөек шәхсиятләргә «каһарман» исеме бирә вә аларның ролен бик нигезле итеп яктырта.

Соңгы заманнарда алман мөтәфәккирләреннән Курт Брейциг та бик җентекле тикшерүләргә таянган «Vom Weschitlichen Werden» исемле[46] әсәрендә бөек шәхсиятләрнең ролен төпле мисаллар белән яктырта. Шул ук вакыт бу мөтәфәккирләрнең һәр икесе бәшәрият тарихындагы иң мәшһүр шәхесләр турында сүз алып баралар. Безнең фикеребезчә тарихта үз урыны булган шәхесләр бары исемнәре тарихка кереп калган мәшһүр инсаннарга гына кайтып калмый. Инде югарыда әйтеп үткәнебезчә, болардан башка һәр милләтнең хәятендә билгеле бер очракта, билгеле бер рәвештә уңай роль уйнаган, әмма исемнәре тарихка керми калган «каһарманнар» да бардыр. Милли характерның формалашуында һәм ачылышында боларның да роле бик мөһимдер.

Карлил вә Брейциг кебек мөтәфәккирләр шәхесләрнең тарихтагы ролен иң мөһим нәрсә буларак кабул итсәләр, социалистлар вә коммунистлар исә тарихи үзгәрешләрне фәкать халык массаларының куәтенә бәйләп аңлатырга тырышалар.

Шушы карашларын инде әйтелгән ике юнәлеш вәкилләренең һәр кайсы үз позициясеннән торып бер яклы гына аңлаталар. Без исә хакыйкатән икенченең уртасында торып фикер йөртәбез. Милли холыкның мәйданга чыгуында милләтне тәшкил иткән массалларның да, вә бу массаларны тәшкил иткән индивидларның табигый истидатларның һәм нәселдән килгән кабилиятләрнең ролен дә инкар итмибез. Шул ук вакыт милли массаның истидаты белән бәйләнгән кодрәт вә кабилиятләрнең мадди вә рухи эзләрен ачу белән бергә, милләтнең хаят вә ачылып килүенә беренче дәрәҗәдә юнәлеш бирүче, шөбһәсез, бөек шәхсиятләр икәнлегендә онытмыйбыз.[47]

Шуны да әйтеп үтәргә кирәктер ки, милли холыкның формалашуында һәм үсешендә шагыйрьләрнең вә әдәбиятчыларның роле бигрәк тә зурдыр.

Бөек шәхсиятләр тәэсирендә формалашкан милли холыкның бөтен милләттә таралу механизмы исә мәгълүм социологик кануннарга бәйләнгән. Еш кына уйланылганча милли характерның гомумиләшмәсе һәр вакытта да ниндидер басым нәтиҗәсе түгелдер.[48]

Бер үк вакыт дәүләт эчендә озын-озак заманнар дәвамында яшәгән аерым индивид вә төркемнәр арасында берук сүзнең, берук инануларның, бер үк гореф-гадәтләрнең, бер ук рухи омтылышларның таралуы билгеле бер социологик канунга нигезләнәдер. Бу тәкълит (үткәнгә карап эш итү) кануны булыр.

Кешелек җәмгыятенең яшәешендә иҗат вә тәкълитнең мөһим роль уйнаганлыгын фәнни рәвештә Франциянең бөек социологларыннан булган Габриель Тардье ачып салды. Бу галим үзенең «Тәкълият кануннары»[49] исемле әсәрендә бу канунның мәгънәсен түбәндәгечә аңлата: «Барлык иҗтимагый үзгәрешләр зур яки зур булмаган ниндидер фикерләр белән башлана. Бу фикерләрнең тууы башта бер кемнең дә дикъкатен җәлеп итми, һич кемгә дә исем вә шөһрәт китермәве мөмкин дә. Мин бу яңа фикерләрне иҗат вә ачышлар дип атыйм. Бу ике сүз белән без моңа кадәр ясалган иҗад җимеше булган теге яки бу нәрсәгә яңа элементлар өстәлүен яки бу нәрсәнең алга таба үсешен күз алдында тотабыз. Дөньяга яңа ихтыяҗлар һәм аларны канәгатьләндерү чаралары китергән бу яңа фикер вә омтылышлар тирәлеккә таралу һәм гомумиләшү сыйфатына ия һәм алар даими рәвештә җәелә торалар. Бу җәелү шулай ук инсанның табигатендә яткан һәм аның үзенчәлеген хасил иткән тәкълиткә бирелгәнлек нәтиҗәсе буларак барлыкка килә».[50]

Бу канун бөтен иҗтимагый күренешләрдә дә үзен сиздереп торган закончалыктыр. Тәкълит тормышта инде булып узган теге яки бу хәлнең, әйтелгән фикернең, үзен сиздергән хиснең тәэсирендә ясалган бер хәрәкәтнең рәвешен һәм эшләнгән эшнең яки иҗат ителгән бер нәрсәнең башкалар тарафыннан үзләштерелүедер; бу ул хәлнең, ул фикернең, ул хиснең, ул хәрәкәтнең ысул һәм юлның кабатлануыдыр. Бу тәкълит күренеше тәкълит ителүченең теләгеннән башка барлыкка килә ала, яисә тәкълиткә ияргенең теләге белән туган хәл төсен ала һәм, ниһаять, нәрсәне дә булса башкаларга күчерү өчен кулланылган чаралар нәтиҗәсе буларак күзәтелә. Теге яки бу нәрсәнең тәкълит юлы белән таралуын тәэмин итү

чараларыннан иң мөһиме үгет-нәсихәт вә өйрәтүдер. Үгет вә өйрәтү чаралары да бик күптер: китаплар, газеталар, конференцияләр, әңгәмәләр, рәсемнәр һәм башка шундыйлар. Беренчел җәмгыятьләрдә тәкълит чынлыкта бары тик күзәтү юлы белән барлыкка килә. Шул ук вакыт беренчел җәмгыятьләрдә дә, мәдәни җәмгыятьләрдә дә индивидлар арасындагы һәр төрле бәйләнәлешләр бер тарафлы булсалар да, каршылыклы булсалар да тәкълитнең чыганагы һәм башлангычы булып торалар. Иҗтимагый тормышта тәкълитнең вә үгет-нәсихәтнең роле бик зур. Пропаганда дип атала торган эш системалы һәм аңлы рәвештә алып барыла торган инандыру чаралыннан башка бер ни дә түәлдер.[51]

Оешып килә торган милләт эчендә милли холыкның таралуы, гомумиләшүе шулай тәкълит кануны нигезендә бара. Тәкълит җәмгыятьнең күпчелеген тәшкил иткән түбәнге катламында да, мәдәниятле сыйныфларда да башлыча үзләрен тотышлары һәм эш-гамәлләре рәвешендә күзгә чалына. Шулай да тарихи шартлар һәм гамәлләр нәтиҗәсендә югары культура дәрәҗәсендә яшәгән төркем үзеннән түбән культуралы, әмма хәрби яктан куәтле бер төркемнең лисанын, гореф-гадәтләрен кабул итәр. Моның киресе, табигый булганы исә, шулай да күбрәк күзәтелә.[52]

## 6. МИЛЛӘТ ВӘ МИЛЛИЯТ ХАКЫНДА КИҢ ТАРАЛГАН ФИКЕР ҺӘМ ТЕОРИЯЛӘР

А. **Метофизик теория**: Бу теориянең иң мәшһүр вәкиле алман философларыннан Гегельдер. Гегель карашынча «миллият» серле бер рухтыр. Ягъни һәр милләтнең үзенә хас бер рухы бардыр.[53] Бу рух башка милләтләрнең рухларыннан үзгәдер. Милли рухлар үзләренең үсеш дәрәҗәләре һәм башка җәһәтләре ягыннан бер-берсеннән аерылып торалар. Хәтта аерым милли рухлар арасында каршылыклар да күзәтелә. Ә кайберләре арасында исә, киресенчә, бер-беренә якынлык, уйгунлык, үзара ярашканлык күзгә ташлана. Милли рухлар арасындагы килешмәүчелек милләтләр арасында дошманлык, нәфрәт, бәрелешләр тудыра. Милли рухлар арасындагы ох-

шашлык, якынлык, үзара ярашканлык исә мәхәббәт, дуслык вә үзара симпатия уята. Милли рухларның асылында бер «җиһан рухы» (Weltgeist)[54] бар. Җиһан рухы бөтен милли рухларга хакимдер. Нигездә исә милли рухлар җиһан рухының аерым милләтләрдә чагылышыннан һәм ачылышыннан гыйбарәтләр. Җиһан рухының чагылыш мәйданы исә җиһан тарихыдыр.

Милләтләрнең күтәрелүе һәм түбәнгә тәгәрәве, уңышлары һәм югалтулары, җиңү һәм егылулары барысы да җиһан рухының ихтыяры нәтиҗәсе. Милләтләрнең тарихта теге яки бу рольне уйнавы, теге яки бу юнәлештә хәрәкәт итүгә омтылышы да шулай ук җиһан рухының чагылышы булып тора.

Тарих сәхнәсе алдында милләтләр бер туктаусыз урынна-рын алыштырып торалар. Һәр дәвердә җиһан рухы теге яки бу милләттә үзен куәтле һәм какшамастай көч рәвешендә ачып сала. Бу милләт шул дәвердә башка милләтләрнең җитәкчесе һәм мөршиде, ә мәдәният мәйданында юл күрсәтүче булып калкып чыга. Ул дәвернең мәдәни милләтләре җиһан рухы ачылышының иң күренекле вәкиле булган бу милләтнең рухи өстенлекләреннән илһам алалар. Шушы рухи өстенлек нәтиҗәсендә бу сайланылган милләт һәр яктан да хаким милләт урынын алып тора. Бу хакимият нигезледер. Башка милләтләр җиһан рухын чагылдырган милләт белән чагыштыр-ганда хак һәм хокук ягыннан мәхрүмнәрдер.

Гегель карашынча җиһан рухы бәшәрият тарихында башта кабатлана-кабатлана Шәрекъ императорлыкларында, аннан соң юнаннарда, тагы да соңрак Рим дәүләтендә үзенең чагылышын тапты.

«Бүген (ягъни Гегель заманында: 1770—1830) җиһан рухы алман дәүләтендә үзен күрсәтә»,[55] дип язды Гегель.

Күренүенчә Гегельнең теориясе өстен ырк теориясенең бары бер кадәр башкачарак яңгырышы гына булып тора.

Метафизикада «Өстен ырк» теориясен алга куйган Гегель-нең милли рух хакындагы фикерләре кайбер башка милләтләр арасында да таралды. Руссиядә славян ыркының. бигрәктә русларның кешелек белән идарә итү өчен Аллаһ тарафыннан

сайланган һәм аерып алынган бер ырк булганлыгын исбат итәргә тырышкан мөхәррирләр зоһур булдылар. Боларның иң мәшһурләре Аксаков вә Хомяковтыр.

Бу язучыларның һәм аларга иярүчеләрнең фикерләре славянофиллык (славянчылык) исеме белән мәгълүм.[56] Бүгенгеагрессив коммунизм кабул итми кала алмаган нәрсәнең берсе һич шөбһәсез шушы славянчылыктыр. Гитлер ни кадәр Гегель эзеннән барган булса, Ленин һәм аның рус милләтеннән булган иярченнәре дә уйлапмы яки уйлапта тормычамы шул ук дәрәҗәдә славянчылык идеясенең тарафдарлары булып калдылар.

В. **Социалистик теория**: Социалистик әдәбиятта миллиятнең әсасы хакында бер-береннән аерылып торган ике агым бар: боларның берсе миллиятне бары тик икътисади шартларның һәм капитализмның җимеше дип аңлаган милләтләр дә капитализм кебек ук юкка чыгуга хөкем ителгән бер күренеш дип таныган агым; икенчесе исә милләтләрнең барлыкка килуен бер тарихи чынбарлык дип кабул иткән һәм яшәеше табигый саналган бу барлыкны, исәпкә алуның зарурлыгын алга сөргән агым.

«Космополитизм» бүлегендә без беренче агым вәкилләре, рухландыручылары Маркс белән Энгельс булган коммунистлар турында махсус рәвештә тукталырбыз. Ә хәзергә бары шуны искертеп үтәбез: Маркс һәм Энгельс карашынча капиталистик тәртипләр бетерелгәннән соң пролетариат хакимияте дәверендә милләтләр дә юкка чыгачаклар. Коммунистик җәмгыять сыйныфларсыз булачагы кебек, ул заманда милләтләр дә булмаячак.[57]

Бүгенге рус коммунистлары да һәм принцип, һәм реаль сәясәт ягыннан рус милләтеннән башка милләтләрнең мөстәкыйль яшәве һәм милләт буларак үсүе тарафдарлары түгелләр.[58]

Социалистлар арасында икенче агымны тәшкил итүчеләр буларак беренче чиратта Австриянең социалист фикерләүчеләре тора. Боларның иң мәшһура Отто Бауэр. Бу мөтәфәккирнең «Миллият мәсьәләсе һәм социал-демократия» исемле әсәре заманында дөнья социалистлары арасында зур кызыксыну һәм шөһрәт казанды. Бу әсәрдәге әсаси фикерләрнең сөземтәсе түбәндәгечә яңгырый:

«Милләт исеме бирелгән инсани төркемнәр бер яктан кешеләрнең табигать белән көрәше шартларының, икенче яктан байлык җитештерү белән бәйләнгән хезмәт мәйданындагы төрле үзгәрешләрнең табигый нәтиҗәседер. Бу куз-лектән караганда милләтләрне мәйданга тарих тудыра.

Милләтләр мәдәният һәм мәгърифәт өлкәсендәге үсешләре нәтиҗәсендә милләт кысаларында культураларының яңа үсеше өчен тагы да киңрәк мөмкинлек алалар. Шушы рәвешчә башка милләтләр тарафыннан йотылу, юкка чыгу куркынычы тагы да азайган бер хәлгә киләләр.

Җәмгыятьнең демократлашуы вә социаллашуы да миллият әсасын тирәнәйтә һәм куәтләндерә.[59] Миллият тойгысы бөек бер чынбарлыктыр, социалистик җәмгыятьтә дә шулай ук миллият тойгысының юкка чыгу ихтималы фараз ителми. Бер милләттән икенчесенә күчкән теләсә нинди фикер, оешма яки принцип боларны алган милләтнең милли тойгыларына, милли аңнарына, милли хосусиятләренә уйланылмыйча кабул ителми. Милли культуралардагы гомуми әсаслар күзлегеннән караганда бер-беренә якынлашуы миллиятнең, милли хосусиятләрнең җимерелүен күрсәтми. Бүгенге дәвер милләтләрнең мәдәният һәм культура мәйданында бер-береннән иң күп файда күрүләре чоры. Шуңа карамастан теге яки бу милләтнең башка милләтләрдән аерып торган факторлар белән бәйләнгән үз аңнары вә милли тойгылары һич заман бүгенге кадәр куәтле, ачык һәм нык булганы да юк».[60]

Алманиянең беренче дөнья сугышы алдыннан яшәгән мәшһүр социалист мөтәфәккирләреннән булган К.Каутский милләтләрнең икътисади әмәлләр җирлегендә туган күренеш икәнлек турындагы фикерне кабул итүе турында сөйләгәннән соң, түбәндәге карашны алга сөрә:

«Бүгенге милли юнәлешләрнең нигезе заманабыздагы бәшәриятның үсеш тенденциясеннән аерылгысыз. Тарихтагы бөтен милли юнәлешләр дә хаклыдыр. Милләтләрнең үсешенә ясалма рәвештә комачауларга тырышу гомумән бәшәриатның үсешен тоткарларга тырышлык күренешедер».[61]

Социалист мөтәфәккир һәм язучылар арасында миллият тойгысын табигый бер күренеш итеп хисаплап, милләтләрнең

барлыгын кабул итү зарурәтен алга сөргән агым Австрия һәм Германия өчен генә хас түгел. Франциянең беренче дөнья сугышы алдындагы мәшһүр социалист мөтәфәкире Жорес та милләтләрне тану кирәклеген кабул итә иде. Жорес «Яңа армия» исемле әсәрендә болай дип язды:

«Ватан нигезенең ныклыгын бары икътисади төшенчәләргә генә таянныып аңлатып булмый. Бу нигезнең ныклыгы шулай ук милек һәм чикләр өчен көрәш кысаларына гына да сыйдырыла алмый. Миллият төшенчәсе үз эченә табигый тирәнлекне дә, мәгънәви биеклекне дә ала. Хәзергә кадәр җир йөзендәге шартлар бөтен бәшәриятның бер бөтен җәмгыять рәвешендә формалашуына киртә булып килделәр. Җир йөзе кешеләрнең санына караганда шактый зуррак һәм киңрәк. Шуңа күрә бәшәрият таралыш канунына буйсынып яшәде.

Нәтиҗәдә бәшәрият бер-береннән аерылган төркемнәр рәвешендә яшәп килде. Милләтләрнең, ягъни бер-береннән аерылып торган группаларның оешуы, алга таба үсешне тәэмин итү һәм тагы да зуррак группалар оешуның алшарты булып килде.

Бу милли группаларның һәр берендәге бердәм тормыш бер гомуми аң тууына китерә. Бу гомуми аң бөтен кешеләрне дә берләштерә һәм шуның нәтиҗәсендә аң үзе дә куәтләнә».[62]

Жоресның 1905 елны Штуттгардта җыйналган социалистлар конгрессында сөйләгән түбәндәге сүзләре дә бик мәгънәледер:

Жорес анда «милләтләр бәшәри даһилыкның, бәшәри үсешнең хәзинәләредер, рухи байлыкларны үз эченә алган бер вазадыр. Бу культура хәзинәләрен җимерү пролетариат өчен чит булган бер хәрәкәттер», диде.[63]

Соңгы елларда социалистик әдәбиятта хакимлек иткән фикер милләтләрнең юкка чыгуын алга сөрми, киресенчә аларның үсеш юлында булуларын, якын бер киләчәктә бәйсезлектән мәхрум ителгән милләтләрнең дә күпчелегенең бәйсезлеккә, һич булмаса киң милли мөхтәрияткә ирешуен яклый торган фикердер.

C. **Психологиягә кагылышлы теория**: Бу теорияне иң элек алга сөрә башлаучы француз белгечләреннән һәм мөтәфәкирләреннән Эрнест Ренан (1823—1892) булды. Ренан карашынча

миллият ниндидер бер рухи принциптан гыйбарәт.[64] Бу рухи принцип башлыча ике элементтан тора. Аларның берсе үткәнгә, ә икенчесе киләчәккә караган. Беренче элемент үткәннән калган, нәселчәнлек нигезендә тапшырылып килгән хатирәләрдер. Икенчесе исә бер милләткә кергән кешеләрнең бергәләп яшәвен дәвам иттерүгә, үткәннән күчкән милли хатирәләрне һәм рухи мирасны яшәтүгә теләк һәм омтылыштыр. Милләтләр юктан бар булмыйлар. Милләт озын-озак һәм авыр көрәш, коллектив фидакарьлек һәм каршылыклы үзара тәэсирләрнең нәтиҗәседер.

Миллиятнең ныклыгы милләтнең каһарманлыгы белән тарихта ачыла. Моның иң ачык гәүдәләнеше аталарга хөрмәт, чөнки милләтне тудыручылар да аталардыр. Миллият бер милләткә кергән кешеләрнең бер яктан тарихта гомуми горурлыкка лаек булган бөек эшләр башкаруы нәтиҗәсендә туган хатирәләренә һәм милләт эчендә барлыкка килгән рухи байлыкка бәйләнгән, ә икенче яктан бүген һәм киләчәктә дә бердәм бөек эшләр башкаруга теләк вә омтылышлардан гыйбарәт.[65]

Югарыда сөземтә рәвешендә китерелгән теорияләрнең һәрбере миллият тойгысын тәшкил иткән элемент һәм факторларның бары бер яки икесен нигезләнәләр. Шул сәбәпле түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин:

А. Гегельнең миллият хакындагы фикерләре метафизик һәм мистик характердалар. Аны позитив методлар белән исбат итеп тә, кире кагып та булмый. Бу теория кубәүләр өчен бары шәхси бер принцип кына булып кала. Позитив һәм социологик күзлектән караганда исә миллият тойгысы бары кешеләрнең күңелендә яшәгән рухи бер халәттер. Бу рухи халәттән яки реаль инсани рухлардан тыш ниндидер метафизик мәуҗудият (барлык) юк.

Без Гегельнең милли рухның асылы һәм бәгъзе милләтләрнең җиһан рухын гәүдәләндерүләре сәбәпле дөньяга хаким булырга хаклыгына кагылышлы фикерләрен кабул итә алмыйбыз. Безнең карашыбызча милләт вә миллият тойгысы һич тә метафизик төшенчә түгел, ә милләтне тәшкил иткән кешеләрнең күңелләрендә яшәгән реаль рухи бер халәттер. Милләт

исә шушы рухи халәткә ия булган кешеләрнең бер-беренә бәйләнгән тупламасыдыр.

Гомумән алганда Гегельнең фикере тарихи күзлектән карaганда да ялгыштыр. Чөнки тарих, мәдәният, культура, сәяси кодрәт һәм тарихи рольләре ягыннан бер-берсе белән бөтенләй тигез булган милләт вә дәүләтләрнең бер үк дәвердә яшәгәнлекләре күзгә ташлана. Вавилон мәдәниятының күтәрелгән дәвере Мисыр мәдәниятының да чәчәк аткан чорына туры килә. Рим мәдәнияты һәм культурасы күтәрелгән дәвердә грек мәдәнияты һәм культурасы да әле сүнмәгән һәм «җиһан рухы» анда да үзен бик югары рәвештә сиздерә иде. Алманиянең (Пруссиянең) күтәрелгән дәверендә француз мәдәнияты вә культурасы да, инглиз мәдәнияты да һәм бу ике милләтнең сәяси кодрәте дә юкка чыкмаган иде.

Гегельнең бөтен фәлсәфәсе кебек үк милләт вә милли рух хакындагы фикерләре дә төгәллектән ерак һәм шул ук вакыт фикер иясе булу чигеннән узган даһи бер шагыйрьнең рухыннан ташыган хис туфаны хәлендәге зиһен җимешедер.

B. Социалистларның миллият хакындагы фикерләре шулай ук бу мәсьәләне бер яклы гына куру җимешедер. Югарыда күрсәтелгәнчә социалист мөтәфәккирләрнең карашынча милләтнең хаятендә иң мөһим нәрсә икътисади фактордыр. Инсаният тормышында икътисади факторның мөһим булуы белән бергә бу фактордан башка да бик күп мадди вә рухи факторлар булуы шөбһәсез. Бу хакыйкатне социалист мөтәфәккирләрдән бары Жорес кына аңлаган.

C. Ренанның миллият тойгысының эчтәлеге һәм асылып аңлату рәвеше хаклыкка якындыр. Шул ук вакыт Ренан да милләтнең нинди шартларда һәм нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килүе мәсьәләсенә кагылмыйдыр.

Безнең аңлавыбызча милләт һәм миллиятнең әсаси асылын иң гыйльми шәкелдә ачып бирүчеләр хокук тарихи белән шөгылләнүче социологлардыр. Мәсәлән унтугызынчы гасыр азагында шөһрәт казанган француз социологы Е.Друкһейм милләтне түбәндәгечә аңлата:

«Милләт этнологик һәм тарихи әсасларга таянып фикер йөрткәндә бер үк кануннар астында аерым бер дәүләт буларак

яшәү теләге һәм омтылышы белән көн иткән кешеләрдән оешкан бәшәри төркемдер. Хәзер «милли омтылыш» дип аталган нәрсә мәдәни милләтләргә хас бер принцип буларак кабул ителгәндер».[66]

**Искәрмәләр:**

[1] Sumner Maine. Etudes sur L'Ancion droit et la coutume primitive, Ch. VII P.255—301. Etude sur du droit. La famille patriarcale, P.435—505.

[2] La Cite Antique, Liv.II, V, VIII. Liv. III, III.

[3] Edward Westermack. Histoire du Mariage, Tome II, Chp VIII.

[4] Wundt, Volkerpsychologie, Tome VII, Teil I, Kapit I.

[5] Биологик закончалакны без фәрд (индивид) вә төркемлнәрнең яшәешенең табигый нигезенә бәйле хәләт мәгънәсендә кулланабыз.

[6] Ыруг (Soy) тәгъбире латиндагы Gens, оймак тәгъбире Fratria (Curia), оймаклар союзы булган (кабилә) тәгъбире de File (Tribu) тәгъбирләренең төрекчә мәгънәсе буларак кулланыла.

[7] Без Урта Азия тарихында бу закончалыкның киресен күрсәтүче мисалларны да күзәтәбез (моны шушы юлларны язучы авторның «Төрек тарихы һәм хокук» дигән әсәренең VII китабының 112—116 параграфларыннан күрергә мөмкин).

[8] Бу хакыйкатьне Римләннәр дәүеренең бөек мөтәфәккере Цицерон күрсәтеп үтте. Sigeron de Republika. Liv.VI, VI.

[9] H.Spencer, Principes de Sociologie, Tome III. Partie V, Ch I, II, III.

[10] Lester F.Ward, Sociologie pure, Tome I, Ch. X pp.253, et Suiv. Gumplowiz, La lutte des races. Traduetion de Ch.page, Paris, 1893. Herbert Spencer, Principes de Sociologie, tome III. Partie V. Ch.I, II.

[11] Herbert Spencer, Introduction a la Science Sociale, Ch.IX, P.222. Gumplowiez, Precis de Sociologie, Liv.II, V.

[12] Franklin Henry Widdings, Principles of Sociology. New-York 1920. Liv.I, Ch.I, Liv.II, Ch.II.

[13] W.Mac Dougall, The group Mind. New-York, 1920.

[14] Кешеләр төркеме бер хайвани җәмгыяттер. (Zoopolitikon). Бу хакыйкатне моннан ике мең өч йөз елдан артык элек бөек философ Аристотель (безнең эрага кадәр 384—322) әйтеп калдырган (Aristotel, La Politique, Lis.I, Ch.I 9). Җәмгыяви хайваннар бары тик бер төркем булып, бер җәмгыять эчендә генә яши алалар. Җәмгыять эчендә яшәгән фәрдләрнең үзләре яшәгән җәмгыятькә бәйлелеге аларның үзләренең дә, җәмгыятьнең дә яшәешнең алшартлыдыр һәм бу бәйләнгәнлекнең дәрәҗә вә куәте иҗтимагый төркемнең яшәүгә

булган кодрәтенең күрсәткечедер. (Alfred Espinas, Des Societes animales, Paris, Alkan, 1923). Pierre Grasset. Les societes dinsectes, Dans «les origines de la societe» Renaissonce du Livre. Paris.

[15] Lester F.Ward, Sociologie pure, tome I, Ch.X. E.Renan, Qu'est-ce qu'une Nation Payes francaises, Paris, 1921.

[16] W.Wund, Volkerpsychologie, Band VII, Jeil I, kapitel I, P.65—86. Sadri Maksudi, Hukuk'un Umumi Esaslari. Sahife 40—57.

[17] F.Ratzel. Der Staat and sein Boden geographisch beobachtet. Zeipzig, 1899. In «Annee sociologue», tome I. P.533—539. H.Th.Buckle, History of civilisation in England, tome I, Ch.II.

[18] Бүгенге барлык төрки төркемнәрң дә сүзләре бер үк тамырдан булуып искә алганда аларның бер үк телдә аралаша алулары тарихтан элеккеге дәверләрдә үк куәтле вә озын гомерле дәүләтләр эчендә яшәгәнлекләрен күрсәтәдер.

[19] H.Delacroix, Le langage et la pensec. Paris, 1924. F.Brunot, La penseee et la langue. Paris, 1922. I.Vendryes, le langage. Paris, 1921. Sadri Maksudi, Turk dili irin. Istanbul, 1930.

[20] Mommsen, Histoire romaine, tome I. Ch.IX, Page 145. Prof Ramsay Muir, Nationalisme et interationalisme. Paris, 1918, P.53. Paul Miliyukof. L'Histoire de la culture russe, tome III. P.14—16. Ch.Shignobos, Histoire politique de L'Europe Contempraine, Ch. XIII, XVII.

[21] H.Spencer, Principes de Sociologie, tome III, partie IV.

[22] Аерым милләтләрнең башка милләтләрдән кайбер сүзләр алып үз грамматикаларына яраклаштырып кулланулары милли телнең үсешенә киргә түгелдер. Телләрнең бер-берсеннән аерлышын күрсәтүче иң мөһим хосусият грамматикадыр. Әмма чит телләрдән алынган сүзләр милли сүзләрдән өстен түгелләрдер.

[23] Wund, Volkerpsichologie, band II, Muthus und Religion. Durkheim, Les formes elementaires de la vie religieuse, Paris, 1912. G.Mensehing, Sociologie religieuse, Ch.I. A.Moret et G.Davy, Des clans aux Empires, Partie I, Ch.II.

[24] W.Radloff. «Aus Sibirien», Band II. Das Schamanentum und sein kultus, S.1—67. Sadri Maksudi, Turk tarihi ve hukuk, s.47—54.

[25] Lucien Febvre «La Terre et evolution Humanie L'anciennete des groupements nationaux. Partie II, Chap.III.».

[26] Camille Jullian, L'anciennete de la Nationalite. Revue politique et parlamentaire, 18—25, Janvier 1913.

[27] Fustel de Caulages, la cite antique.

[28] Mommsen, Historie Romaine, tome I, Ch.IX.

[29] Ratzel, Der Staat und sein Boden geograpisch beobahtet. Annec socioloque, tome I. S.533—539.

[30] Gustave le Bon. Les lois psychologiq ues de l'Evolution des peuples. Otto Bauer, La question nationale et la Social-democratie.

[31] Фәрдәләрнең (индивидларның) физик үзенчәлекләре вә хосусиятләре борынгыдан килүе, буыннан буынга күчеше кебек үк үзләренә генә хас рухи хосусиятләренең дә нәселчәнлек юлы белән буыннан буынга күчеше бүген исбат ителгән нәрсә. Моны H.Spencer, Weissman, Galton исбат иттеләр. Yves Delage, A.M.Goldschidt, Les theories de l'evoluton, ch.VII, IX, XII, XIII. H.Spencer, Principes de biologie, Volume I, p.p.302—303, Paris, 1888. Ve Richard Simon, Das problem der Verherbung erworbener Eigenschatiften.

[32] Plutarque, Les vies des Hommes illustres, tome I. P.1—35.

[33] Helmolt's, op.cilt. Tome IV. S.S. 281—283.

[34] Lite-Live, VIII. 34.

[35] Plutarque, op.Cit. tome II, 1—34.

[36] Legende de Nibelungen, edition Ehrhard.Wrimm, Die deutche Helden Sage, Gottingen, 1867.

[37] Chanson de Roland.

[38] Jeanne d'Arc (1410—1431). Франция тарихының иң мәшһүр, кешелләр арасында соклану хисе уяткан каһарманнардандыр. Бу каһарман кыз турында Аурупа телләрендә бик күп әсәрләр язылган, җөмләдән алман шагыйре Шилләр трагедия, француз шагыйре Альфред de Вигни элегия язмыштыр.

[39] Беренчел дип саналган һәм җитлеккән мәдәниятләре булмаган кавемнәргә бәйле фәрдләрнең уй-фикерләрнең әле мантыйкый булмаганлыгы һәм була алмаганлыгы ачыктыр. Беренчел һәм җаһил инсаннар өчен бик күп хакыйкатьнең ачык булмавы аларның Аристотельнең мантыйк эсасларына яраклаштырып фикер йөртү кодрәтеннән мәхрүм булуларыда күренә. Әмма бу Африканың беренчел кавемнәренә генә кагылышлы раслама түгелдер. Бүгенге мәдәни Аурупада да Лондон вә Парижның фәкыйрь мәхәлләләрендә җаһил инсаннар арасындагы күренешләр, мәсәлән, мантыйк вә сәләмәт акыл белән фикер йөртмәүче бик күп бичара бәндәләр барлыгын күрсәтә.

[40] Густав ле Бон милли характер тәгъбире урнына «Ame colletive» (бердәм рух) яки «Constituion mentale» (рухи төзелеш) тәгъбирләре куллана. Les lois psichologues de l'evolution des peuples, Ch.I.

[41] Француз социология галимнәреннән Дуркһейм болай ди: милли аң, бердәм вөҗдан бик акрын формалаша һәм бик акрын юкка чыга.

Нинди дә булса бер эш ысулының, ниндидер бер гомуми инануның барлыкка килүе кебек, аның юкка чыгуы да озак вакытлар эсти (сорый) торган бер процесстыр. Г.Лебон да шул ук фикердәдер (Lts lois psichologiqe de l'Evolution des peuples, Ch.I, II, III).

[42] Милли холык темасына кагылышлы тибәпдәге әсәрләрне күрсәтергә була. Alfred Fouilee, Esquisse psychologique des peuples europeens. Paris, F.Alcan, 1921. Alfred Fouillee, La psyichologie du peuple francais. Paris, F.Alcan. Daniel G.Brinton, The Basis of social relations. A.Study in ethnical psychology, New-York, 1902. W.Mac Dougall, The group mind, New-York, London. 1920. G.Tarde, Les lois de l'imitation, Paris, 1901. Ch.Letourneau, La Psychologie ethnique, Paris, 1901. E.Boutmy, Elements de la Psychologie politique du peuple americain. Paris, 1902. E.Boutmy, Essai d'une psychologie du peuple anglais au XX siecle. Paris, 1901. Gustave Lebon, Le lois psychologiques de I'Evolution des peuples. Paris, 1927.

[43] Кешелек тарихында бөек шәхсиятләрнең роле хакында тәфсиллерәк белергә теләчеләр бу әсәрнең мөәллифенең (авторының). Беренче төрек тарих конгрессында укылган «Tarihin amilleri» дигән докладына төрәҗәгать итсеннәр (Birinci Turk Tarihi Kongresi Zabitlari S.S.339—364).

[44] Биредә исемнәре китерелгән язучы, шагыйрь вә мөтәфәккирләр үз милләтләренең милли рухиятендә яңа барлыкка килгән рухи тенденция вә хосусиятләрне ачы итеп күрсәткән инсаннардыр.

[45] Paris, 1922. Инглизчәсе «Heros and hero worship».

[46] Бу әсәрнең исемен төрекчәгә «**Tarihin oluşu**» (Тарихның барлыкка килүе) дип тәрҗемә итәбез. Бөек шәхсиятләр турындагы китапның беренче җилден тәшкил иткән, «Personlichkeif und Entwickung» исемле бүлегендә сүз алып барыла.

[47] Бөек шәхсиятләрнең тарихи роленә Алман философы Гегель дә игътибар иткән. W.F.Hegel. Vorlesungen uber die Philosophie der Geschicte, Einlutung, K.III.

[48] Тарихта милләтләр телләре һәм диннәренең тышкы басым нәтиҗәсендә үзгәрүе күзәтелсә дә, бу сирәк очрый торган һәм бары бик көчле изү режимы шартларында гына барлыкка килә торган күренеш.

[49] G.Tarde, Les lois de l'imitation, Paris, 1921.

[50] G.Tarde, Op.Cit., P.2.

[51] P.Rossi, Le suggesteur et la foube. Paris, 1904. Gustave le Bon, la Psichologie de la foule, Paris, 1947.

[52] Кара: S.74, paragraf 4.

[53] Гегель карашынча милли рух (Volksgeist) серле, метафизик бер барлык. Милләтне тәшкил итүче инсани төркемнәр бу барлыкның гәүдәләнеше.

[54] Гегель фәлсәфәсендә «Weltgest» (милли рух)ка Аллаһ дәрәҗәсенә якын бер мәгънә бирелә).

[55] Hegel, Grundlinien der Philosophie des Rechts, paragraf 334—360. Leipsig, 1930. Гелель югарыда китерелгән фикерләрен «хокук фәлсәфәсенең нигезләре» исемле әсәренә керештә, тарих фәлсәфәсенә кагылышлы «Vorlesungen uber die Philosophie der Gesehichte» исемле әсәрендә бик тәфсыйльле рәвештә аңлата. Гегельнең бу әсәрендә һәр милләтнең милли рухы барлылын исбат итүче фикерләр җитәрлектер. Мисал итеп әйтелгән әсәрнең бишенче бүлегендәге «Die germanische Welt» фасылын китерә алабыз.

Гегельдән башка алман мөтәфәккир тарихчыларыннан Л.Ранке дә миллиятнең нигезләре хакында метафизик фикерләр китерә (Die Osmanen und Spanische Monarchie in XVI und XVII Jahr.).

[56] Славянчылыкка кагылышлы әсәрләрдән түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: Louis Leger, Le Panslavisme. Pupnin, le panslavisme dans le passe et dans le present.

[57] Karl Marx, Friedrich Engls, Manifest of the communist party. New-York, International Publisher, p.28. Le Manifeste du Parti Communiste, Paris 1934, edition d'Alfred Costes, Pages 91—92.

[58] Бүгенге Русиядә идарә итүче Коммунистлар милләтләренең ireген һәм мохтариятын сүздә танысалар да, алларында тоткан максатлары милләтләрне миллиятсезләндереп тора-бара бер социалистик совет милләте «тудырмак» өчен бөтен гайрәтләрен сарыф итмәктәдер.

[59] Otto Baner, La question nationale et la demokratie sociale. III. P.131.

[60] Ibidem, III, p.161.

[61] K.Kautski, Nationale de Notre temps.

[62] J.Jaures, L'Armec Nouvelle. Paris Rouff, p.p.553—586.

[63] L'Humanite et la nature ambiante. La question nationale.

[64] Principe spirituel.

[65] Ernest Renan, Quest-ca que la Nation? Pages Franraises, p.p.68—73. Paris, Calmann Levy.

[66] Rene Johannet, Le Principe des Nationalites MCMXVIII. Paris, pp.22—23.

# III. МИЛЛИЯТ МӘСЬӘЛӘСЕНДӘ КАРШЫЛЫКЛЫ АГЫМНАР

## 1. КОСМОПОЛИТИК АГЫМ

Космополит тәгъбире грек телендәге ике сүзне бергә кушып ясалган сыйфат: 1) космо — «дөнья, галәм», 2) политес — «ватандаш». Космополит — «дөнья ватандашы», ягъни теге яки бу өлкәне түгел, ә бәлки бөтен дөньяны үзенең ватаны дип кабул иткән кеше.

Бу җәһәттән, космополитлык (cosmopolitisme) теге яки бу кешенең бөтен милләтләргә карата да яхшы күңеллелек һәм симпатия белән каравы мәгънәсендә йөри.

Шулай да, космополитлык сүзенең төп мәгънәсе — миллият дошманы булу, миллият тойгысын күралмау. Без дә биредә бу сүзне шушы мәгънәдә кулланачакбыз.

Шулай итеп, космополитлык — миллиятне инкяр иткән, миллият тойгысын һәм нигезен зарарлы нәрсә дип расларга тырышкан, ә милләтләрне киләчәктә юкка чыгарга хөкем ителгән төркемнәр тупланмасы дип кабул иткән бер агым.

Үзләрен «суллар» дип атаган анархистлар һәм коммунистлар белән социалистларның да күбесе космополитлар.

Мәсәлән, рус социализмы тарихында мөһим роль уйнаган Лавров, миллияткә карашын шул рәвешле аңлата: «Социаль мәсьәлә — безнең карашыбызча, беренче дәрәҗәдә мөһим мәсьәлә. Социаль көрәш мәсьәләләре янында һәм каршысында миллият мәсьәләсе юкка чыгарга тиеш. Социаль проблема өчен тел аерымлыклары, милли традиция үзенчәлекләре юк. Бары тик кешеләр һәм бөтен кешеләргә уртак социаль максатлар гына бар. Бу принциплар миллият аерымлыклары белән нигезле сурәттә көрәшергә тиешләр».[1]

Марксистлар һәм коммунистлар да космополитлар. Карл Маркс белән Энгельсның дөнья эшчеләренә мөрәҗәгать иткән

язмаларында болай диелә: «Коммунистлар ватан һәм милләтне юкка чыгарырга тырышуда гаепләнәләр. Эшчеләрнең ватаны юк һәм үзләре хуҗа булмагач, алар нәрсәдән мәхрүм ителсеннәр икән. Милләтләр арасындагы аерымлыклар, хосусиятләр, дошманлык буржуазиянең үсеше, җитештерү ысулларының һәр мәмләкәттә бертөрле шәкел алуы, сәүдә иреге һәм ул тудырган тормыш мөнәсәбәтләре нәтиҗәсе буларак юкка чыгачаклар. Пролетариат хакимлеге, властьнең пролетариат кулына күчүе милләтлернең юкка чыгуын тизләтәчәк».[2]

XIX гасыр ахырларында Аурупада зур шөһрәт казанган немец философы Ницше да космополит иде. Ул болай ди: «Сәүдәнең һәм промышленностьның үсеше, нәшрият һәм китаплар арадашлыгы ярдәмендә милләтләр арасында мөнәсәбәтләрнең ныгуы, югары культураның уртак булуы, кешеләрнең яшәгән урыннарын җиңел алыштыра алулары, крестьян булмаган халыкның «күчмә» тормышы — бөтен бу шартлар туктатылуы мөмкин булмаган бер сурәттә миллият тойгысының һәм ахыр чиктә, һич булмаса Аурупада, милләтләрнең юкка чыгуына җирлек хәзерли. Милләтләрнең берләшүе нәтиҗәсендә яңа бер «ырык» (милләт?) барлыкка киләчәк».

Маркcның да, Ницшенең дә әсәрләрендәге югарыда сүз алып барылган фикерләрне, миллияткә дошманлыкның чагылышы дип түгел, ә галим һәм фикер иясенең гыйльми карашлары дип кенә дә күзалларга мөмкин.

Ләкин дөреслек бу рәвешчә түгел. Маркcның да, Ницшенең дә миллияткә булган тискәре карашлары объектив фикер йөртү һәм анализлау нәтиҗәсе булудан бигрәк, үзләренең фәлсәфи доктриналары белән килешүе мөмкин булмаган миллият нигезенә карата бер күралмау хисенең чагылышы иде.

Миләтләрнең яшәеше, милли хиснең көчле бер тарихи дәлил булуы — болар, әлеге фикер ияләренең фәлсәфи һәм тарихи карашларына каршы төшкәнгә һәм алар төзегән карашлар системасы белән килешүе мөмкин булмаган бер чынбарлык булганга, аларның фикеренчә, «эч пошыргыч» күренешләр генә иде. Бу фикер ияләренең, милләтләр юкка чыгарга хөкем ителгәннәр, дигән фикерләре исә, бары тик

күңелләрендә туган бер теләкнең гыйльми тышчага төренгән чагылышы гына.[3]

Маркс — материалист буларак, рухи барлыкның күптәнге дошманы. Икенче яктан, бу фикер иясе икътисади сәбәпне бөтен иҗтимагый күренешләрнең бердәнбер этәргече дип кабул итә һәм бөтен кешелек тарихын сыйныфлар көрәше итеп күрсәтергә тырыша. Шуңа бәйле рәвештә, ул бөтен дөньяның эшчеләр сыйныфын берләшергә һәм капиталистик сыйныф булган буржуазия белән көрәшергә чакыра. Әмма, дөнья эшчеләренең Маркс теләгәнчә ватаннарын онытып, милләтләрен юк дип фараз кылып берләшәчәкләренә киртә булып төшкән зур каршылык бар, ул — миллият нигезе, миллият тойгысы.

Маркс — фәлсәфи һәм социологик карашларына бәйле рәвештә миллият нигезенең дошманы.

Марксизмны фәнни һәм нигезле сурәттә тикшергән һәм тәнкыйть иткән галимнәрнең берсе — немец галиме Рудольф Штаммлердер. Аның хезмәтенең исеме «Wirtschaft und Recht».[4]

Маркснең «тарихи материализм» исеме белән мәгълүм булган социологик карашларын ныклы фәнни дәлилләргә таянып тәнкыйть иткән икенче бер фикер иясе — танылган чех галиме һәм миллиятчесе Теодор Масарик. Масарик «Die plilosophischen und soziologischen Crundlagen des Marxismus»[5] исемле әсәренең, Маркс һәм Энгельсның миллият турындагы фикерләрен тикшерү вә тәнкыйть итүгә багышланган бүлегендә (VIII бүлек, 115, 116) бодай ди: «Маркс та, Энгельс та заманыбыздагы милләтләргә хас миллият хисенең үсешен күзәтә алмаганнар. Бу аларның тормыш шартлары һәм үз шәхесләренең үсеш-үзгәреш рәвеше белән аңлатыла ала».

Масарик моны түбәндәгечә ачыклый: Маркс та, Энгельс та асылда космополит буларак формалаштылар. Алманиядә урнашкан самодержавиегә каршы баш күтәрү аларны башта Франциядә, соңыннан Англиядә яшәргә мәҗбүр итте. Парижда, Брюссельдә, Швецариядә төрле милләтләрдән торган пролетариат сыйныфы вәкилләре белән бәйләнешкә керделәр. Шуның нәтиҗәсе буларак, шигары (лозунгысы): «дөнья пролетарийла-

ры, берләшегез!» булган коммунистик мөрәҗәгать басып таратылды. Марксизм башыннан ук бәйнәлмиләл (интернациональ) бер шәкелдә формалашты. Әмма бу хәл озак дәвам итмәде, һәр мәмләкәттә аерым милли социалистик партияләр төзелде. Чөнки XIX гасырда миллиятчелек тел мәсьәләсендә генә түгел, бәлки башка барлык мәсьәләләрдә дә үзен сиздерә башлаган күренеш иде. Фредерих Листның икътисад өлкәсенә караган фикерләре, Савигниенең хокук мәсьәләсенә кагылышлы карашлары; Фихте, Гегель, Вагнернең фәлсәфә өлкәсендәге фикерләре, Русиядә барлыкка килгән славянчылык агымы — боларның бөтенесе дә миллият тойгысы тәэсирендә туган юнәлешләр иде. Миллият хисе Австрия һәм Русия империяләрендәге әсир милләтләрдә дә ачыла башлаган иде.

Маркс белән Энгельс бу агымнарның барысыннан да читтә калдылар һәм миллият юнәлеше белән килешүгә бара алмадылар. Шуңа да карамастан, алар үзләренең күңелләре белән алман (немец) булып калдылар. Маркс белән Энгельсның «алманлык» хисе Германиянең берләшүе мәсьәләсендә генә түгел, славяннарга карата булган мөнәсәбәтләрендә дә үзен сиздерә иде. Тик аларның миллият тойгысы, әлбәттә, телләре, миллиятләре юк итүгә юнәлдерелгән, сәяси мөстәкыйльлектән мәхрүм ителгән әсир милләтләр хис иткән тойгы белән бер була алмый иде. Чөнки алманнарны милли телләреннән һәм миллиятләреннән мәхрүм итүне максат итеп куйган бернинди көч тә, бернинди дәүләт тә юк иде.

Менә шушылар нәтиҗәсендә марксизмга нигез салучылар миллиятне бары тик сәяси һәм иҗтимагый мәгънәдә генә аңладылар, бу хисне бары тик икътисади шартлардан туган бер күренеш дип кенә кабул иттеләр. Маркс шактый язмаларында милләт белән дәүләтне бергә катыштыра, һәр икесен эгоизм җимеше дип кабул итә.

Марксизмга нигез салучылар милләтне һәм миллиятне тарихи материализм күзлегеннән карап тикшерергә һәм тәнкыйть итәргә тиешләр иде. Тик бу эшне башкарып чыкмаганнар. Чөнки, марксизмның миллият мәсьәләсендәге теоретик фикерләү юнәлеше фәнни түгел.

Ницшегә килсәк, бу фикер иясе фәлсәфәсенең нигезе — мәгълүм булганча, иҗтимагый тормыш һәм мәдәният өлкәсендә хәзергә кадәр юл күрсәтүче булып торган акыл, дин, әхлак, демократия кебек бөек төшенчәләрне инкяр итүдән гыйбарәт. Ницше кешелекне бу күренешләргә бәйле булып калмаячак дип саный, аларны бары физиологик деградация нәтиҗәсе итеп кабул итә.[6] Ницшенең максаты — «кыйммәтләр баскычын аудару», ягъни кешеләр тарафыннан бүгенгә кадәр югары бәяләнеп килгән кыйммәтләрне инкяр итеп, көч һәм кодрәт туплау өчен генә тырышкан, шәфкать ни дә, мәрхәмәт ни икәнлеген белмәгән, һәрнәрсә, һәркемне һич тартынмыйча тап-тап китә алган, мин-минлеге соң дәрәҗәгә җиткерелгән «өстен кеше» барлыкка китерү.[7]

Бу мәшһүр, тик шөбһәсез, башта ук рухи хаста булган, ә соңыннан акылын бөтенләй югалткан мөтәфәккирнең (фикер иясе) башка әхлакый кыйммәтләр белән бергә, мәдәният тарихында бөек иҗади көч ролен уйнаган миллият нигезен инкяр итүе гаять табигый.

Космополитларның миллияткә каршы юнәлдерелгән һәм алга сөргән фикерләре шул: «Кабиләләр бер дәүләт эчендә берләшеп, озын-озак вакытлар бергә яшәүләре нәтиҗәсендә кабиләчелек тойгысын ничек оныткан һәм ничек итеп милләтләр барлыкка китергән булсалар, шулай бүгенге милләтләр дә бөтендөнья күләмендәге бер «кешелек дәүләте» эчендә миллиятләрен онытып, бик шәп, миллиятсез бер «кешеләр тупламы» хәленә килерләр».

Бу фикернең психологик һәм социологик нигезләре булмаганлыгын алдагы бүлектә аңлатырга тырышачакбыз.

## 2. КОСМОПОЛИТИЗМНЫҢ ПСИХОЛОГИК ҺӘМ СОЦИОЛОГИК НИГЕЗЛӘМӘЛӘРГӘ КАРШЫЛЫГЫ

Космополитлар, коммунистлар һәм миллият дошманнары теләгәнчә, бүген яшәештә булган милләтләрнең юкка чыгуы, кешелекнең миллиятсез «бәшәри туплам» хәленә килүе мөмкин түгел.

Милләтләрне юк итеп миллиятсез бер «бәшәри туплам» барлыкка китерүгә мөмкинлек бирмәгән төп сәбәп—бүгенге милләтләрнең югары культура җирлегендә туган психологик халәте, моның нәтиҗәсе булган әхлакый һәм хокукый карашлары һәм нәселчәнлек канунына нигезләнгән, һаман тирәнәя барган миллият тойгысы.

Тарихка күз салсак, борынгы дәверләрдә бер үк ырыкка караган кечкенә төркемнәрдән зур гына бер төркемнең барлыкка килүе, күбесенчә, үзара яраклашу юлы белән барган. Бу башлыча ике шәкелдә булган:

1) Кечкенә төркемнәрнең, хакимият көченә ия булган зур төркемнең гореф-гадәтләрен, телен, кануннарын үз теләк вә ихтыярлары белән кабул итүләре.

2) Хакимият көченә ия булган төркемнең үз гореф-гадәтләрен, кануннарын һ. б. кабул иттерер өчен басым, җәбер куллануы.

Вакыты белән бер үк ыругка караган, әмма телләре югары үсеш ала алмаган кабиләләрнең, хакимлек итүче кабиләгә охшашлану юлы белән аның эчендә эрүе кайчагында кулайрак та булган.

Бүгенге милләтләр өчен бу инде мөмкин хәл түгел. Чөнки, хәтта латин милләтләре кебек бер-берсенә якын телләрдә сөйләшкән һәм озын уртак тарихы булган милләтләрдә дә милли аң бик нык үскән. Бүген бөтен мәдәни милләтләрнең милли тарихлары, югары үсешкә ирешкән телләре, халыкта зур горурлык хисе тудырган бай сәнгать әсәрләре, материаль мәдәният истәлекләре бар. Бу хәзинәгә ия булган милләтләрнең тәкълит (иярү) юлы белән бер-берләренә охшашлануларын, ягъни милләтләреннән баш тартуларын күз алдына да китереп булмый.[8]

Дөрес, римляннар кебек кайбер тарихи милләтләрнең инде тәмам оешып җиткән милләтләрне йотуы да күзәтелә. Әмма, Римда барлыкка килгән императорлык бер милләт булудан бигрәк, милләтләр тупламы иде һәм Рим җимерелгәннән соң, шунда ук бүлгәләнде.

Бу катнашманың, бу эретмәнең барлыкка килүе бары зур күләмдә җәбер-золым һәм басым куллану нәтиҗәсендә мөмкин

булды. Бүген исә, ассимиляцияләү өчен бу алымга мөрәҗәгать итү — мөмкин булмаган хәл. Чөнки, бүген инде бер генә милләт тә башка бер милләтне үз динен, телен, гореф-гадәтләрен кабул итәргә мәҗбүр итә алмый. Бүгенге көндә милләтләр юкка чыгып, бөтен бәшәриятнең бер төр масса хәленә килүенә киртә булган тагы бер сәбәпне күрсәтеп үтәргә кирәк:

Тарихта бер милли төркем тарафыннан башка төркемнәрнең ассимиляцияләнүе тәкълит (иярү) юлы белән булса да, мәҗбүр ителү нәтиҗәсе булса да, үзенә иярткүче яки көчләп кушучы мәгълүм бер милләт тарафыннан башкарылган. Бу, гадәттә, дәүләт белән хакимлек итүче милләт: римляннар, гарәпләр, англосаксоннар.

Бөтен дөньяда бер «бәшәри туплам» барлыкка килсен өчен, бүген яшәештә булган милләтләр кайсы милләткә иярәчәкләр? Я булмаса кайсы милләткә охшарга мәҗбүр ителәчәкләр?

Әгәр, милләтләрнең бер төрдәге бәшәри туплам хәленә китерелүе, аларны бүген яшәештә булган олуг дәүләтләрнең, «Дүвали муаззама«ларның берсенә охшашландырудан гыйбарәт икән, ул вакытта сул фикердә торучылар— бердәнбер милләтнең бөтен дөньяда хакимлек итүенә җирлек хәзерләүче агым булуы күзгә ташлана. Монда максат — милләтләрне бүген яшәештә булган теге яки бу милләткә охшашландыру булмыйча, әле яшәмәгән, тик киләчәктә оешачак дип күз алдына китерелгән бер «Х» милләткә охшашландыру була икән, ул чакта бу тормышка ашуы бөтенләй мөмкин булмаган бер хыял гына. Чөнки, кайчандыр яшәгәне дә, кайчан да булса яшәячәге дә билгеле булмаган ниндидер бер хыялый «Х» милләтенә охшау да, охшашландыру да мөмкин түгел.

Нинди генә караштан чыгып өйрәнелсә һәм анализланса да, космополитизмның ялгыш бер фикер җимеше булуы ап-ачык бер хакыйкать булып алга баса.

Миллият дошманы булган космополитизм тарихи караштан ялгыш бер фикер булган кебек, социология һәм иҗтимагый психология ягыннан караганда да ялгыш. Чөнки, җәмгыять барлыкка килгәннән бирле, «кеше» гаилә, кабилә, милләт кебек

тупланмаларга бәйле булмаган хәлдә яшәмәгән һәм яши дә алмаячак. «Туплам хисе» — кешенең тирән рухи элементларының берсе.

Кешенең рухи хәятенең бер элементы булган һәм бүген миллият тойгысы шәкелен алган бу хис ниндидер бер мөтәфәккирнең теләк һәм ихтыяры яки ниндидер бер партиянең «программасына кертелгән» «миллиятсезлек принцибы» аркасында гына җәмгыять тормышыннан сызып ташланыла алмый. Миллият хисеннән мәхрүм индивидлардан оешкан бер «бәшәри милләт»нең барлыкка китерелүе—бөтен милләтләрнең милли идеалларының бердәй рәвеш алуы, милли психологияләр арасында аерымлыклар калмау кебек шартларның үтәлүенә бәйле. Ә бу исә, тормышка ашуы бөтенләй мөмкин булмаган бер хыял гына.

Мәгълүм булганча, дөньядагы бөтен нәрсәләр дә төссез, иссез, күзгә күренмәс кечкенә кисәкчекләрдән, ягъни атомнарның төрле шәкел һәм нисбәттә берләшүеннән хасил була. Бу атом берләшмәләренең бер өлеше органик булмаган матдәләрне барлыкка китерә. Милләтләр дә, «кеше» дип аталган иҗтимагый «атомнар»ның берләшүеннән хасил булган бәшәри төркемнәр, бер-берләреннән аермалы рухи һәм матди барлыклар. Бүген бер үк атом кисәкләреннән хасил булган алтынны тимергә әйләндерү мөмкин булмаган кебек, милли психологияләре, милли характерлары, социологик корылышлары һәм тормыш үзгәлекләре ягыннан бер-берсеннән бөтенләй аермалы булган француз фикер сөрешен инглиз милли концепциясенә, алман милли психологиясен итальян психологиясенә әйләндерү дә мөмкин түгел.

Миллият нигезләренә дошманлык рухы белән сугарылган фикердә, куәтле булып күренгән дәлилләрнең берсе түбәндәгечә яңгырый: «Миллиятнең асылы милләтләр арасында килешмәүчәнлек, дошманлык һәм нәтиҗәдә сугышлар китереп чыгара. Бу фикер беренче нәүбәттә, тарихи яктан һәм психологик караштан ялгыш: бәшәри төркемнәр арасындагы дошманлыкны «миллият» тойгысы тудырмый. Әгәр миллиятнең асылын милләтләр арасында каршылыклар һәм дошманлык тудыруы өчен юкка чыгару кирәк булса, бу мантыйк буенча бәшәрият

хәятеннән гаилә мөнәсәбәтләрен дә сызып ташлау, юкка чыгару кирәк булыр иде. Чөнки күп очракларда, гаилә эгоизмы да гаиләләр арасында дошманлык, конкурентлык һәм көрәш тудыра. Димәк, бу эгоизм күренешләрен юкка чыгару өчен иң хәлиткеч юл—гаиләнең үзен юкка чыгару. Кешеләр дә, хайваннар кебек очраклы җенси мөнәсәбәтләрдә булсыннар, бу мөнәсәбәтләрдән туган, атасы билгесез балалар бала тәрбияләү йортларында үссеннәр, аналарын да, аталарын да танымасыннар, ата-анасы урынына җәмгыятьнең бөтен кешеләрен, барлык ватандашларын бер үк дәрәҗәдә сөйсеннәр. Әмма гаилә мөнәсәбәтләре юкка чыгарылса, гаиләләрне бер-берләренә каршы куйган үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту хисләре урынына, бөтен җәмгыятькә карата гомуми бер сөю, мәхәббәт хисе туар дип уйлап бик нык ялгышырга мөмкин.

Нәкъ менә гаиләне юкка чыгару фикере, кызганыч ки, кешелек җәмгыятенең иң бөек философларыннан саналган берәүнең зур ялгышы иде. Бу фикерне иң беренче булып, борынгы грек философларыннан Әфләтун алга сөргән.[9] Әфләтун фикеренчә, гаилә дә, мал-мөлкәт тә гамәлдән чыгарылырга тиеш. Мәмләкәттәге бөтен байлыклар кебек хатыннар һәм балалар да бөтен җәмәгатьчелек өчен уртак булырга тиешләр. Бары тик шул вакытта гына бөтен ватандашлар бер-беренә кардәш булыр, бер-берләренә карата бер үк хисләр белән яшәрләр.[10]

Әфләтунның бу фикерләрен, остазына караганда реалистрак булган шәкерте Аристотель түбәндәге сүзләр белән кире кага һәм тәнкыйть итә: «Гаилә табигый һәм зарури бер нәрсә. Гаилә мөнәсәбәтләрен юк итеп, гаилә урынына дәүләтне куярга маташу—бу бары яшәеше реаль булган гаилә бәйләнешләрен хыялда гына яшәгән бәйләнеш—дәүләткә бәйләнеш хисләренә корбан итү булыр иде. Балалар дәүләт балалары булган очракта, һичкем, һичбер ватандаш бу балаларга карата, ата-ана үз баласына карата тоя торган шәфкать хисен тоя алмас. Чын сөю, үз итеп кайгырту бер-беренә «кан» кардәшлеге белән бәйле булган кешеләр арасында гына мөмкин. Гавәм эчендәге мәхәббәт һәм бәйләнеш хисләре исә бары диңгезгә салынган берничә тамчы бал кебек кенә: шунда ук эреп юкка чыга да бетә».[11]

Әфләтунның моннан 2200 ел элек гаилә хакында әйтелгән фикерләре никадәр ялгыш һәм никадәр киләчәксез фикерләр булса, бүгенге космополит мөтәфәккирләрнең миллият хакындагы уй карашлары да шул ук дәрәҗәдә дәлилсез, шулар кебек үк тотрыксыз, тормышка ашырылуы мөмкин булмаган фикерләр.

Аристотельнең гаилә турында әйткән сүзләрен бер үк вакытта зур гаилә булган милләтләргә карата да кулланырга мөмкин; миллиятсез бәшәриятка карата булган бәйлелек хисе, һич кенә дә, миллият тойгысының һәм милләткә мәхәббәт хисенең урынын ала алмас.

Әфләтун, гаилә хакында әйтелгән фикерләрен алга сөргәндә, гаиләнең юкка чыга алачагына ышанган. Тик моннан соң инде 2000 ел үткән булса да, кешелек җәмгыяте гаилә мөнәсәбәтләреннән ваз кичмәде, ваз кичү ихтималы да юк.

Милләтләр дә — гаилә кебек ук, иҗтимагый мөнәсәбәтләр күренеше. Бер уртак телдә сөйләшкән, үзенә хас гореф-гадәтләре, уртак тарихы, уртак әдәбияты һәм милли холкы булган бер зур төркемнең аерым һәм мөстәкыйль милләт буларак яшәвенә кем һәм нәрсәгә таянып киртә була алыр?

Бу мәсьәләләр хакында җитди уйлану көчен югалтмаган һәр зыялы тоячак һәм аңлаячак ки, гаиләсез җәмгыять әхлакый бозыклык һәм рухи таркалу лабораториясенә әйләнергә мөмкин булган кебек, милләтләр юк ителгәннән соң, алар хәрабәсе өстендә барлыкка киләчәк дип күзалланган, биологик һәм социологик нигезләрдән мәхрүм, миллиятсез «бәшәрият» рухсыз бер көтүдән башка бернәрсә дә була алмаячак.

Кешелек тарихын социологик һәм хокукый карашлардан чыгып өйрәнүләрдән туган һәм бүген социологлар тарафыннан бер хакыйкать буларак кабул ителгән нәтиҗәләрнең берсе шул: миллият нигезенә корылган дәүләтләрнең барлыкка килүе, ягъни милли дәүләт диелгән бер оешманың тууы— мәдәнилек (цивилизация) тарихында мөһим һәм исбат ителгән бер күренеш булып тора.

Һәр милли дәүләт, үзе тәэмин иткән тынычлык һәм хокук тәртибе белән бер мәдәният мәктәбе булып торган.

Милли дәүләтләр, югары дәрәҗәдәге диннәрнең, фәлсәфә һәм әхлак системаларының барлыкка килүенә, гыйлем һәм фәннәрнең үсешенә мөмкинлек биргән иҗтимагый һәм сәяси җирлек булып торганнар.[12]

Суллар, революцияне күз алдында тотып, милләт дигән мөнәсәбәтләрнең инде аз дигәндә җиде меңъеллык тәҗрибә белән расланган гамәли нәтиҗәләрен онытып «милләт» төшенчәсе урынына «халык» төшенчәсе кулланып, чынлыкта ниндидер аңлаешсыз максатка ирешмәкчеләр.

Миллияткә каршы алып барылган бу пропаганда милли дәүләтләрнең яшәеше һәм үсеше өчен бик зарарлы һәм куркыныч бер нәрсә. Чөнки, миллият тойгысының юкка чыгуы мөмкин булмаса да, милли дәүләтләрнең җимерелүе мөмкин хәл. Моның өчен милләт эчендә миллият хисеннән мәхрүм, ватанына хыянәт итәргә хәзер булган берникадәр кешенең барлыкка килүе һәм аларның төрле урыннарда рухи һәм сәяси «күпербашы» (ягъни плацдарм) ясаулары да җитә. Кызганыч ки, һәр милләттә пропагандага җиңел бирелгән, милли принциплары зәгыйфь кайберәүләр булганлыктан, бу «бер уч» кеше ачык яисә яшерен эшчәнлекләре, туктаусыз үткәргән үгет-нәсихәтләре белән дәүләтнең җимерелүен хәзерли алалар. Шуңа күрә, заманыбыздагы дәүләт эшлеклеләренең мондый пропагандаларга карата бик аек булулары аеруча мөһим. Чөнки, озакка сузылган, системалы бер пропаганда нәтиҗәсендә милләтнең нигезләре какшавы бик мөмкин.

Күз алдына шундый бер дәүләтне китерик: миллияткә каршы пропаганда нәтиҗәсендә бу милләткә караган бер төркем кешеләрдә милләткә бәйлелек һәм дәүләткә тугърылык хисләре юкка чыккан булсын һәм бу бәндәләр яшерен оешмалар төзеп, миллияткә каршы астыртын эш җәелдерсеннәр; төрле мәсләктәге кешеләр арасына үтеп кереп, миллият хисен агулаучы үгет-нәсихәт таратсыннар, хәтта шушы яшертен әмма системалы пропаганда нәтиҗәсендә дәүләт чиновниклары арасында да шәхси мәнфәгатьләре өчен дәүләт серләрен сатарлык дәрәҗәдә рухи түбән кешеләр барлыкка килсен, миллият дошманына әйләнгән язучылар миллият той-

гысына таркаулык кертердәй мәкаләләр, роман авторлары миллият хисен көлке хәлгә куярдай, романнар, милли хистән мәхрүм тарихчылар милләтнең бөек тарихи шәхесләренә һәм мөкатдәс ядкярләренә карата ихтирам күрсәтелмәгән әсәрләр язсыннар, ди; милләтнең парламентында ачыктан-ачык дәүләткә каршы эш алып баручы партияләр барлыкка килсен, ди. Мондый дәүләтнең язмышы нинди булыр?

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Аурупаның шактый мәмләкәтләрендә югарыда тасвир ителгән тискәре күренешләрнең күбесе күзәтелә һәм бу мәмләкәтләр күп тә үтми җимереләләр, бәйсезлекләрен югалталар.

Бу рәвешле әхлакый һәм милли упкынга тәгәрәү куркынычыннан, күп шөкер, хәзергә кадәр тәңре төрек милләтен саклады. Бездә, әле язып үткән шәкелдә бер милли бозыклык һавасы барлыкка килә алмады. Дошманнарыбыз безнең мәмләкәттә дә шундый бер милли һәм әхлакый җимереклек тудыру өчен кулларыннан килгәннең һәммәсен эшләсәләр дә уңышка ирешә алмадылар. Төрек милләтенең аек акылы, миллиятенә, тарихына бәйлелеге, дини инанулары, иман саулыгы милләтебезне дошманнары теләгән деградация куркынычыннан хәзергә кадәр коткарып килде.

## 3. ШОВИНИЗМ

Индивидуаль буламы, коллектив буламы, һәр хис Һәм һәр иҗтимагый принципның таркалу кичерүе мөмкин булган кебек, миллият тойгысының да деградацияләнүе, асылына капма-каршы шәкел алып, хакыйкый максатыннан читкә тайпылуы мөмкин.[13]

Миллият тойгысының шулай деградацияләнгән бер шәкеле—шовинизм. «Шовинизм» сүзе Шаувин исемле бер французга барып тоташа һәм «Шаувинчылык» мәгънәсендә кулланыла. Николас Шаувин Франциядә Рошефорт шәһәрендә туган, революция вакытында һәм Наполеон сугышларында 17 тапкыр яраланган бер гаскәри. Ватанына, бигрәк тә императорның шәхесенә нык бәйле булуы, аны бөтен Франциягә мәшһүр иткән. Заманында, Шаувинның телләрдә дастан дәрәҗәсендә

йөргән ватанпәрвәрлеген мактап җырлар чыгарылган һәм алар бөтен Франциядә җырланылганнар. Менә шушы кеше шәхесенә бәйле рәвештә ватанны сөю мәгънәсендә «шовинизм» сүзе барлыкка килә дә. Соңыннан бу сүзгә тискәре мәгънә салынган. Шулай итеп, бүген бу сүз ватанын чиктән ашып яратучы дигән мәгънәне белдерүдән бигрәк, башка милләтләргә түбәнсетеп карау, үз милләтеннән башка милләтләрне бернигә дә санамау мәгънәсендә кулланыла.

Чын милли хистән аерылып торган һәм чигеннән чыккан зарарлы шовинизмны түбәндәгечә аңлата алырбыз.

Шовинизм — үз милләтенең кимчелекләрен күрмичә, аның өстенлекләрен чиктән тыш күпертү, ә башка милләтләрнең бары кимчелекләренә генә игътибар итүгә бәйле берьяклылык күренеше.

Шовинизм миллият хисенең бер авыруга әйләнеп үскән шәкеле, «гипертрофия»се. Нормальлектән авышкан бөтен хисләр кебек, әлбәттә, шовинизм да зарарлы бер рухи халәт. Сәламәт, нык һәм рациональ миллиятчелек башка милләтләргә карата дошманлыкны да, кимсетеп карауны да хуп күрми.

Шовинизм ялгыш карашларга, ялгыш хөкемнәргә һәм нәтиҗәдә ялгыш сәяси адымнарга китерә торган бер рухи халәт. Бөек социолог Герберт Спенцер бу үзенчәлекне «ватанпәрвәрлек нигезендә туган ялган фикер» (Preiuje de patriotisme) дип атый һәм «Иҗтимагый фәнгә кереш» исемле әсәрендә шовинизмның төрле өлкәләрдә үз чагылышын тапкан шәкелләрен анализлауга тулы бер бүлек багышлый.[14] Шовинизм аркасында инглиз һәм алман әдәбиятында французлар хакында бик күп ялгыш карашлар, дөреслектән ерак торган хөкемнәр һәм нигезсез гаепләүләр очратабыз. Французлар, алман язучыларының күбесе раслаганча беркатлы һәм җиңел акыллы милләт булмаган кебек, алманнар хакында француз шовинистларының сөйләгән, язган нәрсәләренең дә күбесе объективлыктан ерак.

Декартны, Паскальне, Бергсонны биргән, мәдәният һәм культура тарихының иң якты бер дәверендә бөтен Аурупа милләтләренә рәхбәрлек иткән (юл күрсәткән) бер милләт, ягъни француз милләте, тоташтан беркатлы милләт дип

бәяләнә алмас. Шулай ук, Гетены, Шиллерны, Бетховенны, Бахны биргән алман милләтен дә бөтенләе белән тупас бер милләт итеп бәяләргә ярамас.

Милләтләрнең бер-берләренә ихтирам һәм үз итү хисләре белән карауларына ирешү бүгенге кешелеккә лаек бер максат булып тора. Моның юлы — милләтләрне шовинистик фикерләрдән коткару. Культуралы кешенең миллиятчелеге — башка милләтләргә хөрмәт белән сугарылган, шовинистик фикерләрдән азат булган, рациональ бер миллиятчелек.

Беренчел кешеләрдәге агрессивлык, аларның юк кына бер сәбәп аркасында башкаларга ташланучанлыгы, талауга китерерлек вәхши эгоизмы, бүген югары культура, югары дин һәм югары хокукый тәртипләр ярдәмендә нинди рациональ кысаларга кергән, ә эгоизм хисе «кешелек дәрәҗәсе», «үз-үзеңне яклау» һәм «үз-үзеңне саклау» хисләре шәкелендә калкып чыккан булса, миллият тойгысы да кешелек җәмгыяте эчендә культура җәелә барган саен рациональ бер шәкел алачак һәм ала бара.

Тик, мәдәният өлкәсендә милләтләр никадәр генә алга китсәләр дә, кешеләр арасында күзәтелгән үз-үзен яклауга хокук мәңгелек булган кебек, милләтләр өчен миллиятчелек тә, шулай ук, кешелек яшәгәндә яшәячәк.

## 4. ИМПЕРИАЛИЗМ

Миллият хисенең тагын бер бозык һәм дегенерацияләнгән шәкеле бар. Ул— билгеле бер милләт кешеләренең үз милләтләрен башка милләтләрдән өстен күреп, үзләрен аларның хөкемдары булырга хаклы санаулары. Моңа «хакимият психозы» яки «агрессив миллиятчелек» исеме бирергә мөмкин.

Башка милләтләрнең ирегенә, бәйсезлегенә, матди һәм рухи байлыгына агрессияне аклаган, башка милләтләрне үз хакимияте астына алуны үзе өчен бер хәер-хаһ итеп кабул иткән империализм кешелек өчен дә, шушындый рухи халәткә төшкән милләт өчен дә зарарлы. Моның иң ачык мисалы Гитларның Алманиядә җәелдерергә тырышкан агрессив шәкел алган миллиятчелеге.

Башка бер мисал да бар, ул—бүгенге Совет Русиясенең бөтен дөнья милләтләренә карата алып барган сәясәте.[15]

Нинди дә булса бер милләт кысаларында агрессив миллиятчелек дәүләт сәясәтенең нигезенә ята башлагач ук, башка милләт һәм дәүләтләрнең моңа каршы торырга хәзерләнүе гаять тә табигый. Тарихның һәр дәверендә милләтләрне үз хакимияте астына алырга теләгән агрессив миллиятчелеккә башка милләтләр каршы торганнар һәм каршы торырга тырышканнар. Бу—үз-үзеңне саклау кануны милләтләр тормышында чагылышы булып тора.

Тарихта бөтен дөнья дәүләтләре өстеннән хаким булу сәясәте алып барган хөкемдарлар яисә дәүләтләр шактый гына күренгәләгән. Тик бүген инде милләтләрдә миллият тойгысының нык алга киткәнлеге сәбәпле, бөтен дөньяда хакимлек итү өчен үткәрелгән сәясәт нәтиҗәсез калуга хөкем ителгән. Һичкайчан теге яки бу милләт бөтен дөньяга хаким була алмаячак, чөнки кешеләрдә дә, милләтләрдә дә иң зур нәфрәт уяткан нәрсә ул—коллык.

**Искәрмәләр:**

1 Лавров. «Вперед», № 1, 1873.

2 Marx, Engels. Le manifeste communiste, Paris, 1934, edition Alfred Costes, P.91, Manifesto of communist party. New-York, International publishers. p. 28.

3 Күрергә теләмәгән берәр әйберне яки күренешне юк дип үзен-үзе ышандырырга тырышу аучыны күрергә теләмәгән тәвә кошына гына хас түгел, күрәсең. Әфлатун (Платон) кебек бөек философлар да хәтта кайбер мәсьәләләрдә шушы хәлгә төшкәннәр.

4 Leipzig, 1896.

5 Wien, 1899.

6 Emile Brehier, Histore de la philsophie, Tome II. Partie II. Ch. VI.

7 Ницшенең фәлсәфәсе хакында тагын да нигезлерәк фикер тупларга теләгәннәргә, аның, аеруча «Һумаин, троп һумаин» һәм «Ainsi parla Zarathoustra» исемле әсәрләрен укырга киңәш итәбез.

8 Бүген дә мәдәни милләтләр бер-берләреннән шактый әйберләр алалар. Тик бу үзара алыш-бирешләр милләтләрнең милли корылышын (структура) какшатырлык рәвештә түгел. Милләтләр, чит милләтләрдән алган нәрсәләрен даими рәвештә милли корылыш һәм

үзенчәлекләренә яраклаштыралар. Соңгы ике-өч гасыр эчендә инглизләр белән французлар мәдәният өлкәсендә бер-берләреннән шактый нәрсәләр алганнар, әмма бу, аларның инглиз һәм француз булып калуларына һич кенә дә киртә була алмаган, инглизлек, французлык тойгысы һәм милли аңына зыян китермәгән. Чөнки бу ике милләт бер-берләреннән алган нәрсәләрен миллиләштергәннәр.

[9] Platon, La Republique, Liv, V. II.

[10] Әфләтун ахырга таба бу фикерләреннән нигездә ваз кичкән. (Les Lois, Ch. VI)

[11] Aristote, La Politique, Liv. II. Ch. I 17.

[12] Дәүләтнең асылы һәм тарихи роле турындагы әдәбият бик бай. Бу мөһим мәсьәләләрне өйрәнеп ачыкларга теләгәннәр Г.Желлинекнең француз теленә «L'Etat moderne etson droit» дип тәрҗемә ителгән әсәрендә дәүләтнең үзенчәлегенә һәм тарихи роленә багышланган әсәрләрнең шактый бай библиографиясен таба алырлар. (Premiere partie, Chapitre III, note I.)

[13] Мәсәлән, чынлыкта зур хөрмәткә лаек булган аналык хисе деградацияләнеп, баланы бозган, аның холкында тискәре күренешләр уяткан узындыру рәвешендә калкып чыга. Шулай ук, билгеле бер дин хакимлек иткән дәүләтләрдә, яңа барлыкка килгән бер мәзһәбкә нигез салучыларны эзәрлекләүне дөрес дип тапкан рухи халәт тә дингә бәйлелек хисенең дерацияләнгән бер шәкеленнән гыйбарәт.

[14] Indroduction a la Science Sociale. Sh. IX.

[15] Бүгенге Совет Русиясенең сәясәтендә күзәтелгән яшерен бер омтылыш—ул да булса, башка милләтләрне сәяси яктан юкка чыгарып, русларның дөньяда бер хаким милләт булуына ирешү.

# IV. ТАРИХТА МИЛЛИЯТ ТОЙГЫСЫ

## 1. БОРЫНГЫ ЗАМАННАРДА ҺӘМ УРТА ГАСЫРЛАРДА МИЛЛИ ХИСНЕҢ РОЛЕ

Күп кенә Аурупа тарихчыларының әсәрләрендә, бигрәк тә XIX гасырда, еш кына кабатлана торган фикерләрнең берсе — миллиятчелек хисе гүя ки бары соңгы гасырларда гына тарала башлаган. Мондый караш тарихи күзлектән караганда да, социологиягә таянып фикер йөрткәндә дә ялгыштыр.

Миллият хисе бәшәри җәмгыятләр, милләтләрнең үзләре кебек үк искедер. Милләтне миллиятчелек яшәтә.

Милләт төшенчәсенең борынгылыгын раслау өчен Тәураттан бер мисал китерәбез: Тәуратның Сифри-Тәквин китабының X фасылында Нух пәйгамбәр улларының исемеге китерелгәннән соң түбәндәге бер җөмлә күзгә ташлана: «Төрле төбәкләрдә үзләренең телләре, ыруглары, милләтләре буенча урнашкан кавемнәр боларның торунлары (оныклары) дыр».[1]

Миллият хисе тууын X1X гасырга бәйләп карау бары Европадагы бәгъзе бәйле милләтләрдә миллият хисенең шушы гасырда яңадан җанлануы күренешен миллият хисенең гомумән барлыкка килүе дип санау нәтиҗәседер. X1X гасырда күзәтелгән миллиятчелек хисе моңа кадәр гомумән булмаган яңа бер хиснең тууы түгел, ә бәлки теге яки бу чит милләтнең хакимияте астында калган бәгъзе милләтләрнең сәяси бәйсезлекләрен яңадан үз кулларына алу өчен көрәш юлына басулары күренешедер.

Хакыйкатьтә, инде иң борынгы дәверләрдән ук кешелек тарихының асыл нигезе миллият хисе белән бәйләнгән.

Миладидан 17 гасыр элек Мисырга бәреп кергән һиксос кавеме белән Фива фиргавеннәренең озакка сузылган көрәшен, соңгы чиктә мисырлыларның һиксос хакимиятен бәреп төшереп бу чит милләтне куып чыгара алуларын мисырлылардагы миллият хисе көченнән башка һич ни белән дә аңлатып булмый.[2]

Миладидан кырык гасыр элек Гыйракта (Месопотаниядә) яшәгән туран кавемнәреннән булган шумерләр белән алардан мең ел соңрак монда килеп Гыйракның көнъяк өлешендә урнашкан семит кавемнәреннән саналган акадлар ни өчен бер-берсе белән туктаусыз көрәштеләр? Тел, культура һәм милли рух ягыннан бер-берсеннән аерылып торган бу ике ыркый көчне көрәшкә этәргән сәбәп миллият хисе вә милли аң булмыйча тагы нәрсә булсын? Бу көрәшнең сәбәбе һич тә икътисади мәнфәгатьләр өлкәсендә түгел иде. Ике төркемнең дә икътисади мәнфәгате, киресенчә, тынычлыкта яшәү белән бәйләнгән иде. Чөнки ул дәверләрдә Гыйракның туфрагы һәр ике милләт тә байлыкта йөзәрлек дәрәҗәдә ундырышлы һәм юмарт иде.[3] Шумерләр белән акадлар көрәшенең сәбәбе һәр ике милләтнең милли хисләре, берсенең икенчесе хакимияте астында яшәргә теләмәве, ягъни миллият тойгысы иде.

Шундый ук хәлне Трояльлар белән юнаннар арасындагы кискен көрәштә дә, ягъни мәшһүр Троя бәрелешендә күрәбез. Троялылар белән юнаннарның бу көрәше билгеле булганча Гомерның «Иллиада» исемле эпопиясенең эчтәлеген тәшкил итә.

Троя сугышлары заманында, ягъни миладидан 1250 ел элек юнанлыларда юнанлык тойгысының һәм аңының ни дәрәҗәдә үскән булуы хакында фикер йөртү өчен «Иллиада»ның икенче бүлегенә игътибар итү дә җитә.

Троялыларның юнаннар белән ун елга сузылган аяусыз көрәше, аларның бу көрәштә күрсәткән фидакарьлекләре, Приам белән Гектор кебек шәхесләрнең Трояны саклаудагы каһарманлыкларының чыганагы да троялыларның милли хисе, мөстәкыйль булып калуга булган ихтыярларының чагылышы түгел идемени?[4]

Тагы да соңрак, миладига кадәр 490 елда, юнаннарның Иранның бөек хөкемдары Дарийның Юнанстанга басып кергән һәм аны буйсындырырга тырышкан гаскәренә каршы торуын, аларның Мильтиад җитәкчелегендә Марафон янында иранлыларны җиңүгә ирешүләрен,[5] шушы вакыйгалардан ун ел соңрак, миладига кадәр 480 елда Ксерокс җитәкчелегендәге Иран флотының Юнанстанны диңгездән кереп яулап алырга тырышу-

ын, Фемистокол җитәкчелегендә Саламиндагы бәрелештә җиңелүгә дучар итүләрен[6] юнаннар арасында нык тамыр җәйгән миллият хисеннән, иранлыларга бәйлелеккә төшү куркынычына каршы милли гайрәтләрен җигүдән башка нәрсә белән аңлатырсың?

Иранлыларга каршы көрәш башлануга кадәр ук юнан җәмәгатьчелегендә бу көрәш өчен ныклы рухи җирлек хәзерләнгән иде. Иранлыларның Анатолиянең көнбатышындагы юнан шәһәрләрен басып алулары, бигрәк тә Милетнең, ягъни Милосның җиңелүе бөтен юнан дөньясына бик көчле тәэсир итте. Юнан шагыйрьләреннән Фрунижус[7] «Миласның җиңелуе» исемле драма да яза. Бу драмада Миласлыларның Иранлылар белән хөррият вә бәйсезлек өчен алып барган көрәше һәм сугышта җиңелүләре күңелләрне дулкынландырдай рәвештә тасвир ителгән. Юнан дөньясының бөтен шәһәр вә бистәләрендә драманы караган юнанлылар Миласлы кардәшләренең фаҗигале язмышын сәхнәдә күреп күз яше түктеләр. Бу драма тәэсирендә юнан җәмәгатьчелегендә туган рухи күтәрелеш шулкадәр көчле булды ки, бер араны драманы кую хөкүмәтләр тарафыннан таелып та торды.[8] Бу хадисә дә борынгы юнаннарда миллият хисенең ни кадәр куәтле булганлыгын ачык күрсәтә булыр.

Борынгы Рим тарихының иң мөһим чорларыннан берсе римляннарның Карфаген белән озакка сузылган сугышлары. Бу сугышлар вакытында башта римляннарның һөҗүменә карфагенлыларның каһарманларча каршы торуы, ә соныннан Ганнибал җитәкчелегендә Италияне яулап алу өчен килгән карфагенлыларга римляннарның уңышлы каршылыгы һәр ике милләтнең милли хисләреннән башка һич ничек тә аңлатыла алмый.[9]

Урта гасырларда миллият хисе күпмедер вакыт бер кадәр йомшабрак калды. Моның үзенең сәбәпләре бар: бер яктан урта гасырларда Аурупада миллият хисеннән христианлык хисе яхшы ук өстенлек ала; бөтен христиан кавемнәре дә үзләрен киң таралыш алган христиан җәмгыятенең аерылгысыз бер кисәкчәсе итеп күз алдына китерәләр. Ә икенче яктан Аурупаның инде милләт буларак формалашып өлгергән кавемнәренең җирләренә башта герман, ә соңыннан норман

кавемнәре үтеп керәләр. Бу урыннарда (Франция, Англиядә, Италиядә) яңа утырган германнар белән иске милләтләрнең кушылуы нәтиҗәсендә элекеге милли рух йөмшара һәм хәтта юкка да чыга. Урта гасырларның башында бу өлкәләрдә яңа милләтләр әле формалашып өлгермәгәннәр, бары формалашу чоры гына кичерә иделәр. Англиядәге халыкта «британияле»-лек хисе туганчы, монда башта саксониялек хисенең өстенлек алуы, норманнарның килүе, аларның көч белән хакимиятне үз кулларына алулары, саксоннар белән норманнарның катнашуы, каршылыклы үзара тәэсирләр нәтиҗәсендә шул ике кавем нигезледә яңа бер инглиз милләтенең барлыкка килүе вә инглиз тойгысының тууы кирәк иде. Ә моның өчен үз чиратында күп вакытлар үтү кирәк булды. Икенче тарафта, Франциядә, галлар белән римляннарның катнашмасыннан барлыкка килгән галл-роман милләте белән Франциягә килеп урнашкан герман элементларын (франкларның, бургундларның, вистготтларның) берләшүе нәтиҗәсендә француз милләтенең мәйданга чыгуы өчен дә, әлбәттә, күп заман үтәргә тиеш иде.

Инглиз милләте белән француз милләте яңа милләтләр булып оешып та җитмәделәр бу ике милләт арасында миллият хисе тәэсирендә көндәшлек тамыр җәйде һәм алар арасында аяусыз көрәш башланды. Инглизләр белән французлар арасында йөз елга сузылган сугыш ике милли хиснең бәрелешеннән башка һич ни дә түгел иде. Бу каршылык унбишенче гасырның беренче яртысында бик кискен төс алды. Ниһаять, Франция короле Карл VII заманында (1422—1461) французлар үз җирләрен басып алган инглизләрне җиңделәр һәм мәмләкәтләреннән чигенергә мәҗбүр иттеләр.[10] Бу чорда французларның инглизләрне үз җирләреннән куып чыгару өчен көрәшкә бердәм ташлануын һәм бу юлда күрсәткән фидакарьлекләрен француз милләтенең милли хисенең куәтле бер күренешеннән башка бер ни дә булмаганлыгы хакыкый бер нәрсәдер. Бу вакытта французларның рухларында чын мәгънәсендәге милли хис хакимлек иткәнлеген раслау өчен бу халыкның бөек кызы Жанна д'Арк этәргәч биргән милли хәрәкәтнең тәэсирен әйтеп үтү дә җитә.[11]

Христиан дөньясында хакимлек иткән дини хис ислам дөньясында да шул ук рәвештә тамыр җәйгән иде. Урта шәрекъта, исламият таралганнан соң, мөселманлык тойгысы күпмедер бер вакыт милли хисне онытгырган кебек тә күренде: гарәпме ул, төрекме һәр кайсы үзләрен беренче чиратта «мөселман», дип, ә бөтен ислам милләтләре үзләрен Азия, Африка һәм Европаның бер өлешенә таралган ислам җәмгыятенең аерылгысыз өлеше дип саный башладылар. Шулай да бу хәл озакка сузылмады: инде үлгән үк кебек тоелган, әмма оеп кына калган милли хис ислам дөньясында да милади буенча унберенче гасырдан үк яңадан уяну чоры кичерә башлады. Иранлыларда да, төркиләрдә дә милли хис белән сугарылган шагыйрьләр һәм язучылар[12] калкып чыгу белән бергә Багдад хәлифәлегенә бәйлелекләре яхшы ук йомшарган байтак кына милли дәүләтләр дә барлыкка килде.

## 2. ЯҢА ЗАМАНДА МИЛЛИ ХИС

Унтугызынчы гасыр бәйсезлеген яки милли бердәмлеген югалткан милләтләрдә миллият тойгысының яңадан да җанланып киткән дәвере. 1815 елда җыйналган Вена Конгрессының «миллият» мәсьәләсенә теоретик яктан игътибар итмичә, бары Аурупа дәүләтләре хакында чыгарылган карарлары аркасында, 1820 белән 1878 еллар арасында бөтен Аурупада «миллият» идеясе файдасына куәтле бер фикри пропаганда һәм хәрәкәт күзгә ташланды.

Бу дәвердә Италиядә, шушындый агымның башында Италияне берләштерү өчен көрәш идеясе күтәргән һәм «Яшь Италия» исемендә җәмгыять төзегән Жозеф Мадзини (1805—1872) торды.[13] Мадзини бүленгәләп беткән Италияне берләштерү өчен генә түгел, ә бәлки Аурупаның бөтен изелгән милләтләренең бәйсезлеге өчен дә көрәште. Мадзини нигезен салган бу агым бәйсезлеген югалткан бөтен милләтләрнең идеализм белән канатланган бөтен яшьләренә гаять тирән тәэсир ясады. Милли һәм сәяси бәйсезлеген яки бердәмлеген югалткан милләтләрнең барча милләтче яшьләре берләшеп, «Яшь Аурупа» исеме астында милләтләренең хөррияте, бәйсез-

леге һәм бердәмлеге өчен көрәшкән һәм бөтен Аурупаны колачлаган җәмгыять оештырдылар. Бу җәмгыять өчен «Яшь Италия» һәм башка «Яшь Алмания», «Яшь Польша», «Яшь Мадьяристан (Венгрия)» кебек бүлекләр дә төзелде. Башында Мадзини торган «Яшь Аурупа» җәмгыятенең эшчәнлеген һәм яшәешен тәэмин иткән миллиятчелек — ул рациональ бер миллиятчелек иде. Менә шушы чорларда миллият идеясе җитәкче бер принцип һәм бер доктрина буларак формалашты да. Тарихның башыннан бирле яшәп килгән миллият тойгысының чыганагы шул рәвешчә ачыкланды.

Милләтләрдә милли хиснең бу уянышы һәм милли аңның куәтләнүе нәтиҗәсендә кечкенә дәүләтләргә бүленгән зур милләтләр бердәнбер дәүләт эчендә берләшү өчен көрәшкә тотындылар. Парчаланган Италиянең һәм кечкенә дәүләтләргә бүленгән Германиянең өлешләре берләште һәм бу ике милләт һәрберсе үз-үзенә бер зур дәүләт төзеделәр.[14]

Әйтелгәннәр таркалган бүлгәләнгән милләтләрдә милли бердәмлек хисенең беркайчан да бөтенләй юкка чыкмавы турында сөйлиләр. Шушы миллият хисе аркасында 1831 елны сәясәт мәйданыннан юкка чыккан[15] поляк милләте яңадан да мөстәкыйль бер милләт булып яши башлады.[16] Шушы миллиятчелек хисе һәм милли үзаңның көчле тәэсире аркасында Австриянең мең еллык династиясе җимерелде һәм бу династия хакимияте астында яшәгән чехлар һәм словаклар сәяси бәйсезлекләренә ирештеләр.[17] Миллият хисе дип аталган рухи көчнең каршылык күрсәтүе нәтиҗәсендә гасырлар дәвамында үзбилгеләнү өчен көрәшкән ирландиялеләрнең бер төркеме инглиз хакимиятен тетрәндерүгә иреште.[18] Шул ук көчнең тәэсире аркасында Индонезия милләтләре Голландия хакимиятеннән, Һиндстан белән Пакистан инглиз хакимиятеннән котыла алдылар. Милләтләрне яшәткән, җанландырган миллият аңының тәэсире аркасында бүген Төньяк Африканың Франциягә буйсынып яшәгән милләтләре француз хакимиятеннән котылу һәм мөстәкыйль бер милләт булыр өчен көрәшәләр.[19] Соңгы утыз ел эчендә озак вакытлар рус патшаларының золымы астында яшәп килгән шактый милләтләр—литвалылар, латышлар, эстон-

нар, әзәрбәйҗан төркиләре, грузиннар үзләренең бәйсезлекләре өчен көрәш алып баралар.[20]

Бүген советларның, ягъни русларның идарәсе астында булган бөтен милләтләр, украинаылар, Төркстан төркиләре, Идел-Урал төркиләре һәм төньяк Кавказ милләтләре бәйсезлекләренә ирешү теләге белән яшиләр.

## 3. ӘСИР МИЛЛӘТЛӘРНЕҢ УЯНУЫ

Теге яки бу милләттә миллият тойгысының көче һәм тирәнлеге ул милләтнең үз тарихы һәм мәдәнияте хакындагы белеменә тыгыз бәйләнгән. Борынгы тарихларын һәм мәдәни ядкәрләрен оныткан милләтләр әкренләп-әкренләп миллият аңын да югалта баралар. Шуңа күрә яшәү кодрәтенә ия булган милләтләр тарихларының чәчәк аткан дәверләрендәге мөһим вакыйгаларны онытмау, боларны милләтнең хәтерендә яшәвен тәэмин итү өчен төрле чаралар күтәргәннәр: һәйкәлләр куйганнар, кабер ташлары яздырганнар, елъязмаларда милләтнең тормышында булган мөһим вакыйгаларны теркәгәннәр. Шуның өстенә милләтнең шагыйрьләре дастаннар иҗат иткәннәр, чәчәннәре бу дастаннарны җыеннарда укып милләтне йә сөендергәннәр һәм дулкынландырганнар, йә елатканнар.

Кайбер милләтләр исә чит бер милләткә күпмедер буйсынып яшәгәннән соң, акрынлап телләрен һәм милли мәдәниятләрен онытканнар һәм шуның нәтиҗәсендә милли хис һәм аңнарын да югалтканнар. Ягъни, үзләре буйсынган милләт эчендә эретелгәннәр. Шул рәвештә эрегән милләтләрнең мисалы итеп, Рим мәдәнияте барлыкка килгән дәверләрдә зур роль уйнаган, шул дәвернең югары мәдәни милләтләреннән булган этрусклар[21] белән миладига кадәр VI гасырда көнбатыш Анатолиядә иң бай һәм иң көчле милләт булып саналган лидиялләрне күрсәтә алабыз. Бу ике милләт сәяси бәйсезлекләре белән үзләренең барлыкларын да мәңгегә югалтканнар.

Шул ук вакыт, милли хисләре һәм аңнары көчле булган кайбер милләтләр, милли һәм сәяси бәйсезлекләрен югалтканнан соң да, кайчакта гасырлар дәвамында чит милләтләрнең басымы астында яшәгән хәлдә дә, миллиятләрен онытмаганнар,

милли аңнарын югалтмаганнар. Кайберләре хәтта телләрен онытткан тәкъдирдә дә, милли рухларын һәм милли холыкларын саклап калганнар һәм моның нәтиҗәсендә милли бәйсезлекләрен дә яңадан яулап алуга ирешкәннәр.

Сәяси бәйсезлеген югалткач әкренләп миллиятен дә югалту куркынычы астында калган теге яки бу милләтнең милли хисенең яңадан да җанлануында нинди факторлар роль уйный ала?

Болар—милли телдә сөйләнә һәм языла торган милли әдәбият, милли тарих һәм гомумән милли культура әсәрләре. Ә чынлыкта шушы әмәлләр, шушы калыплар һәм кабыклар эчендә сакланган милли рух.

Милләтләрнең милли аңы аерым шәхесләрнең рухына йомшаклык гамәлләре күрсәтсә дә, милләтнең мәкальләрендә, шигырь, хикәя һәм мәсәлләрендә, милли җырларында, милли дастан һәм риваятьләрендә, әдәби һәм тарихи әсәрләрдә мәңге яшәр.

Теле һәм милли культурасы чәчәк ату дәверен кичергән милләтләргә миллиятне бөтенләй югалту, юкка чыгу куркынычы заруратттән түгел.

Үзен әсир иткән дәүләтнең мәрхәмәтсез ассимиляцияләү сәясәтенә эләккән борынгы бер милләтнең милли-мәдәни әсәрләре заман һәм хаким милләт тарафыннан юкка чыгарылудан котыла алган икән, димәк, ул милләтнең рухы да саклана алган.

Бу рухның яңадан мәйданга килүе һәрвакыт мөмкин. Тарихта без моның бик күп мисалларын да күрәбез.

Алдагы бүлекләрдә миллият тойгысының тиңе булмаган бер көч булуын ачык итеп күрсәтү өчен, бәйсезлеген югалтып, әкренләп миллиятен дә оныту сукмагына кергән кебек күренгән милләтләрнең кайберләренең «яңадан туулары» тарихына күз ташларбыз.

## 4. ЧЕХЛАРНЫҢ МИЛЛИ УЯНЫШЫ

Урта гасырлардан бирле чехлар югары культуралы милләт иделәр. XI гасырның башларында чех телендә әсәрләр дә күренә башлый. Беренче әсәрләр дини эчтәлектә була. XIV

гасырда исә дөньяви әсәрләр дә языла башлый. Чех телендә язылган беренче мөһим әдәби әсәр булган «Далимил тарихы»[22] миллият тойгысы белән сугарылган әдәби һәм тарихи әсәр.

Чехлар үз тарихларының башыннан ук алман милләте белән көрәш алып барган бер милләт иде. Чехларның милли омтылышы — ватаннарын алман буйсындыруыннан коткару, сәяси мөстәкыйльлекне саклау була. «Далимил тарихы» менә шушы омтылышларны чагылдырган әсәр иде.

«Далимил тарихы»ннан соң чех телендә тирән милли рух белән сугарылган әдәбият туа. Чех телендә язылган бу әдәбият XIV гасырның башларыннан XVII гасырга кадәр һаман үсә бара. XVI гасыр ахырларында чех милләте инде югары үсеш алган әдәби телгә һәм милли әдәбиятка ия була.

Мәшһүр алман дин реформаторы Мартин Лютердан да элегрәк, католик диненә ислахат (реформа) үткәрүдәге эшчәнлеге өчен, Констанс шәһәрендә 1414 елда оештырылган католик руханилары Югары җыелышы тарафыннан терелләй яндырылып җәзага тартылган Жан Гусс (1373—1415) чех милләтеннән иде. Шул ук вакытта бу дини көрәшче чех миллиятчесе дә иде. Беренче булып чех теленең имля һәм грамматика кагыйдәләрен билгеләүче дә Жан Гусс була. Гусстан соң, XVI гасырдан башлап, чех милләте һәр өлкәдә күп кенә күренекле шәхесләр җитештерә: чех милләте тарихын язган Вацлав Гаек кебек тарихчылар, Хелциски кебек мөтәфәккирләр шулар җөмләсеннән. Шул ук гасырларда төрле өлкәләрдә иҗат итүче язучылар да өлгерә. Соңгыларының арасында иң мәшһүре Велеславин була.

XY һәм XYI гасырларда чехлар мәдәниятнең башка өлкәләрендә дә искиткеч дәрәҗәдә алга китәләр. XYI гасырда Прагада ачылган университет — Аурупаның иң борынгы университеты. Чех милләте XYII гасырга таба Аурупаның мәдәнияттә иң алга киткән милләтләренең берсе. Хәлбуки, бу милләт ул заманнарда бөтенләй үк мөстәкыйль дә түгел иде. Чехларның ватаны булган Богемия[23] XI гасырдан алып Алмания императорлыгына керә һәм кечкенә бер корольлек тәшкил итә. Ә ил эчендәге эшләрдә исә киң хөррият һәм мохтарияткә ия була.

1617 елда Габсбурглар династиясеннән булган Австрия короле Фердинанд II бер үк вакытта Богемия короле дип тә игълан ителә һәм ике елдан соң Алмания императоры итеп сайлана. Протестантлыкның рәхимсез дошманы булган Фердинанд II үзенә караган өлкәләрнең халкын католиклыкны кабул иттерү эшенә керешә.

Инде күптәннән протестантлык мәзһәбен кабул иткән чехлар корольләре дип танылган Палатина принцы Фредерих Y җитәкчелегендә Фердинанд II гә каршы баш күтәрәләр.

1620 елда Белагора дип аталган урында Алмания императоры Фердинанд гаскәре белән чех гаскәрләре арасында көчле бәрелеш була һәм чехлар җиңелүгә дучар ителәләр.

Чех өлкәсен басып алып буйсындырылган алманнар чех милләтенең бөтен аксөяк һәм зыялы катламын юкка чыгаралар. Алар халыкны католик динен кабул итәргә мәҗбүр итеп кенә калмыйча, чех милләтенең телен, милли мәдәниятен дә юк итү нияте белән, чех телендәге бөтен китапларны һәм китапханәләрне яндыралар. Бу золым һәм изү нәтиҗәсендә кырык меңләп чех зыялысы ватаннарын калдырып китәргә мәҗбүр була.[24]

Шулай итеп, Белагорадагы җиңелү чех милләте өчен кайсы яктан гына караганда да бер һәлакәт һәм әсирлек дәверенең башы була. Моннан соң Австрия хөкүмәте җир эшкәртүчеләрдән генә гыйбарәт булып калган чех милләтенә карата эзлекле рәвештә алманлаштыру сәясәте үткәрә башлый. Рәсми тел немец теле булу белән бергә, укыту-тәрбия дә немец телендә генә алып барыла башлый. Хәтта чех телендә әсәр иҗат итү дә тыела.

Бу сәясәт нәтиҗәсендә шәһәрләрдә яшәүче чехлар тора-бара алманлашалар, алман телендә генә сөйләшә башлыйлар. Католик динен кабул иткән аксөякләр сыйныфы чех милләтеннән булуларын инкяр итә, чехча белмәүләре белән горурлана башлыйлар. Аксөякләр сыйныфына караганнарының бер өлеше алман исемнәренә охшату өчен фамилияләрен дә үзгәртәләр. Чех теле акрынлап бары тик шәһәрләрдән еракта урнашкан авылларда, авыл теле буларак кына кулланышта кала. Авыл халкының теленә дә бик күп алман сүзләре үтеп керә.

Кыскасы, чех милләте үз миллиятен югалту юлыннан кызу адымнар белән хәрәкәт итә.

XIX гасырга кергәндә, алманнар чехларны тәмам алманлашкан дип саныйлар һәм аларны милли киләчәкләре булмаган, юкка чыгуга хөкем ителгән бичара бер милләтнең калдыклары дип кабул итәләр. Хакыйкаттән, чех милләте бары тик тарих битләрендә генә исеме калган милләтләр хәленә төшкән кебек күренә иде.

Әмма бу бары тик тышкы күренеш кенә булып, чех милләтенең милли рухы үлмәгән, ул фәкать яшеренгән генә булган. Көннәрдән бер көнне бу милли рухның калкып чыгачагы, яңадан бер көчкә әйләнәчәге шик тудырмый иде. Чөнки китап басу барлыкка килгәннән соң, ягъни милләтләрнең милли мәдәният әсәрләрен күбәйтү һәм җәелдерү мөмкинлекләре туганнан соң, милли мәдәнияте булган бер милләтнең киләчәктә юкка чыгарылуы мөмкин булмый башлый.

XIX гасырда чех милләтендә көчле бер милли уяныш хәрәкәте башлана. Алманлашкан дип саналган, асылда чех булып калган зыялылар арасында чех мәдәниятен яңадан җанландыру һәм чех милләтен кабаттан мөстәкыйль бер милләт хәленә китерү теләге һәм омтылышы туа. Бу максатка ирешү өчен барыннан да элек үлә барган милли телне терелтү һәм милләтнең шанлы тарихын милләткә үз телендә аңлату кирәк иде. Чех зыялылары барысыннан да элек милли рухны торгызу зарури булуын, бу милли рухны исә милләтнең мәдәни әсәрләрендә сакланган булуын яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә, акыл һәм ихтыяр көчләрен эшкә җигеп, милли мәдәниятләрен яңадан күтәрү эшенә керешәләр.

Добровский славян телләренең этимологик сүзлеген төзи һәм «Славника» исемле бер җыентык нәшер итә башлый. Йунгман чех теленең сүз байлыгын туплый. Целаковский исемле шагыйрь, славян милләтләренең халык әдәбиятын һәм славян кавемнәренең мәкальләрен өйрәнеп, «Славян фәлсәфәсе» исемле бер әсәр нәшер итә. Коллар «Славян кавемнәренең телләре арасындагы мөнәсәбәтләр» исемле бер китап яза. Моннан тыш ул «Славян кызы» исеме белән танылган яңа

бер дастан мәйданга чыгара. Бу әсәр бөтен славян кабиләләрендә ыркый хиснең (славянлык хисенең) уянуында мөһим роль уйный. Бер яктан, язучылар һәм шагыйрьләр телне һәм милли әдәбиятны яңадан торгызу өчен тырышсалар, икенче яктан, бер төркем миллиятче зыялылар чех милләтенең тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә башлар. Шаффарк чех телендә «Славян антикасы» һәм «Славян этнографиясе» исемендә зур әһәмияткә ия булган ике әсәр язып бастыра. Чехларның милли уянышында аларның тарихчысы Вацлав Томекның хезмәтләре дә зур роль уйный.[25]

Югарыда исемнәре телгә алынган язучы, шагыйрь, галим һәм тарихчыларның әсәрләре тәэсирендә аталары тәмам алманлашкан яшь буын чех зыялыларының күбесе борынгы милли әсәрләрне укый башлыйлар. Француз революциясеннән соң бөтен Аурупада барлыкка килгән нисби фикер (фикер төрлелеге) һәм матбугат хөррияте тәэсирендә чехлар да борынгы милли әсәрләрен бастырып, халык арасында җәелүе һәм миллиятче зыялыларның эшчәнлеге йогынтысында чех халкының йокыга талган милли хисе, миллият тойгысы уяна һәм кайный башлый. Бу әдәби һәм мәдәни миллиятчелек озак та үтми сәяси миллиятчелек рәвешен ала. Миллиятче чех депутатлар чехларның сәяси бәйсезлеккә таба хәрәкәт итүен тәэмин итәрдәй кануннар кабул итәргә тырышалар. Законнар чыгару буенча үткәрелгән бу эшчәнлек нәтиҗәсендә чех өлкәсенең милли мохтарияте акрынлап киңәя бара.

Ниһаять, Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң, бөек галим һәм миллиятче Масарик һәм аның иптәшләренең бөтен чех милләтендә яклау тапкан сәяси эшчәнлеге нәтиҗәсендә, чех милләте тулы бәйсезлеккә иреште. Чехлар үзләренә тел һәм гореф-гадәтләр ягыннан бик якын булган словак кавеме белән берләшеп, мөстәкыйль Чехословакия дәүләтен төзи алдылар.[26]

Чех милләтенең уяну тарихы — милли тойгының, акыл һәм ихтыяр көчен эшкә җиккән милли хәрәкәтнең ничек итеп могҗизалар барлыкка китерә алуын исбат итүче мисалларның берсе.

## 5. ФИННАРНЫҢ МИЛЛИ УЯНЫШЫ

Беренче бөтендөнья сугышыннан соң мөстәкыйль дәүләт төзү мөмкинлеге алган милләтләрнең берсе — финнар булдылар. Бу милләтнең милли уянышы, онытылган мәдәни мирасларын өйрәнү-тикшеренүләре белән бәйләнгән.

XIX гасырга кадәр Финляндия Швеция дәүләтенең бер вилаяте була. Ил эчендә күпчелекне тәшкил итсәләр дә, финнар Финляндиядә азчылык булган шведларга буйсындырылган хәлдә яшиләр. Нигездә, мәдәнияттән мәхрүм калган авыл кешеләреннән торган фин кавеме XVII гасырга кадәр, турысы белән әйткәндә, язусыз, китапсыз, җаһиль бер милләт була. Әмма XVI гасырда финнар арасында дини сәбәпләр аркасында милли хис уяна башлый. Алман дин реформаторы Лютерның дини ислахаты төньяк Аурупа өлкәләрендә зур яңгыраш таба. Аның, шулай ук, Инҗилне алманчага тәрҗемә итүе дә бөтен төньяк Аурупа өлкәләрендәге алман булмаган милләтләрнең алдынгы карашлы руханиларында, дини реформаторлык идеяләрен җәелдерү өчен, Инҗилне милли телләргә тәрҗемә итү фикерен уята. Фин милләтенең алдынгы карашлы руханиларыннан берсе—Або епископы Михель Агрикола Инҗилне фин теленә тәрҗемә итәргә карар кыла. Моны башкарып чыгу өчен, ул иң башта фин теленә яраклаштырылган бер алфавит төзи. Инҗил тәрҗемәсе фин телендә язылган тәүге китап була. Моннан соң Агрикола фин телендә бер дини кагыйдәләр җыентыгы (Катехизис) һәм дини җырлар да яза. Агриколадан соң дини шигырьләр язган башка шагыйрьләр дә күренә башлый. XVII гасырда христианнарның бөтен дини китаплары (Библия) фин теленә тәрҗемә ителә. Шул рәвешле XVII гасырга кадәр фин телендә бары тик дини әсәрләр генә нәшер ителә. Фин теле әлегә мәдәният теле дәрәҗәсенә үк күтәрелмәгән була. XVIII гасыр ахырында Або университеты профессоры Генрих Фортһан үз тирәсенә идеалист яшьләрне туплап, алар белән корган озын әңгәмәләрендә фин халкының мәдәни яктан артта калганлыгы, милләтне алдынгы культуралы милләт дәрәҗәсенә күтәрү өчен хезмәт итү — фин зыялыларының изге бурычы

булуы турында сөйли. Фин, милләтен мәдәни яктан үстерү, алга җибәрү өчен барыннан да элек бер әдәби тел барлыкка китерү кирәклеген аңлата. Әдәби вә мәдәни тел тудыру өчен исә, иң башта, фин халкының сөйләм телен, халык шигырьләрен, әкиятләрен, мәкаль һәм әйтемнәрен, милли телдәге риваятьләрне, кыскасы, милләтнең барлык, авыз иҗаты байлыгын туплап өйрәнү кирәклеген аңлата һәм исбат итә.[27] Фортһанның үгетләре фин яшьләренә тәэсирсез калмый һәм аларның йокыга талган милли тойгылары уяна. Шактый гына яшьләр фин милләтенең теле һәм борынгы мәдәни мирасы өлкәсендә эзләнү-өйрәнү эшләрен башлыйлар. Әмма Финляндия Швециягә буйсынган хәлдә калганга, Швеция хөкүмәте дә, швед зыялылары да фин халкының милли тойгысы уянуын һәм фин телендә әдәбият барлыкка килүен теләмиләр.

1809 елда Финляндия Русия патшасы Александр I хакимияте астына эләгә. Тик Финляндия белән Русия арасындагы мөнәсәбәт бер хөкемдарга бәйле булудан гына гыйбарәт була.[28] Александр I дә, аннан соң килгән рус патшалары да, Финляндиядә элек хакимлек иткән шведларга бик ышанып бетмәүләре сәбәпле, мәмләкәттә күпчелекне тәшкил иткән һәм күбесенчә авыл кешеләреннән торган фин милләтенә таянуны кулайрак күрделәр. Шунлыктан алар фин милләтенең милли уяныш хәрәкәтенә карата түзеп тору юлын сайлыйлар.

XIX гасыр башларында университетта югары белем алган финнар арасында милли телләрен фин телендә шигырь язар дәрәҗәдә яхшы белгән шагыйрьләр барлыкка килә. Тик, Финляндия рус патшалары кулына төшкәннән соң да, чынбарлыкта өлкә белән шведлар идарә итәләр. Мәктәпләрдә укыту теле — швед теле. Дәүләт һәм мәхкәмә (суд) теле булып та швед теле кала. Финнәрнең өлкә белән идарә итүдә рольләре булмый. Шушы шартларда миллиятче яшьләр, фин халкына да өлкә белән идарә итүдә урын бирелүен, фин балалары укый торган мәктәпләрдә укытуның фин телендә алып барылуын, мәхкәмәләрдә фин теленең дә кулланылуын таләп итә башлыйлар. 1820 елда Абода, беренче тапкыр буларак, фин телен

һәм фин халык әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өчен кафедра оештырыла. Бу кафедра эшчәнлеге нәтиҗәсендә финнар арасында милләтен алга җибәрү идеалына бирелгән яшьләрнең саны арта бара. Шведлашкан гаиләләрдә үскәнгә күрә фин телен яхшы белмәгән яшьләр арасында милли хиснең уянуына иң күп хезмәт иткән кеше Людвиг Рунеберг була. Рунеберг, ике яшь миллиятче Леоннрот һәм Снеллман белән берлектә, фин әдәбияты җәмгыятен оештыра. Җәмгыятьнең максаты фин халык әдәбиятын, фин телендәге борынгы мәдәният истәлекләрен, фин теленең сүз байлыгын җыю һәм бергә туплау була. Бу омтылыш һәм хәрәкәтләрнең төп максаты фин әдәби телен барлыкка китерүгә кайтып кала. Фин әдәби телен барлыкка китерүгә иң зур өлеш керткән кеше— Леоннрот булган.

Леоннрот халык телен нигезле рәвештә өйрәнү өчен озак вакытлар халык арасында, авылда яши, халык авыз иҗатының бөтен хәзинәләрен туплый һәм аларны һәрьяклап өйрәнә. Бу тикшерү эшләренә керешкәнче, башка милләтләрдә әдәби телнең барлыкка килүе тарихын һәм ысулларын өйрәнгән Леоннрот, халык арасында авыз иҗаты әсәрләрен җыйганда, көтелмәгән бер хәзинәгә тап була. Яшь филолог, Финляндиянең төрле вилаятьләрендә һәм төрле шәкелләрдә сөйләнгән һәм халыкның ерак үткәне турында сүз барган шигырь кисәкләренең хакыйкатьтә бер бөтен тәшкил иткән дастаннан өзекләре булуын ачыклый. Леоннротның бу ачышы нәтиҗәсендә фин милләтенең борынгы тарихына караган мөһим вакыйгалар хакында сөйләүче милли дастан терелә. Бу дастан Леоннротка финнәрнең кайчандыр бөек, шанлы бер милләт булганнарын исбат итә. Леоннрот бу дастан кисәкләрен «матди хәзинә» итеп күреп, зур кызыксыну һәм сөенеч белән туплый һәм тәртипкә китерә. Халык шагыйрьләре тарафыннан мәгънәсен аңламыйча кулланып килингән сүз һәм җөмләләрнең мәгънәләрен ачыклый һәм аңлатып бирә. Ул бу милли дастанны «Калевала» исеме белән нәшер итә (1835). «Калевала»ның табылуы һәм басылып чыгуы бөтен фин милләтенә көчле тәэсир ясый. «Калевала»ны укыган һәр фин кешесе

үзенең ерак үткән заманда бөек, шанлы һәм мөстәкыйль булган бер милләт баласы булуын хис итеп, чиксез шатлык һәм милли горурлык тоя һәм нәтиҗәдә, аның үзенең дә, милләтенең дә киләчәгенә ышанычы арта.

Бу дастан финнарның рухларында киләчәкләренә карата да бөек өметләр уята.

Шулай итеп, фин милләтенең милли уянышы һәм мәдәни үсеше тарихында «Калевала»ның нәшер ителүе мөһим бер вакыйга була.[29] Леоннрот бу дастаннан тыш тагын башка шигырьләрне дә туплап, «Кантелетар» исеме белән халык әкиятләрен, хикәяләрен, мәкальләрен, табышмакларын, мәҗүсилек дәвереннән калган дини әдәбиятны да туплый. Леоннрот туплаган «Халык әдәбияты» хәзинәсе тел галимнәре өчен зур бер тикшеренү темасына әйләнә. Бу әдәби «хәзинә» бер яктан гыйльми һәм тарихи яссылыкта өйрәнелсә, икенче яктан, андагы сүз байлыгы нигез буларак алынып, фин галимнәре тарафыннан милли телдә фәнни терминнар эшләнелә башлый. Финнар арасында Кастрен кебек бөек тел галимнәре үсеп чыга. Кастрен 1841 елда «Суоми» (Финляндия) дип аталган бер журнал чыгара башлый. Бу журнал битләрендә беренче буларак бары тик финча терминнар гына кулланып язылган мәкаләләр басыла. «Фин әдәбияты җәмгыяте» халык өчен язылган, халык телендә иҗат ителгән әсәрләр нәшер итә.

Әмма фин милләтенең һәр яктан гаҗәеп дәрәҗәдә үсә башлавы рус хөкүмәтен борчуга сала. 1850 елда рус патшасы фин телендә дини китаплардан башка китаплар басуны тыеп фәрман чыгара. Әмма берничә елдан соң ул бу фәрманын юкка чыгарырга мәҗбүр була. Фәрман чыгар-чыкмас, фин телендә бик күп яңа әсәрләр нәшер ителә. 1872 елда Финляндиядә бары тик фин телендә язылган пьесаларны гына сәхнәгә кую максаты белән бер театр ачыла. Театрны оештырган Бергбом үзе дә фин телендә берничә сәхнә әсәре иҗат иткән.

Оксанен исемле бер мөхәррир «Очкын» исеме белән лирик шигырьләр нәшер итә. Шул ук елларда, илһам чыганакларын

киңәйтү, баету өчен бөек милләтләрнең мәшһүр классик әсәрләрен фин теленә тәрҗемә итү кирәклеген аңлаган зыялылар барлыкка килә. Пауль Каяндер Шекспир әсәрләрен тәрҗемә итә. Кыска гына арада шактый ук шагыйрьләр, язучылар, тәрҗемәчеләр җитешәләр, һәммәсе дә күпмедер дәрәҗәдә инде эшләнгән һәм эшләнүе дәвам иткән милли әдәби телдә язалар. Яңа фин әдәбияты башыннан ахырынача, миллиятчән һәм халыкчан була. Язучылар темаларын халык тормышыннан алалар, сурәтләүләрдә бары тик фин сүзләрен һәм терминнарын гына куллануны милләткә тугърылык бурычлары итеп санийлар. Фин язучылары гаять дәрәҗәдә акыллы һәм кайнар миллиятчелекне бәшәрияткә һәм бөтен милләтләргә карата хөрмәт һәм мәрхәмәт хисе белән берләштерү юлларын да беләләр. Фин әдәбияты миллиятчән, халыкчан булуы белән бергә бәшәриятче дә. Бүген финнарның үз телләрендә иҗат ителгән бай әдәбиятлары бар. Финнәр дә чит тел алынмаларыннан арынырга тырышу башка милләтләрдәге мондый омтылышлардан да көчлерәк була. Финнәр «телефон» кебек сүзләр урынына да фин телендәге исемнәр уйлап тапканнар.[30]

Моннан 150 еллар элек сәяси бәйсезлектән мәхрүм ителеп телен оныткан авыл кешеләреннән гыйбарәт булган фин милләте бүген сәяси яктан мөстәкыйль мәдәнияте дә Аурупаның башка мәдәни милләтләре дәрәҗәсенә ирешкән.

Бу могҗиза миллият тойгысының уянуы вә милләтчелекнең милләтләрне үсәргә, алга таба хәрәкәт итәргә этәргән сихерле көче тәэсирендә барлыкка килгән. Милли идеалларга бәйле булган һәм карашы югары үрләргә төбәлгән милләт өчен ирешә алмастай биеклекләр була алмый.

## 6. ЯҺҮДИЛӘРДӘ МИЛЛИ ТОЙГЫНЫН ИКЕ МЕҢ ЕЛ БУЕ УЯУЛЫКТА БУЛУЫ

Миллият тойгысының вә милли аңның милләтләрнең рухи тормышында бик тирән тамырлары булган, нәселчәнлек юлы белән буыннан—буынга күчеп килгән, үлмәгән, сүнмәгән бер тойгы булганын исбат иткән күренешләрнең берсе, күзебез-

нең алдында торган, Палестинада Израиль дәүләтенә нигез салынудыр.

Яһүди милләтенең милли вә сәяси уянуының вә җанлануның әсаси гамәлләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Миллият тойгысының куәте.

2. Бәйсезлек дәвереннән бирле милли телдәге әдәбиятның яшәве.

Яһүдиләр тарихын ике дәвергә аерырга мөмкин:

1. Легендар дәвер.

2. Тарихи дәвер.

Беренче дәвернең бөек шәхесе Ибраһим пәйгәмбәрдер.[31]

Яһүдиләрдә яшәгән риваятьләргә караганда Ибраһим гәләйһиәссәләм яһүди милләтенең атасыдыр. Бу дәвернең башка күренекле шәхесләре, Ибраһим пәйгәмбәрнең уллары Исмәгыйль вә Исхак.

Ислам дине голәмәсе тарафыннан да пәйгәмбәр буларак танылган бу шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре пәйгамбәрләр тарихында яктыртылганлыгы мәгълүмдер.

Яһүдиләрнең борынгы тарихының күзаллана торган дәвере Йакуб пәйгамбәрдән башлана. Йакуб пәйгамбәр Мисырда җирләшкән иде. Йакубның токымнары заманы белән үрчеп, Мисырда аерым бер төркем тәшкил иттеләр. Мисырлылар яһүдиләрне әсирләр итеп санаганнар вә коллардай эшләткәннәр. Яһүдиләрнең Мисырда татыган җәбер-залымнары Тәүрәтнең Sifrul-Huruc (Exode) — «Сәфәргә чыгу» исемле китабында тәфсилле сурәттә хикәяләнә. Яһүдиләр Мисырда коллык хәлендә яшәгәннән соң, Муса пәйгәмбәрнең җитәкчелегендә «аннан чыгуга» ирештеләр.[32]

Яһүдиләр, Мисырдан чыкканнан соң, озак вакытлар Палестинада кабиләләр хәлендә яшәделәр. Бу кабиләләр үз араларыннан бер король сайларга карар бирделәр вә Саул атлы бер җитәкчене король иттереп куйдылар. Ягъни, мөстакыйль Яһүди дәвләтен кордылар. Саул (б.э.к. 1055—1033) дан соң Яһүди дәүләтенең башына Дауд (1033—993) пәйгәмбәр килде. Изге китаплардан булган Зәбур (Псаломнар) Даудка килгән. Даудтан соң Сөләйман пәйгәмбәр (993—935) тәхеткә килде.

Сөләйман дәвере Яһүди дәүләтенең иң якты дәвередер. Сөләйманнан соң Яһүди дәвләте икегә аерылды: җәнубтә (көньякта) Сөләйман пәйгәмбәрнең токымнары тарафыннан идарә ителгән Иуда (Иудея) корольлеге, шималда (төньякта) Израиль корольлеге. Шимальдагы Израиль корольлеге б.э.к. 718-дә Ассирия короле Сарган II тарафыннан җимерелде, җәнүбтәге Иудея дәүләте б.э.к. 606 да Вавилон хөкемдары Навуходоносор (б.э.к. 605—562) тарафыннан яулап алынды вә Яһүди милләтенең зур бер өлеше әсирлеккә эләгеп, Вавилонга китерелде. 536-да Вавилон иранлылар тарафыннан буйсындырылып, яһудиләргә ватаннарына кайтырга рөхсәт бирелгәнгә кадәр, алар җитмеш ел шунда әсирлек хәлендә яшәделәр.

Б.э.к. 536 тарихында яһүдиләр яңадан Палестинага әйләнеп кайттылар.

Бу вакыттан соң яһүди милләте бер ара йә берәр бөек дәүләткә буйсынган рәвештә, йә мөстәкыйль рәвештә яшәде. Соңга таба яһудиләр бөтен дөньяга таралдылар.[33] Бер өлеше яшәгән өлкәләрнең телләрендә сөйләшә башласалар да, борынгы телләре булган иврит, дини йолалар теле буларак, кулланышта сакланып калды.

Яһүдиләр бөтен дөньяга таралган хәлдә дә (бу таралып вә жәелеп яшәү урыннарын ДИАСПОРА дип атыйлар) миллият тойгыларын, милли аңларын һичбер заманда югалтмадылар. Төрле өлкәләрдә яшәгән хәлдә, милләтнең бөтен өлешләренә хас булган аң яһүдиләр арасында даими куәтле бер хис булып яшәде. Аларда бу хис һичбер заманда загыйфләнмәде.

Унтугызынчы гасырда яһүдиләр арасында миллият хисе бөтенләй куәтләнде. Кайберләре тарафыннан онытылган, милли телләре булган иврит телен тергезү, яңадан шушы телдә аралашкан бер милләт булу вә мөстәкыйль яһүди дәүләтен булдыру теләге, яһүдиләр өчен төп идеал урынын алды. Һәм бу максатка юнәлтелгән эшчәнлек киң хәрәкәт төсен алды. Яһүдиләр арасында күп тарафдарларын тапкан бу агымга «сионизм» исеме бирелде.[34]

Сионизм агымының лидерларыннан Һерцель исемле яһуди миллиятчесе яһүдиләрнең милли идеалын тормышка ашырыр өчен жаны-тәне белән тырышты.[35] Моның нәтиҗәсендә вә шимали Америка яһүдиләрнең мәдди вә мәгънәви ярдәмләре белән яһудиләр 1948 елны Палестинада яңадан мөстәкыйль Яһүди дәүләтен коруга вә Тәүрәт телендә сөйләшә торган милләтләрен торгызуга муафыйк булдылар.

Яһүди милләтенең миллият тойгысының ике мең ел буе уяу булуында, борынгы дәверләрдән калган язма әдәбиятының да роле зур булды.[36]

Яһүди милләтенең борынгы дәверләрдән калган әдәби әсәрләренең бөтенесе пәйгәмбәрләр иҗатына кайтарып калдырылган әсәрләрдер. Бүген бу әсәрләрнең күбесе яһүдиләр тарафыннан гына түгел, христиан галимнәре арасында да бөек изге китаплардан саналалар. Дини булуы белән бергә дәвамлы рәвештә яһүди милләтенең тарихын сөйләгән вә шуның белән яһүдиләрнең үзенчәлекле милли хисләренә туры килгән бу әдәбиятның яшәве вә моның изге бер мирас булып күзаллануы, һич шөбһәсез, яһүди милләтенең яңадан дәүләт кора алуында мөһим алшарт булды.

**Искәрмәләр:**

1 Genese, X.5

2 Gustave Fougeres et ses collaborateurs, Les premieres civilisations, Liv. II, Ch.II.

A.Moret et G.Davy, Des clans aux Empires, PP.282—302, Leon Hamo, Histore d'orient, Ch.1.

3 C.Leonard Woolley, les Summeriens, Paris, 930. A.Moret et Davy, Op.Cit. P.231—246. Fougeres, Op.Cit.Liv.I. Ch.IV, VI, VIII.

4 Helmolt's, Geschicte der Mensehheit, cilt IV.

5 Herodote, Liv.VI, I—CXL.

6 Herodote, Liv.VI, I—CXLIII Hemolt's, op.cit.IV, pp.281—283.

7 Phrynicus M.E. V гасырда язган шагыйрь, мәшһүр Аристофанның көндәше иде.

8 Helmolt's Op.Cit Tome IV, s.281.

9 Th.Mommsen Histore romaine, Tome II, Liv.III, Ch.I, II, III, IV, V.

10 Lavisse et Ramband, Histoire generale, Tome III, Ch.III.

11 Жанна д'Арк кешелек тарихындагы иң саф, иң сөекле милли

каһарманнарның берседер.

[12] Иранда «Шаһнамә», Кытай Төркстанында «Кутадгу Белек» әсәрләренең язылуы иранлыларда вә төрекләрдә милли аңның уянуына этәргеч биргән хәдисәләрдер.

[13] Ramsay Muir, Nationalisme et internationalisme, Paris, 1918.

[14] Ch.Seignobos, Histoire politique de l'Europe, Paris, 1921. Georges Weil, l'Eveil des nationalites et le mouvement liberal. Paris.

[15] De Ferrand, Histoire des trois demembrements de la Pologne, Paris, 1820.

[16] Хәзерге Польшада коммунистлар хакимиятен мин шәхсән вакытлы бер хакимият итеп кенә кабул итәм.

[17] Bertrand Auerbach, Les Races et les nationalites en Autriche. Paris, 1917. L.Leger, la Renaissance tcheque au dix-neuvieme siecle.

[18] O'Conor, History of the Irish people. Manchester, 1883. Ch.Seignobos, Histoire politique de l'Europe contemporaine ch.IV.

[19] Автор бу китапны 1952 елда язган, ул чакта бу милләтләр әле бәйсезлекләре өчен көрәш хәлендә генә иделәр (нәшрият).

[20] Бүген бу милләтләр кабат русларның кул астына төшкән булсалар да, бу хәл якын киләчәктә үзгәрер дип ышанам.

[21] Рим дәүләтенең формалашуында, римлыларның мәдәниләшүендә борынгы греклардан да элек зур роль уйнаган, югары мәдәнияткә, мөстәкыйль бер телгә, чәчәк аткан бер культурага, милли кануннарга (законнарга), милли язуга ия булган, дәвернең бөтен мәдәни милләтләре белән сәүдә итүче булган этруск милләтенең тулысынча юкка чыгуы, аның римлылар эчендә эреп бетүе, бу — миллият мәсәләсенә мөнәсәбәте булган һәр кешене кызыксындыра алырлык бер күренеш булып кала. Соңгы 50 ел эчендә этрусклар турында бик күп хезмәтләр язылган. Мөнәсәбәте булган кешеләргә без бу китапның авторының «Гомуми хокук тарихы» исемле әсәренең 5-нче китабындагы 1-нче бүлекнең 60-нчы параграфында күрсәтелгән хезмәтләрне тәкъдим итә алабыз.

[22] Chronique de Dalimil.

[23] Чехлар яшәгән географик өлкәнең исеме.

[24] Бу сәясәт нәтиҗәсендә ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булган зыялыларның берсе — тәрбия гыйльме олкәсендә күренекле урын тоткан Амос Коменский (1592—1670) була. А.Коменский — укыту һәм тәрбия өлкәсенә караган «Зур дидактика» исемле хезмәтнең мәшһүр авторы. Бу әсәр хакында атаклы немец философы Лейбниц Коменскийның вафаты мөнәсәбәте белән түбәндәге сүзләрне әйтә:

«Әй, Коменский, синең белем һәм тәрбия бирү хакындагы киңәш-фикерләреңнең һәрберсе беркөн тормышка ашачак». Француз мөтәфәкире һәм тарихчысы Мишель дә Коменскийга, даһи, тәрбия гыйлеменең Галилее, дөньяда бер галим, дип бәя бирә. «Зур дидактика»ның иң төп үзенчәлеге — әсәрдә бөтен кешелек дөньясына карата тирән мәхәббәт һәм игелеклелек хисе өстенлек итүдә. Бүген Көнбатышта кабул ителгән укыту һәм тәрбия нигезләренең бөтенесе дә диярлек беренче буларак Коменский тарафыннан күтәрелгән. «Зур дидактика» Песталоций һәм Руссо әсәрләреннән дә алдарак язылганга, Коменский педагогия гыйлеменең нигез салучысы булып саналырга хаклы.

25 Томек Прага университетында профессор һәм Австрия парламентында әгъза була. Мәшһүр хезмәтләре — «Богемия, тарихы» һәм «Прага шәһәренең тарихы» исемле әсәрләр. Шәхсән, Томек миллият тойгысын югалткан дип саналган кешеләрнең күңелләре түрендә бу тойгының даими яшәгәнлеген, уңайлы шартлар туган тәкъдирдә аның кабат җанлануын күрсәтүче ачык бер мисал да. Томек егерме яшьләренә кадәр чехларның иске телен һәм бу телдәге әдәбиятны белми. Шундый бер әдәбиятның булуы хакында хәтта хәбәрдар да булмый. 20 яшенә кадәр бары тик алман мәдәнияте тәэсире астында формалаша. Чех миллиятчеләренә дә алман сүзләрен чех сүзләре белән алыштырырга омтылган телчеләр дип кенә карый. Тора-бара Томекның миллиятчелек хакындагы фикере тәмам үзгәрә. Тормышында булып узган бер-ике вакыйга Томекның бу үзгәрешенә сәбәп була. Иң беренче, чех миллиятчесе Йунгманның XVII гасыр башында Австрия гаскәре тарафыннан чехлар тар-мар ителгән Белагораны зыярәт кылган вакытта сулыгып-сулыгып елавы хакында ишетүе, ә аннан соң икенче бер миллиятче — лицей укытучысы Свободаның укучыларына чех җирләренең австриялеләр тарафыннан басып алынуы һәм буйсындырылуы тарихын сөйләгәндә елый башлавы турында ишетүе була. Томекка болар бик көчле тәэсир итә һәм миллиятчелек хакындагы фикеренең үзгәрүнә сәбәп була. Бу ике вакыйга Томекка чех миллиятчелегенең бары телчеләр фанатизмыннан гына тормаганлыгын, ә, бәлки, бу «кәлимәчелек» артында киң бер хис галәме барлыгын исбат итә: Шушыннан соң Томек миллиятче даирәләр белән бәйләнешкә керә, борынгы чех әдәби телен өйрәнә һәм борынгы әдәби әсәрләрне укый башлый. Бу әсәрләрдән мәгълүматы арта барган саен аның милли тойгысы да үсә һәм, ниһаять, чех милләтенең иң самими, иң акыллы һәм иң иманлы миллиятчеләрнең берсе булып җитешә.

[26] Чех милләтенең тарихы белән кызыксынучыларга түбәндәге әсәрләрне укырга тәкъдим итә алабыз: M.E.Denis. La Boheme depuis la montagne blanche; Pipini Sapasovic. Edebiyat tarihi, Tome II. Louis Leger, La Renaissance Tcheque; Louis Leger, Le Panslavisme; Bertrand Auerbach, Les Racers et Les nationalitees en Autriche. P.Springer, La lutte allemande-tcheque, dans la collection des etudes sur «Les formes du mouvement national dans les Etats contemporains».

[27] Фортһан милли телне әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрү өчен ниләр эшләргә кирәклеген белсә дә, үз милли телен фин телендә әсәр язарлык дәрәҗәдә белми. Шуңа күрә әсәрләрен швед яисә латин телләрендә яза.

[28] Дәүләтара хокук термины белән әйткәндә, Русия белән Финляндия арасындагы берлек Union personelle дән, хөкемдар берлегеннән гыйбарәт була.

[29] Калевала — каһарманнар өлкәсе дигән сүз. Дастанның әдәби кыйммәте турында заманыбызның мәшһүр тел белгече Макс Мюллер болай ди: «Бәшәриятнең дүрт бөек дастаны — «Илиада», «Махабарата», «Шахнамә» һәм «Нибелунген»нан соң бишенче итеп «Калевала» саналырга тиеш. (Jules le Clerog, la Finlande aux mille lacs p.168). Радловның «Proben der Volkslitteratur der nordlichen Turkischen Stamme», Teil V, SS I—XXIV хезмәтендә кара-кыргызларның «Манас» дастанына кереш буларак язылган сүзендә милли дастаннарның ничек барлыкка килүе турында мөһим фикерләр бар.

[30] Фин милләтенең һәм фин теленең үсеше-үзгәреше хакындагы хезмәтләр: Jules le clerg. La Fenlande aux mille lacs. Paris 1914 (L'Epopee finnoise, 150—205). Reuter, la Finlande et les Finlandais. Jacop Crimm Uber das finnische Epos. Helmolt, Gescichte der Menschheite. Tome VI, Fasil x, j.3.

[31] — Ибраһимның пәйгамбәрлегенә карата Коръәндә шактый аятьләр бардыр. Шул җөмләдән «Нисан» сүрәсенең 161-нче аяте. Бу аятьтә Исмәгыйль, Исхак, Йакуб, Сөләйман вә Дауд пәйгамбәрлеге дә тасвирлана. Риваятьләр буенча Ибраһим пәйгамбәр безнең эрага кадәр 1996-да туа, 1821-дә вафат була.

[32] — «Нисан» сүрәсенең 162-нче аятында Мусаның пәйгамбәрлегенә дә ишарә бардыр. Яһүдиләрнең Мисырдан чыгып китүләре Мисыр фиргавенләре Аменофис II (1447—1420) вә Тутмес V (1420—1410) дәверләренә туры килүе чамалана. (Gustave Fougeres, Les Premieres civilisations. P.233).

[33] — Урта Шәректә ислам дине таралганнан соң, ислам мәмләкәтләрендә

яһүдиләр һич бер заманда Аурупаның христиан мәмләкәтләрендәге кебек золымга вә хокукларын чикләүгә дучар булмадылар.

34 — Сионизм, «Сион» сүзеннән килеп чыккан (ясалган) бер төшенчә. «Сиончылык» димәк. Сион исә Кудүстагы бер калкулыкның атыдыр.

35 — Т.Һерцель әсәренең исеме «L'etat Juif» дыр.

36 — Яһүдиләрнең борынгы дәверләрдән калган әдәбияты өч өлештән тора:

1) дини эчтәлектәге әсәрләр;
2) пәйгамбәрләрнең кыйссалары;
3) әдәби вә әхлакый әсәрләр.

Дини эчтәлектәге әсәрләрнең иң мөһиме ислам милләтләренең әдәбиятында «Тәүрат» исеме белән мәгълүм булган, Муса пәйгамбәрнең иҗаты дип саналган биш китаптыр.

# V. ЗАМАНЫБЫЗДА МИЛЛИЯТЧЕЛЕК

## 1. МИЛЛӘТЛӘРНЕҢ ҮЗ-ҮЗЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ ПРИНЦИБЫ

Бүген миллияткә дошмани караштa булган язучыларның үткәрергә тырышкан фикерләрнең берсе, миллият әсасының, янәсе, инсанлыкка вә инсани теләктәшлек принципларына туры килмәүедер. Бу фикер социологик вә психологик караштан шул кадәр нигезсездер ки, кайбер җитди тикшерүчеләр тарафыннан да тәкрарлануына хәйран калмыйча мөмкин түгел.

Югарыда әйткәнебезгә, миллиятчелек, инсанларның үз милләтләренә карата тойгылары бәйләнешеннән гыйбарәт бер рухи хәләттер. Бу рухи хәләт ничек инде вә кайсы яктан инсани теләктәшлек белән, ягъни башка милләтләргә карата хаерхаһлык (киң күңеллелек) белән яраклашмасын?

Бөтен инсанлыкның мәдәни үсеше, икътисади муллыкка ирешүе, иҗтимагый яктан гадел бер низамга оешуы өчен, бөтен милләтләрнең хөр вә мөстакыйль булулары лязим түгелме соң?

Инсанлык милләтләрдән корылган бер бөтенлектер. Бөтенлекнең сәгадәте өчен аның өлешләрнең дә бәхетле булуы шарт түгелмени? Әлбәттә, шарттыр. Хакыйкәт шунда ки, теге яки бу милләтнең мәдәни үсеш өчен тырышуы, бәйсезлеген саклау өчен көрәшүе, ягъни миллиятлелеге, инсанлык мәнфәгатьләренә каршы килми генә түгел, киресенчә, бөтен инсаниятның бәхет вә иминлегенә ирешүнең юлыдыр. Чөнки бөтен инсаниятның алга баруы өчен иң эффектив юл - һәр милләтнең үзе өчен тырышуыдыр. Теге яки бу милләт үзенең камилләшүе өчен үзе тырышмаса, аның өчен кем тырышачак? Бу сөалгә төбигатьтә булган бер биологик канун җавап бирәдер: «Яшәргә теләсәң, үз хәләтеңне вә барлыгыңны үзең тәэмин ит, үзең өчен үзең тырыш». Бу канун шәхесләргә кагылган кебек, милләтләргә дә кагыла.

**Һәрбер милләт өчен үз хәятен вә барлыгын, мәдәниятен, иминлеген вә сәгадәтен башка милләтләрдән көтү, башка милләтләрнең ярдәмләренә салыну бик ялгыш юлдыр.** Моңа кайтып калган рухи халәтнең милләтләрне таркалуга, инкыйразга китереп җиткерүе мөмкин. Бу куркынычлы рухи бер халәттер. Чөнки «инсанлык» асылында бер абстракт фикер, «абстракция» ята.

Реаль гәүдәләнештә булган барлыклар исә итле, сөякле инсаннардан торган милләтләрдер. Бу милләтләр эчендә башка милләтләргә карата кардәшлек хисләре кузгатып торучыларның да булулары мөмкиндер.[1] Әмма милләтләр, милләт буларак, башка бер милләтнең бөтен дәртләренә кызыксынмаслар. Һәрбер милләтнең милләт буларак мең дә бер дәрте бардыр. Калкып чыгу, үсү өчен тырышу, табигый буларак, һәр милләтнең үз өстенә төшкән вазыйфасыдыр.

«А» милләте «В» милләте өчен эшли алмаганы кебек, шәрә бер төшенчәдән гыйбарәт булган «инсанлык»та «В» милләтенең үсешенә үзеннән башка күп эшли алмас. Ни бүген, ни тарихта мәдәни яктан артта калган милләтне мәдәниятле, имин, вә бәхетле кылыр өчен, башка милләтләрнең үз файдаларын күз алдында тотмыйча нидер эшләгәнләре күренмәде. Ерак гасырлардан бирле хәбәшләрнең (эфиоплыларның) күпчелеге христиан динендә булуга карамастан, диндәшләре булган мәдәниятле христиан милләтләренең һич бере бу өлкәне мәдәниләштерү һәм үстерү өчен ярдәм кулын сузмадылар. Муссолини бер заман Хәбәштан белән кызыксынуын күрсәтсә дә, бу Хәбәштанның яшәешенә булышу өчен түгел, киресенчә, аның сәяси барлыгын юк итү, олы тарихка ия булган бу милләтне әсир итәр өчен иде.

Хәлбуки, моннан йөз ел элек заман мәдәниятеннән мәхрүм булган япон милләтенең үз эчендә туган үсү ихтияры вә системалы рәвештә моның өчен тырышуы аркасында бу милләт бүгенге дөньяның иң мәдәниятле милләтләре арасында данлыклы урын алды. Бу үсеш башка милләтләрнең тырышулары вә ярдәмләре белән булдымы? Юк. Бу япон милләте эчендә туган миллиятчелек ташкыны аркасындагы вакыйга

булды. Әгәр бүгенгә кадәр япон миллиятчеләре «Ауропаның кайбер мөтәфәккирләре (мөтәфәккир — фикер иясе) вә кайбер сәяси партияләре миллиятчелекне хупламауларына, аны кирелек күренеше дип санауларына карап, үз милләтләренең алга китүе өчен гайрәтләнеп ныклап эшләмәсәләр. бүгенгә кадәр япон милләте бөек бер дәүләтнең колониясы булудан котыла алмас иде.

Һич шәбһә юктыр ки, миллиятчелек милләтләр өчен иң тәэсирле үсеш вә камилләшү гамәледер. Миллият тойгысы милләтләр арасындагы теләктәшлеккә каршы күренеш диючеләрдән сорыйк: Теге яки бу милләтнең милли тойгысының тәэсире белән мәдәният майданында үсеш өчен тырышлыгыннан инсаният нинди яктан зыян алыр икән? Азия вә Африкадагы берәр милләтнең миллиятчелек агымы аркасында милли вә икътисади үсүләреннән, җәнүби Америка милләтләре, мәсьәлән, Аргентина яки Бразилия, дәүләте, нинди яктан зыян күрде? Бу милләтләрнең үсүеннән зур дәүләтләрнең колониаль сәясәте, бу мәмләкәтләрнең зур капиталистлары вә бай сәүдәгәрләре зыян күрсәләр күрер. Соңгыларының эгоистик мөнфагатьләре яшәргә вә үсешкә юл тоткан бер милләтнең законлы вә тормышчан максатларыннан ваз кичүе өчен сәбәп була аламы?

Миллиятчелекнең тәрәкъкыять гамәле икәнлеге инкарь ителмәслек бер хакыйкать булган хәлдә, кайбер язучыларның миллиятчелекнең кешлек дөньясы күзлегеннән зарарлы бер агым дип расларга тырышулары ирексездән кешедә шундый бер сөал уята: гәҗәб, бу язучыларның миллиятчелекне зарарлы бер агым дибрәк күрсәткән хезмәтләрендә үз мәмләкәтләрендәге хакимиятләренең империалистик вә колониалистик сәясәтләрнең вә дөньякүләм капиталистларының тәэсире юкмы икән? Гәҗәп, бу язучыларның аңлы яки аңсыз рәвештә Азия вә Африканың мәдәни яктан артта калган милләтләрнең милли уянышларына ауропалыларның моңа кадәр хакимлек иткән базарларын югалтуларына киртә кую өчен миллиятчелекне бер куркыныч нәрсә итеп күрсәтергә тырышулары нәтиҗәсе түгелме икән? Бигрәк тә колониаль милләтләрдән чыккан язучыларның миллиятчелекне тискәре вә зарарлы бер агым

булуы турындагы фикерне дәвамлы рәвештә яклаулары, үзе объектив фикер йөрткән һәрбер кешедә шөбһә уятырдай бер нәрсәдер.

**Бүген милләтләрара хезмәттәшлек, шәкелләренә карамастан, һәр милләтнең үзе өчен үзе тырышуы, үз җирлегендә вә үз имкянларына таянып калкып чыгуы вә ярдәмне үзеннән эзләп табуы миллиятчелек принципларының берседер.**

## 2. МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЛӘР ФЕДЕРАЦИЯСЕ

Бүгенге реалист миллиятче һәр нәрсәне үз милләтеннән көткәнгә күрә, сугыш дигән афәтне булдырмас өчен, башка милләтләр белән берләшеп федерацияга керү фикерен билгеле шартларда кабул итә алачак. Чөнки бүгенге хәрби кораллар кешелек алдына бөтен кискенлек белән «булу яки булмау» мәсьәләсен китереп куйды.

Заманыбызда милләтләр арасындагы каршылыкларның вәһшәт вә варварлык дәверендәгечә кораллы бәрелешләр вә сугышлар юлы белән хәл ителүенең бүгенге мәдәният вә культура дәрәҗәсе белән тәңгәл килмәве һәм моның бөтен кискенлеге белән кире кагылырга тиешлеге киң таралган ныклы бер фикердер.[2]

Бу фикер бары тик әхлакый күзлектән генә туган караш булмыйча, объектив әсасларга таянган реаль чынбарлыкның чагылышыдыр.

Чөнки бүгенге дәһшәтле кораллар вә җимергеч чаралар юлы белән сугышларны дәвам иттерү инсаниятның юкка чыгуы белән килешүгә бәрабәр булыр иде. Бу яктан, тынычлыкның кыйммәтлегенә инанган һәрбер инсан сугыш куркынычына юл куймауга, әлбәттә, зур әһәмият бирәчәктер. Агрессив сугышларга[3] каршы куярдай чара вә чамаларны табу, шөбһәсез, бүгенге инсаният өстенә төшкән вазыйфадыр.

Сугышларга юл куймауның имкяннары бармы соң? Булса, моның юллары нинди?

Югарыда күргәнебезчә, радикаль космополитлар карашынча, сугышларны юк итү өчен милләтләрнең милли хисләрен

сүндерергә, милләтләрне юкка чыгарырга вә инсанлыкны миллиятсез масса хәленә китерергә кирәк. Бу карашның социологик вә психологик яктан ялгыш бер караш икәнлеген югарыда һәртөрле дәлилләр белән исбат иткән идек.

Сугышларны юкка чыгарыр өчен алга сөрелгән фикерләрдән бере — аларга юл куймастай гәскәри көче булган көтле бер милләтара тәшкиләтның мәйданга килүедер, ягъни, дәүләтләрнең бер ФЕДЕРАЦИЯ рәвешендә берләшмәсен тудыру.[4]

Бүген күп кенә мәмләкәтләрдә федерация фикерен җәелдерү максатын алларына куйган эшлекле федералистик җәмгыятьләр дә корылдылар.[5] Федералистлар карашларынча иң әүвәл һәр кыйтгадә аерым-аерым федерацияләр, федераль берләшмәләр корылыр, соңыннан исә бу федерацияләр берләшеп дөнья федерациясын тәшкил итәрләр.

Бүген ике төр федерацияның нигезләре салынган. Аурупа Шурасы (Conseil de L'Europe) исеме белән мәгълүм, мәркәзе Страсбург шәһәрендә булган берләшмә Аурупа федерациясен тормышка ашыру юлындагы бер адымдыр.[6] Мәркәзе Нью-Йоркта булган Берләшкән Милләтләр (United Nations) тәшкиләте исә, дөнья федерациясенең корылыш юлындагы бер омтылу вә тәҗрибә мисалыдыр.[7]

Күргәнебезчә, федерация фикере әгъзаларының игелекле нияттә булган тәкъдирдә, тормышка ашырылуы мөмкин булган бер фикердер.

Аерым федераль тәшкиләтнең яшәве өчен бу оешманың психологик вә социологик яктан реалистик вә рациональ әсаслар нигезендә корылуы шарттыр.

Бу әсаслар ниндиләр соң? Һич шиксез рәвештә әйттә алабыз ки, бүгенге демократик дәүләтләрнең таяныч принциплары нинди булса, федерацияләр төзелешендә дә шул ук принциплар игътибарга алыналар. Бүгенге демократик дәүләтләренең таяныч принциплары исә түбәндәгеләрдән тора:

1. Шәхес дәүләт өчен түгел, киресенчә, дәүләт шәхес өчендер.

2. Шәхесләрнең дәүләт тарафыннан инкарь вә бозыла алмый торган табигый хаклары бардыр. Бу хаклар шәхесне

һәр төрле эзәрлекләүгә чик куйган бер мәгънәви ныгытманы тәшкил итәләр.

3. Дәүләт шәхесләрнең хокукый яктан танылган табигый хакларын тулысынча хөрмәт итәргә тиештер.

4. Дәүләт шәхесләрнең хәят вә хөррияте белән үзе теләгәнчә эш итә торган бер залим күәте түгел, киресенчә, күәт вә вәкаләтләрен шәхесләрнең (ягъни, ватандашларның) хуплаулары, ризалыклары белән ала торган бер хокукый оешмадыр.

5. Шәхесләрнең хокукый яктан танылган хак вә хөрриятләрен инкарь иткән яки кире каккан дәүләт үз барлыгы сәбәпләрен дә инкарь иткән булып чыга.

6. Бер тарафтан шәхесләрнең хак вә вазыйфалары, икенче тарафтан дәүләтнең вәкаләте вә җаваплыгы Конституция белән ачык сүрәттә билгеләнә вә раслана.

Шулай итеп, Милләтләр Федерациясы бер заманны корыла калса, ул бүгенге демократик дәүләтләр нигезләнгән әсасларга таяначак. Дәүләтнең көче вә абруе шәхесләрнең табигый хаклары белән чикләнүе кебек, Федерациянең вәкаләтләре дә милли дәүләтләрнең милли хакимияте, ягъни, милли суверенитеты (Souverainete nationale) белән чикләнәдер. Бу әсас федераль хокукның иң мөһим принципы булып тора.

Биредә мөһим бер сөал туа: милли дәүләтләрнең хакимияте даими рәвештә сакланса, федераль дәүләтнең вәкаләте нидән гыйбарәт булыр?[8] Бу мөһим сөалнең җавабы шулдыр:

Федераль дәүләтнең вәкаләте Федераль дәүләтнең Конституциясендә (ягъни, федераль дәүләт рәвешендә берләшкән милли дәүләтләрнең үз араларында имзалашкан аңлашмада), асылда милли дәүләтләрнеке булып та, федераль дәүләткә тапшырылган вә ачык, төгәл рәвештә билгеләнеп күрсәтелгән вә чикләнгән хокуклардан торган вәкаләтләрдер.[9] Федераль дәүләтнең вәкаләте теге яки бу ватандашның адвокатка биргән «вәкаләтенә» охшаш әсаска нигезләнгәндер.

Федераль дәүләтне тәшкил иткән милли дәүләтләр асыл хакимият хокукларыннан баш тартмыйлар, алар бары аерым хакимият хокукларын билгеләнгән вә чикләнгән күләмдә файдалану өчен федераль дәүләткә вәкаләт бирәләр.

Федераль дәүләтнең милли дәүләтләрнең бәгъзе хокукларыннан файдалану хокукы вәкаләтләрне тапшырудан туадыр. Федераль дәүләт милли дәүләтләр өстендә торган һәм югары хакимияткә ия булган ниндидер бер залим, бер әмир түгел, бары билгенгән вә чикләнгән өлкәләрдә милли дәүләтләр исеменнән хәрәкәт иткән бер вәкил, бер тәмсилчедер.

Милли дәүләтләр бөтен күләмдәге хакимият хокукларын федераль дәүләткә тапшыра алалармы? Бу сөалгә җавап федераль дәүләтнең корылышында яткан әсаси максатлардан тора. Федераль дәүләт коруының максаты, югарыда ишарә ителгәнчә, сугышлар мөмкинлеген булдырмастай чараларга ия булган бер милләтләрара тәшкиләт төзү. Шуңа бәйле рәвештә федераль дәүләтнең вәкаләтен билгеләр өчен милли дәүләтләр арасында сугышлар тудырырдай каршылыкларның сәбәпләрен ачыклау зарурияте туа. Күзәтүләр күрсәткәнчә, милләтләр арасындагы сугышларны барлыкка китерә торган гамәлләрнең мөһимнәре түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. Дөньядагы икътисади байлыклардан милләтләрнең гадел рәвештә файдалана алмаулары;

2. Хәрби вә икътисади яктан үзләрен күәтле сизгән кайбер милләтләрнең, зәгыйфь күренгән милләтләрне кыерсытып, шул милләтләрнең байлыкларын тартып алу вә аларны мәхкүм милләт дәрәҗәсенә төшерергә омтылышның күренеше.

Шуңа күрә федераль дәүләтнең вәкаләтләре түбәндәгеләргә кайтып калалар:

1. Бер тарафтан таш күмер, бензин, тимер, корыч[10] кебек мөһим икътисади байлык чыганакларыннан файдалану ысулларын тәртипкә салу эше белән шөгыйльләнү;

2. Икенче тарафтан бөтен дәүләтләрнең килешүе нигезендә оештырылган уртак армияне идарә итү белән шөгыйльләнү.

Күренә ки, болар җитдилекләре ягыннан бик дәрәҗәле вазыйфалардыр. Артык аңлатуның хәҗәте дә юк, күз алдыбызга китергән яки хыялланган бу федераль дәүләтнең федерациягә кергән милләтләрнең депутатларыннан торган парламенты, милли дәүләтләрнең вәкилләреннән төзелгән сенаты, милли дәүләтләр исеменнән федераль дәүләтнең эшләре белән идарә

итүче мәркәз хөкүмәте, милли дәүләтләр арасында барлыкка килгән каршылыкларны хәл итүче югары суды булачактыр.

**Милләтләрнең милләт буларак хөррияте, милли хакимияте, сәяси бәйсезлеге, милли дин, милли тел, милли мәдәният, милли традицияләр, милли мөкатдәслек дәирәсендәге хөррият вә хаклары федераль дәүләтнең компетенциясыннан читтә калачагы мәхсүс федераль Конституциядә ачык вә төгәл рәвештә күрсәтелә.**

Әгәрдә федераль дәүләт милли дәүләтләрнең урынын алып милләтләрдән вә дәүләтләрдән өстен бер әмир шәкелен ала калса, димәк милләтләр үз ризалыклары вә килешүләре белән үзләренең өстеннән торган истибдат мәркәзне барлыкка китергән булалар.

**Федерация корган дәүләтләрдән бере яки берничәсе начар ниятә булса, мондый куркыныч туа ала.**

**Сугышларга юл куймау кебек югары бер максатка омтылган милләтләр үзләренең тырышлыклары вә фидакарьлекләре нәтиҗәсендә кулларында булган хакимиятләреннән вә милли даирәдәге хөрриятләреннән һич тә ваз кичмәсләр.**

Милли дәүләтләрдә шәхесләр табигый хокук вә хөрриятләреннән ваз кичергә мәҗбүр ителә алмаганнары кебек, федераль дәүләт эчендәге милли дәүләтләр дә милли хакимиятләреннән «ваз кичү»гә мәҗбүр ителә алмыйлар вә ителмәсләр, чөнки федерализмның максаты сугышларга юл куймау вә милләтара икътисади хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен мондый корбанлыкның һич кирәге юктыр!

Шул ук вакытта һәр өлкәдә радикаль агымнар булган кебек, федералистлар арасында да аерылып торган юнәлешләр бардыр. Мондый радикаль агымнар федерациягә кергән милли дәүләтләрнең федераль дәүләт файдасына милли хакимиятләреннән тамам ваз кичү, федераль дәүләткә һәр өлкәдә чикләнмәгән вәкаләтләр бирү тарафдарлары.

Бүген без федерация мәсьәләсенә кагылышлы күп кенә әсәрләрдә, бәгъзе сәяси корылышларда, хәттә Аурупа Шурасы кебек җитди оешмаларда да дәүләтләрнең милли хакимиятлә-

реннән ваз кичүләре (renoncement a la souverainete nationale), яки баш тартуларын (abandon de la souverainete) лязименә даир фикерләр очраганын да күрәбез.

Бу бик хата вә федерализмның җиңүе максатыннан чыгып караганда зарарлы күренештер.[11]

**Күп кенә милләтләрнең вә күп кенә инсанларның федерация фикерен салкын каршылауларның, бу фикергә күнегергә теләмәүләрнең әсас психологик сәбәбе, һич шөбһәсез, федерацияның миллиятнең дошманы рәвешендәге агым алуыннан куркуыдыр.**[12]

Сугышларга юл куймау өчен милли дәүләтләрнең вәкиле сыйфатында хәрәкәт иткән, милли дәүләтләрнең милли хакимиятләрен хөрмәт иткән, вәкаләте милләтләрара армия белән идарә итү, байлык чыганакларын бүлеп бирү вә милләтара икътисади хәятне тәртипкә китерү белән чикләнгән федерацияның корылуы бүген тынычлык тарафдарлары булган бер төркем зыялыларның теләгедер.

Һәрбер милләтнең мөкаддәс хакы булган милли хакимияттән ваз кичү исә һичкенә дә бәхәс мәсьәләсе була алмый.

## 3. АЗЧЫЛЫКНЫҢ МИЛЛИ ВӘ МӘДӘНИ МОХТӘРИЯТЕ

Бүгенге милли дәүләтләрдән барысының да диярлек халкы асыл милләт кешеләреннән генә гыйбарәт түгел. Бүгенге дәүләтләрнең күбесендә төп милләттән тыш, бу милләттән теле, мәдәнияте яки дине ягыннан аерылып торган вә дәүләт эчендә азчылык тәшкил иткән этник яки дини төркемнәр яши. Мәсәлән, Италияда итальянлардан башка алманнар (Тирольда), хорватлар; Юнанстанда (Грецияда) арнаутлар, алманнар, итальянлар, төрекләр; Маҗарстанда алманнар, хорватлар, румыннар; Төркиядә греклар, әрмәннәр, яһудиләр яши.

Борын-борыннан Русия исемле географик киңлектәге советлар дәүләтендә дә рус булмаган бик күп милләтләр вә кавемнәр яшәгәнлеге һәркемгә мәгълүмдер.

**Без, төркиләр өчен, азчылык проблемасы бигрәктә мөһимдер. Чөнки иң киме унике мәмләкәттә төрки азчылыгы яшидер.**

Хакыйкаттә, дөньядагы бөтен этник төркемнәрнең үз дәүләтләренә ия булулары имкянсыздыр. Чөнки милләтләрнең мөстакыйль дәүләткә ия булулары бер төр шартлар белән бәйле: элеккедән дәүләткә ия булулары, билгеле бер киңлектә (җирдә) тупланган хәлдә яшәүләре, дәүләт булып яшәр өчен кирәк кадәр халык массасы булуы бу шартларның иң мөһимнәреннәндер.

Миллият принцибы буларак аңлатылган эсас бөтен милләтләрнең дә тулысынча «дәүләткә ия булуга хаклы» дигән сүз түгелдер. Милләтләрнең милли дин, милли мәдәният, милли тел, милли традицияләр мәсьәләләрендә хөр вә ирекле булулары, бу өлкәләргә караган эшләрен дәүләт тыкшынуыннан тыш, үзләре идарә итә алулары дигән сүздер. Бүген кайсыдыр бер милләтнең күпчелек тәшкил итүе шартларында бу дәүләт эчендә яшәгән вә аның эчендә азчылыкны тәшкил иткән милләтләргә милли дин, милли тел, милли мәдәният өлкәләрендә хөррият вә хаклары тәэмин ителергә тиештер. Бу хакларга «Азчылык хаклары» исеме бирелгән.[13] Азчылыкның хокуклары Беренче Дөнья Сугышына кадәр милләтара хокукта танылган вә яклана торган хаклар түгел иделәр. Бу хаклар Беренче Дөнья Сугышыннан соң, бер тарафтан, милләтләрара аңлашмаларда,[14] икенче яктан «Милләтләр җәмгыяте» тарафыннан кабул иткән карарларда расланды вә тәэмин ителде.[15]

Азчылыкның хаклары бүген милләтләрара хокукый документларга да таяналар:

1. Берләшкән Милләтләр Уставы (Charte des Nations Uniens).[16]

2. Берләшкән Милләтләр тарафыннан кабул вә игълан ителгән кеше хокуклары Декларациясына (Declaration universelle des droits de L'Homme).

Бу ике документта «Халыклар җәмгыяте» (Лига наций) дәверендә кабул ителгән азчылык хакларының һәммәсе үзләренең урыннарын алдылар. Шулай итеп, аларны үтәү Берләшкән Милләтләр оешмасына кергән дәүләтләр өчен мәҗбүри булды.

Бирედә бүгенге азчылык хакларының бер хосусиятен белү кирәктер: Халыклар Җәмгыяте дәверендә имзаланган аңлашма-

ларда вә Халыклар җәмгыятенең оешмаларыннан чыккан документларда азчылыклар аерым «милли барлык» вә «дини төркем» төшенчәләрен алдылар. Азчылык хокуклары бу төркемнәргә билгеләнгән хокуклар дип таныла.

Берләшкән Милләтләр Уставының вә 1948 елда игълан ителгән Кеше хокуклары Декларациясенең аңлатмасы болардан аерыла: бу аңлатмага күрә милли телне куллану, милли телдә гыйбәдәт кылу, милли телдә нәшер итү, милли телдә укыту вә башкалар төркемнәргә түгел, азчылыкка кергән шәхесләргә билгеләнгән хаклардыр. Бу бик мөһим аерма.[17]

**Бүген миллионнарча кавемдәшләребез башка мәмләкәтләрдә азчылык булып яшәгән хәлдә, бу аерма безнең, төрекләрнең (төркиләрнең — ред.) диккатен җәлеп итәчәк күренештер.**

## 4. ЗАМАНЫБЫЗДА МИЛЛИЯТЧЕЛЕК НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?

Инсаниятнең иҗтимагый-психологик үсеше вә камилләшүе кешеләрнең дини, фәлсәфи вә милли карашларының хорәфәт, фанатизм, золымлык вә баскынчылык тенденцияләреннән эзлекле рәвештә арынуы вә мәгърифәтле инсанларның психологиясендә акылның җиңүе рәвешендә күренер. Башкача итеп әйткәндә, бу камилләшү бөтен иҗтимагый хәят принципларының рациональлашуы рәвешендә беленер.

Бер заманда католиклар дөньясында дини фанатизм аркасында, руханилар, католиклык әсасларыннан чигенгәннәрне, хәтта чигенүе мөмкин дип фикерләнгәннәрне инквизиция хөкеме белән үлем җазасына хөкем итү мөмкин, дип санадылар. XV-нче гасыр башында дини ислахчы Ян Гус вә XVI-нче гасырның ахырында философ Джордано Бруно фикерләренең католиклык дини әсасларына каршы булганлыгы өчен үтерелделәр. Хәтта дингә турыдан туры бәйләнеше булмаган бер гыйльми фараз белән чыкканы өчен Галилей да, үзенә эшләнгән җафалар вә куркытулар аркасында, хәкыйкәт булган, бүген хәтта башлангыч мәктәп укучысына билгеле булган җирнең әйләнешенә кагылышлы карашын халык алдында инкарь итәргә мәҗбүр ителде.[18]

Дини тәгассыблык католиклар дөньясына гына хас булмады. Габбаси хәлифәләреннән әл-Мансур дәвәрендә зиндыйкларны (Мани вә Маздак мәзһәбләренең тарафдарларын) хөкем итү өчен үзенә бер мәхкәмә (суд) оештырылды.

Бүген һичбер мәгърифәтле католик руханиеның яки диндар бер ислам белгеченең дин өлкәсендә мәмләкәттәге күпчелекнең инануларыннан аермалырак фикер йөрткән өчен кемнедер җәзага тарту фикере акылына килмәс.

Бүген дин өлкәсендә агрессия вә явызлык мәрхәмәтсезлеге дәвере узган кебек күренә. Чын диндар фанатизмның кирәге юк. Кайбер истисналар күренгәләнсә дә, әйтә алабыздыр ки, бүген һәр шәхес дин вә вөҗдан өлкәсендә үз ихтыярында кала.

Дин өлкәсендәге бу «рациональлашу» миллиятчелек өлкәсендә дә үзен сиздерә. Миллиятчелек шовинистик карашларны кире кага. Шуңа күрә бүгенге мәдәниятле милләтләрдә күзәтелгән һәм омтылышыбызда булган миллиятчелекнең үзенчәлекләрен шул рәвешчә нәтиҗәли алабыз:

1. Бүгенге миллиятчелек рациональ, мантыйкка вә акылга туры килүчән күренеш.

2. Бүгенге миллиятчелек социологик вә психологик әсасларга таяна: кан тикшерүләр белән шөгыльләнми, баш сөяге шәкеле белән дә кызыксынмый. Билгеле бер милләткә бәйлелек хисе бүгенге миллиятчелекнең әсасыдыр.

3. Бүгенге миллиятчелек хөрриятчедер, либеральдер.

4. Шул ук вакытта бүгенге миллиятче бөтен милләтләрнең үсеш сәләтләре ягыннан бертигез булуларына инана, өстен милләт, түбән милләт карашларын инкарь итә. Үз милләтенең башка милләтләргә карата хокук, хөррият вә гадәләт әсасларына туры килмәгән хакимият хакын дәгъваламаган кебек, башка милләтләрнең үзен буйсындыруга булган омтылышларын фикере, каләме, кирәк булганда коралы белән дә кире кага.

5. Бүгенге миллиятчелек демократиктыр. Мәдәниятле миллиятчеләр үз мәмләкәтләрендә дә, башка мәмләкәтләрдә дә халык хакимиятенең тарафдарларыдыр. Һәрбер мәмләкәттәге ниндидер бер шәхеснең яки бер «сыйныфның» башка төркемнәр өстеннән

хакимияте дә зарарлы вә шул ук вакытта гадәләт вә хөррият әсасларына каршы килә.

6. Бүгенге миллиятчелек тынычлык сөючәндер, агрессив сугышларның дошманыдыр.

7. Бүгенге миллиятчелек кирәк булса федерализмны да кабул итәчәк. Сугышларны бетерүнең бердәнбер юлы буларак федерализм идеясы расланса, рациональ әсасларга таянган, милләтләрнең хакимияте вә мохтәрияте белән килештерелгән бер федерациягa керү кабул ителәчәк.

8. Бүгенге миллиятчелек идеалистик вә оптимистиктыр, инсанлыкның, ягъни бөтен милләтләрнең һәр өлкәдә чикләмәгән килешү сәләтенә инана. Киләчәктә дөньяда тынычлык сөючәнлекнең хакимлек итәчәгенә, икътисади иминлек урнашуына, ирекле үсеш имкяннарының артуы нәтиҗәсендә бөтен милләтләрнең бүгенге көнгә нисбәтән мадди вә мәгънәви яктан тагын да бәхетлерәк булачакларына өмет итә.

Чын миллиятче киләчәктә, мадди вә мәгънәви үсешнең җайлырак шартларында яшәячәк инсаннарның яңадан яңа хакыйкатьләргә ирешүләренә, позитив белемнәр вә техника өлкәсендә яңадан яңа ачышлар ясаячакларына инана, вә бу бәхетле киләчәкне әзерләү максатында башка милләтләр белән хезмәттәшлек урнаштыруны үзенең вазыйфасы вә намус эше дип саный.

**Бүгенге миллиятче милли абруй, милли мөстәкыйльлек, милли мәнфәгать мәсьәләләрендә соң дәрәҗәдә таләпчән булу белән бергә, шовинизмнан ерак, рациональ, аңлы, уяу милли хисләр белән сугарылган инсандыр.**

## 5. МИЛЛИ ХИС ИҢ ДИНАМИК БЕР МӘГЪНӘВИ КУӘТТЕР

Билгеле булганча, җир йөзендә, электрик кебек, җир тартымы кебек, пар басымы кебек физик куәтләре белән янәшә, алар шикелле ук куәтле, алар кадәр ук тәэсирле мәгънәви куәтләр дә бардыр. Мәсәлән, сөйгәне белән кавышыр өчен таулар кичкән гыйшык, максатка ирешү өчен теләсә нинди киртәне егардай теләк көче, зәгыйф хатынны куәтле, куркак хатынны каһарман иткән аналык хисе...

Шулай ук милләтләрнең тарихында иң тәэсирле роль уйнаган мәгънәви бер көч — милли хисләр, миллиятчелектер. Теге яки бу милләтнең күпчелегенең рухында тирән, көчле милли хис вә аң чыганаклары булуы, ул милләтнең туфрагында бетмәс-төкәнмәс нефть коеларының булуыннан да мөһимдер.

Шуның өчендер ки, билгеле бер милләтне егарга теләгән чит пропагандалар «инсанлык гаиләсе», «дөнья ватандашлыгы» кебек әкиятләр белән шул милләтнең милли хисләрен, миллиятчелеген юк итәргә тырышалар. Әмма хәят ихтыяҗларыннан туган гаилә институты җимерелмәгән кебек, биологик вә социологик шартлар җирлегендә барлыкка килгән милләтләр дә, ягъни ырк күпчелегенә таянган милли дәүләтләр дә җимерелмәсләр. Ә аларның сугышларны булдырмас өчен, милли аң вә хакимиятләрен саклап калыр өчен тар яки киң өлкәле берләшмәләрне тәшкил итүләре мөмкин.

Соңгы гасыр дәвамында җәелеп киткән вә прогрессивлыкны дәгъвалаган космополитлык агымы, ягъни миллиятсезлек, бүген инсаният эчендә билгеле бер фәлсәфи, идеологик вә сәяси кризис тууына китерде. Бу кризис төрле пропаганда чаралары белән ясалма рәвештә вә алдан уйланып терелəндерелеп тора.

Милләт урынына халык төшенчәсен кулланып, бөтен инсаниятны берүк типтагы кешеләрдән вә берүк типтагы төркемнәрдән оешкан масса хәленә китерү ихтималы мөмкин булмаган бер буш хыял булып калганы кебек, каршылыкларның бердәмлегеннән торган дөнья аһәңе дә каршылыклыдыр. Ак, алсу, кызыл, зәңгәр яки сары төсләрдә, төрле-төрле шәкелләрдә, төрле-төрле исле гүзәл чәчәкләр белән бизәлгән бер бакча кебек, бүгенге инсаният тә аерым гадәтләргә ия булган милләтләрдән торадыр.

Бакчачының берсе чыгып: «Мин бу чәчәкләрне юк итеп, аларның урынына бер төсле, бер исле, берүк шәкелдә вә типтагы чәчәк үстерәчәкмен!» — диеп, бакчадагы чәчәкләрне өзеп ташларга тотынса, шөбһәсез ки, бу әдәм акылыннан язган дип, аны психик авырулар хастаханәсенә урнаштыру чарасы күреләчәктер.

**Сәердер ки, шуңа охшаш рәвештәге фикерләрне милләтләргә карата сөйләгән космополитларның, анархистларның, коммунистларның акыллары төзеклегенә шөбһә итү урынына, күп кенә саф инсанлар аларны прогрессчылар итеп кабул итәләр, сафсаталарына ышаналар.**

Нормаль, саф акыллы вә рухлы, психологик комплекс әшәкелекләренә бәйләнеше булмаган һәрбер инсанның миллиятче булуы табигыйдер. Миллиятчелек кирелек күренеше түгел, киресенчә, алдынгылыктыр. Нормаль кешенең белеме вә мәдәнилеге арткан саен, милли хисләре дә аңлырак бер кыяфәт алыр, ачыклык вә күәт казаныр.

Миллиятче прогрессчыдыр, чөнки ул киләчәгеен космополитлардан, миллиятсезләрдән, сулчылардан яхшырак күрә: миллият тойгысының милләтләр үсешендә ни кадәр зур роль уйнаганын күреп, инсаниятнең киләчәгендә дә ни кадәр тәэсирле бер фактор булачагын яхшы белә.

Миллият тойгысы аркасында милли горурлык, милли хәтер, тарихтан алынган тәҗрибәләр, ана теленә карата мәхәббәт, милли традицияләргә бәйлелек, милли мәдәнияткә таянып дөньякүләм хәятне күзаллау, яраткан шигърият, күңелләргә үтеп кергән сүз, үзенчәлекле, юмористик фикер ноктасыннан дөньяны аңлау, милләткә бөек хезмәтләре белән дан казанган милли каһарманнар белән горурлану кебек мәгънәви хәзинәләр тупланалар.

**Миллиятче бетмәс — төкәнмәс мәгънәви байлыкларга ия рухи бай һәм бәхетле бер инсандыр. Милли хистән вә милли изгелектән мәхрүм инсан исә, рухи яктан фәкыйрь бер мескендер.**

Милли хис, шәхесләрдәге кебек, милләтләрнең дә мәгънәви хәзинәләрнең чыганагыдыр.

Рухсыз барлык ниндидер бер мәет кебек булса, милли тойгылардан мәхрүм калган яки аннан аерылган милләт тә бәйсезлеген югалтуга дучар ителгән рухсыз бер массадыр.

Рухи барлыгыннан аерылганнан соң кеше хәяте белән ничек саубуллашса, милләтләр, милли дәүләтләр дә сәяси

җитәкчеләрендә вә лидерларында милли рух вә милли аң калмаса, хәлләре кызганыч. Башка бер дәүләт яки дәүләтләр бу рухсыз массаны үзләренә буйсындырудан кичекмәсләр. Чөнки болар миллиятсезлек микроблары тарафыннан умырып-умырып кимерелеп беткән, эченнән черегән бер гәүдәгенәдер.

Инсанлар өчен булган кебек, милләтләр өчен дә милли аң, миллиятчелек яшәешнең гәләмәте вә гарантияседер. Миллият тойгысы яшәү сәләтен саклый торган, милләтләрнең рухларын тотырган бер хис булганы кебек, тарихи вакыйгаларга да юнәлеш бирә торган тәэсирле бер башлангычтыр.

Без, төрекләрнең (төркиләрнең — ред.) иң якты дәверләребез, әйдәп баручыларыбызда милли аң вә горурлыкның иң куәтле булган заманнардыр.

Зур өлешенең югалуы, хәраб булуы шөбһәсез булган санаусыз мәдәният истәлекләребезнең Орхон язмаларында үзенең чагылышын тапкан ачык вә камил аң, вә бу истәлекләрне ясаткан төрекнең (төркиләрнең — ред.) бөек юлбашчыларында сизелгән вазыйфачанлык вә җавапчанлык хисе күп милләтләрне сокландырырлык куәттер.[19]

Милли хис вә аңның милләтләрнең вә инсаниятнең тарихында иң мөһим, иң куәтле, иң тәэсирле гамәл икәнлеген күз алдына китерү өчен бәйсезлеккә ирешү максатыннан алып барылган сугышыбызны хәтергә төшерү җитә.

Империя җимерелгәннән соң, 1919 ел башындагы Анатолия төрекләрендәге таркаулыкны Ататөрек нотыгының түбәндәге мәшһүр юлларында ачык итеп аңлатыла: «Төрек армиясының кулыннан корал вә башка сугыш кирәк-яраклары алынды... Антанта дәүләтләре вакытлы килешү хөкемнәрен үтәүне кирәк тапмыйлар, төрле сәбәпләр табып Антанта флоты вә гәскәрләре Истанбулга керделәр... Адана вилаяты французлар, Урфа, Марат, Антеп ингизлар тарафыннан алынды. Анталияда вә Коньяда итальян гәскәрләре, Мерзифан вә Самсунда инглиз гәскәрләре урнашты. Һәр тарафта чит ил офицерлары вә чиновниклары, хосусый кешеләре эш итәләр иде... 1919 елның 15-нче маенда Антанта дәүләтләренең хуплауы белән Греция гәскәре Измирга десант төшерде...»

Мадди күәт, мадди имкяннар ягыннан Төркиянең котылу чарасы калмады. Мантыйкый үлчәм буенча Мостафа Кемал ватан вә милләтне коткарыр өчен акылсызлык, диваналык юлына басты. Фәкать бу диваналык җидди бер хисапка, тирән бер ышанычка таяна иде. Мостафа Кемал үз терәген яндырган милләт гыйшыкы утына вә бу утның төрек милләтенең күңелендә булганына ышанып, саф милли хиснең мадди күәтләрне дә, мантыйкны да җиңә алырдай бер мәгънәви куәт икәнлеген белә иде.

Һәм чынлыкта да, бөтен дөньяны таңга калдырып, соңыннан күп кенә әсир милләтләргә үрнәк булып калган бәйсезлек сугыш могҗизасы булып мәйданга чыкты.

Асылда исә, бу мөгҗизә түгел, бәлки акылсызларны, җаһилләрне явыз ниятлеләрне инкарь итеп югарыга калкып чыккан күәтнең — миллиятчелекнең җиңүе иде.

Чөнки чын миллиятчелек милләтләрнең тарихында иң мөһим роль уйнаган, иң тәэсирле, иң динамик бер мәгънәви куәттер.

**Искәрмәләр:**

[1] Инсаниятның бербөтенлеген аңлап, бөтен инсаниятка тирән сөю хисләрен тудырган фикер ияләре тарихның һәр дәверендә күзәтелә. Румлылардан Цицерон, Сенека, Марк Аврелий, яңа заманларда Руссо, Кант кебек фикер ияләренең әсәрләрендә бөтен инсаниятkә карата хәерхаһлык хисе күәтле бер сүрәттә гәүдәләндерелә.

Дингә нигез салучыларның да хакыйкый максаты бөтен инсаниятны һәр ике дөньяда бәхетле кылудыр. Мондый фикер ияләре ислам дөньясында да барлыкка килә. Моның белән килешер өчен Фарабиның «Игелекле дәүләт» атлы әсәрен өйрәнү дә җитә. Иран шагыйрләреннән Шәех Сәгъдиның «Гөлестан» атлы әсәрендә, бөтен инсаниятны бер организм рәвешендә сурәтләгән мисрагълар бардыр. (Beni adem azayi yek digerend — (Адәм балалары бер бөтеннең өлешләре).

[2] Мәңгелек солыхны яклаган әсәрләрнең мәшһүрләре түбәндәгеләрдер: Antoine Marini, «Le pacte confederal» (V-нче гасырның икенче яртысында), монах Emeric Cruce «Projet d’une federation uniҗerselle» (ун алтынчы гасырда), Duc de Jully (1556—1641) «Sages et royales economies de I’Etat» William Penn, (1644—1718), «Essay towards the present and future peace of Europe by the establishment of a

european diet», Abbe de Saint Pierre (1658—1743), «Projet de traite pour rendre la paix perpetuelle en Europe», Kant (1724—1804), «Zum ewigen Frieden» St. Simon, (Et A.Thiery), (1760—1825), «De la reorganisation de I'Europe».

[3] Агрессив сугыш бер милләтнең башка бер милләтне бетерергә тотынуыдыр. Сакланып калу өчен сугыш исә милләтләрнең хаклы чарасыдыр. Агрессив сугышларга киртә була алачак бер абруйлы оешма барлыкка килмичә, сакланып калу өчен сугыш заруридыр.

[4] Федераль дәүләт турында түбәндәге әсәрләрне тәкъдим итәбез: George Jellinek «Etat moderne et son droit», Tome II, Ch XXI, S.S.530—563, Leon Duguit, Traite de droit constitutionnel, Tome III, Cphit IV, 58 A.Bushnell Hart, Introduction to the study of federal goҗernement, Boston, 1891.

[5] 1948-нче елны федералистик җамгыятьләр «Ауропачылык хәрәкәте» исемле федералистик җамгыятьләр берлеген тәшкил иттеләр. Бу мөһим тәшкиләтнең барлыкка килүендә Churhill, de Gasperi вә Spaak'ның рольлары бар.

[6] Аурупа федерациясе вә Аурупа Шурасы турындагы түбәндәге әсәрләргә мөрәҗагать итәргә мөмкин: Richard Coudenhove — Kalergi, Pan-Europe, 1923. Richard Coudenhove — Kalergi, Crusade for Pan-Europe, 1930. Benda, Discours a la nation europeenne, 1933. Oliver Philip. Le Probleme de I'Union Europenne. Edouard Bonnefous. L'idee Europeennt et sa realisation.

[7] «Берләшкән Милләтләр Тәшкиләте» турында түбәндәге әсәрләрне тәкъдим итәбез: Профессор Җәмил Билсәл, Берләшмеш Милләтләр, 1946. Louis Doliҗet «The United Nations, a handbook on the New World organisation», New-York, 1948. Бу әсәрнең ахырында Берләшкән Милләтләр Уставының тексты вә абруйлы гаделлек шураның низамнамәсе дә китерелгән. John Maclaur' in, the United Nations and power politiks, London, George Allen and Unwin Ltd. Бу әсәрдә кушымта рәвешендә Берләшкән Милләтләр тарафыннан 10 декабрь 1948 нче елны нәшер вә игълан ителгән «Инсан Хаклары Бәяннамәсе» китерелгән.

[8] Аңлатырга хаҗәт юктыр ки, биредә күздә тотылган федераль дәүләт, Федераль Алмания кебек бер дәүләттән, төзелеш ягыннан бөтенләй бащка булачактыр.

[9] Бу караштан корылмасы шушы рәвештәге тәшкиләтка конфедерация исеме бирелүе, мөгаен төгәлрәк булачактыр.

[10] Якын киләчәктә килешү өлкәсендә кулланылачак атом куәтен

җитештерү өчен лязим булган уран кебек мәгъдәнләр дә бу маддәләр арасында урын алачаклар.

[11] Француз социологы Альфред Фулле «Аурола кавемнәренең психологиясы» исемле әсәрендә яза: «Бүген французлар милләтенең бер өлеше үтә милләтчелеккә бирелеп калалар, башка бер өлеше исә «инсаният» күзлегеннән ватаны, миллияте әһәмияткә ия булмавын аңлаталар, милли хис вә фикерләрне көлке дип күрсәтергә тырышалар. Сарыкның «әхлакен» бүредән югары булуы әсасына таянып, безгә сарык булырга, күршедәге бүреләр тарафыннан җиңелергә риза булырга тәкъдим итәләр. Шулай итеп «инсансөю» дигән фәлсәфәнең гамәлгә килүенә инаналар; оныталар ки, күрше милләтләр «инсансөю» фәлсәфәсенә түгел, инсанлыкка каршы бер фәлсәфәгә таяналар. Вә бу фәлсәфәнең артында бик күп туп, куәтле вә җиһазланган бер гаскәр бардыр» (Alfred Fouillee, la Psycholoqie des peuples europeens, Preface).

[12] 1950 елны, июль аенда, Алманияның Констанс шәһәрендә Аурола Парламентлар Берлегенең конгрессы җыелды. Бу конгресста Төркия Милләт Мәҗлесе җибәргән һәйәтнең (делегациянең) җитәкчесе буларак мин дә катнаштым. Конгресста Аурупа Федерациясы мәсьәләсе бәхәс темасы булганга, бер чыгыш ясап, бу берләшмәнең Конституциясының әһәмиятенә дикъкатне юнәлттем вә Конституция Комиссиясен корырга тәкъдим иттем. Тәкъдимем кабул ителде вә тугыз аерым милләттән корылган Комиссиягә мин дә кердем. Бу тәкъдимемнең максаты, милли дәүләтләрнең мөһим хакларын, милләтләрара бер трибунадан яклап чыгар өчен форсат тудырырга, бу хакларны чикли торган берәр документның мәйданга килүенә комачауларга иде. Шулай итеп, төрле шәһәрләрдә җыелышлар уздырганнан соң, 1951 елның май аенда Страсбургта җыелган Аурупа Федерация Конституциясе проектын соңгы тапкыр тикшергән комиссияда, Конституция текстын раслау алдыннан түбәндәге ике әсасны кабул иттерүгә муафыйк булдым:

1. Федерациянең бөтен милләтләрнең «милли хакимияте» (милли хөкем сөрүе) белән төзелүе әсасы.

2. Федераль дәүләттә дәүләтләрнең вәкиле булган Сенатында зур булсын, кече булсын, бөтен дәүләтләрнең тигез санда сенаторларның булуы әсасы.

Мәгънәләре бик мөһим булган ике тәкъдимем дә комиссияда бер тавыштан кабул ителде.

[13] Азчылык хаклары асылда түбәндәгеләрдән тора:

1. Бер милли дәүләт эчендә азчылык тәшкил иткән милләтләр үз диннәре, телләре, мәдәниятләренә кагылышлы эшләрен үз теләкләре буенча алып баралар.

2. Милли мәктәпләр ача алалар. Бу мәктәпләрдә дәүләт телен дә укыту шарты белән үз телләрендә укытуны алып баралар.

3. Үз телләрендә төрле китаплар, журнал вә гәҗитләр нәшер итә алалар.

4. Гыйльми, иҗтимагый оешмалар вә хәйрия җәмгыятьләрен төзи алалар.

5. Бу хаклардан файдалану, азчылыкка кергән кешеләрнең яшәүләре, мәмләкәттәге башка ватандашларның хакларына зыян итәргә тиеш түгелдер. Бу мәсьәләгә кагылышлы әсәрләр:

Karl Strupp, Elements de droit international publiqҗe. Tome I, pp.101. Protection des minorites de race, de lanqҗe, et de religion par la societe des Nations. Geneҗe, 1927, Annexse I. Dr.G.A.Pordea, Federalisme et Minorites en Europe orientale, pp.69—71. I.N.Titulesko, La societe des nations et les Minorites, (Communication a L'Academic Diplomotiqҗe Internationale, 15 Mayis 1929) Slanses et Traҗaux. Tome I, pp.1 et suiҗ.

[14] Азчылыкларны яклаган әсасларны үз эченә алган килешүләр арасында азчылык хакларын иң тәфсилле сурәттә чагылдырган килешү 20 июньнең 1919-нче елында Польшада бөек җиңүче дәүләтләр арасында төзелгән килешүдер. Бу килешүнең беренче маддәсе килешүдәге әсасларны Польшаның милли кануны буларак игълан ителүен вә бу канунның Польша Конституциясенең ныклы нигезе булуын алдан билгеләде (Karl Strupp, Elements du droit international publque, Tome I, P.101.

Азчылыкларга караган маддәләрне эченә алган килешүләрдән тагын берсе, 14 майның 1923-нче елны Төркия белән бөек дәүләтләр арасында төзелгән Лозанна килешүедер. XV гасырда, солтан Фатих дәверендә мөселман булмаган милләтләргә бүләкләнгән хөрриятләр Лозанна килешүе тәэмин иткән хаклардан күп очракта киңрәк булганга, Төркиядәге азчылыклар хакыйкәттә Лозаннаныкыннан берәр нәрсә казану түгел, югалттылар гына.

[15] Азчылык хакларының асылы вә чикләре бигрәк тә Милләтләр җәмгыятенең 22 октябрь 1920-нче елны Брюссельда җыелган утырышында Титони'ның докладыннан соңгы карарда билгеләнделәр. Бу карарларда азчылык хакларының асылы вә чикләренә караган әсаслар билгеләнгәннән соң, азчылыкка бәйле килешү төзегән дәүләтләр

өчен азчылык хакларын үтәү мәҗбүрияте халыкара бер вазыйфа булуы да игълан ителде (Karl Strupp, op.cit. Tome I, P.103).

Бугенге заманда азчылыклар хакындагы килешүләрнең үтәлүен тәэмин иткән оешма «Милләтләр җәмгыяте» (Societe des Nations) оешмасыдыр. Бүген дәүләтләр эчендә азчылыкны тәшкил иткән милләтләрнең хокукый халәтләре нинди? Канәгатбез ки, азчылыкларның Милләтләр Җәмгыяте дәверендә танылган хаклары мәңгедер. Чөнки:

1. Милләтләрарасы хокукының әсаслары һәр заман язма маддәләргә таянмас, милләтләрара хокук мәйданында үз үзеңне раслауның да бөек роле бардыр.

2. Азчылыклар хокукы инсаниятның әхлакый вә хокукый үсеше җимешедер. Мәдәни кешелекнең әхлакый вә хокукый карашлары бүгенге дәрәҗәдә калганда, азчылыклар хокукы да мәңге калачактыр.

[16] Берләшкән Милләтләр Уставының 1, 13 (в) 55 (с) маддәләре вә XII-нче фасылдагы маддәләрнең берничәсе вә Берләшкән Милләтләр тарафыннан 10 декабрь 1948 елны игълан ителгән Инсан Хаклары Бәяннамәсенең 15-ләп маддәсе аеруча азчылык хакларының тәэмин ителүен максат итеп куялар.

Бу маддәләрнең иң мөһимнәре шулардыр: Маддә: 1, 2, 7, 8, 15, 18, 19, 20, 21, 22, 23, 26, 27.

The Universal declaration of human Rights. Appendix, in John Maclaurin's, The United Nations and Power politics. London. Charter of the United Nations. Appendix, in Louis Dolivet's The United Nations. New-York, 1948.

[17] Азчылыкларының милли дин вә милли мәдәният өлкәсендәге хөрриятләренә бәйле рәвештә Беренче Дөнья Сугышына кадәр күп әсәрләр язылды. Бу мәсьәлә белән аеруча Австриянең социалист язучылары кызыксындылар вә бу мөһим социологик мәсьәләне фәнни рәвештә өйрәнделәр. Азчылык хакларына бу язучылар тарафыннан бирелгән исем «Мәдәни-милли мохтәрият» (Autonomic nationale culturelle)дыр. Бу мәсьәләне иң гыйльми вә мантыйкый рәвештә өйрәнгән язучылар: Отто Бауер белән П.Шпрингер. Беренчесенең «Миллият мәсьәләсе вә социаль демократия», икенчесенең «Миллият проблемасы» атлы әсәрләре бүгенгә кадәр кыйммәтләрен югалтмаган әсәрләрдер.

[18] Башка бер мисал буларак Испания короле Шарль V-нче дәверендә, ул заманда Испаниягә буйсынган Голландияда протестантлыкка бәйләнешләре өчен илле мең голландлыларның үлем җәзасына хөкем ителү-

ләре, үлем төренең дә тере килеш яндыру яки тере килеш җиргә күмүдән гыйбәрәт булганын кайгы вә нәфрәт белән искә төшерәбез. (Henry Thomas Buckle, History of civilisation in England. Volume II, ch.I, pp.15—20).

[19] Билгеле булганча, Орхон язмаларының берсе, төреклелек горурлыгын чагылдырып, шушы җөмләләрдән башлана: «Югарыда зәңгәр күк, аста кара җир яратылганнан соң кеше баласы яратылды. Кеше балалары арасында бабаларым Бумин вә Истеми ханлар хаким булдылар. Хаким булганнан соң төрк дәүләте белән идарә иттеләр, төрк кануннарны төзеделәр. Дүрт тарафта бик күп дошман бар иде. Алар сугышып дүрт тарафтагы дошманларны буйсындырдыр. Алар бик бөек вә бик мәшһүр ханнар иде».

Орхон язмаларының башка бер җирендә 50 елга кадәр сузылган коллык дәвереннән соң, төрекләрдә Кытай изүеннән котылыр өчен барган көрәшнең нинди хисләр белән вә ничек башланганын тасвирлаган җөмләләрдән, ул замандагы төрекләрдә хаким фикерләрнең соңгы гасырларда да чит ил хәкимиятеннән котылырга омтылган милләтләрнең фикерләү рәвешеннән аерылгысыз булуын гаҗәпләнеп күрәбез: «Без дәүләткә ия бер милләт идек, хәзер ханыбыз кайда? Хәзер хезмәтебезне кайсы дәүләт, кайсы хан өчен сарыф итәбез?» Tomsen, kes Inscriptions de l'Orkhon dechiffrees, I.E., 10, 11, 24, 25, 26, 27, 28, 29.

## ЭЧТӘЛӘК

Китапны басмага хәзерләүчеләр исеменнән берничә сүз ... 3
Садри Максудиның тормыш юлы ... 7
**КЕРЕШ** ... 22
**I. ЫРЫК МӘСЬӘЛӘСЕ** ... 23
1. Ырык: антропологик мәгънәдә ... 23
2. Ырык: этнологик мәгънәдә ... 27
3. Ырыкларның килеп чыгышы ... 28
4. Өстен ырык теориясе ... 30
**II. МИЛЛӘТ ВӘ МИЛЛИЯТ** ... 43
1. Миллият тойгысының социологик вә биологик әсаслары ... 43
2. Милләтләрнең барлыкка килүе ... 48
3. Милли хиснең барлыкка килүе ... 55
4. Милли холык ... 58
5. Милли холыкның формалашуында бөек шәхсиятләрнең вә тәкълит канунының роле ... 60
6. Милләт вә миллият хакында киң таралган фикер һәм теорияләр ... 63
**III. МИЛЛИЯТ МӘСЪӘЛӘСЕНДӘ КАРШЫЛЫКЛЫ АГЫМНАР** ... 75
1. Космополитик агым ... 75
2. Космополитизмның психологик һәм социологик нигезләмәләргә каршылыгы ... 79
3. Шовинизм ... 86
4. Империализм ... 88

**IV. ТАРИХТА МИЛЛИЯТ ТОЙГЫСЫ** ........................ 91
1. Борынгы заманнарда һәм урта гасырларда милли хиснең роле ........................ 91
2. Яңа заманда милли хис ........................ 95
3. Әсир милләтләрнең уянуы ........................ 97
4. Чехларның милли уянышы ........................ 98
5. Финнәрнең милли уянышы ........................ 103
6. Яһүдиләрдә милли тойгынын ике мең ел буе уяулыкта булуы ........................ 107

**V. ЗАМАНЫБЫЗДА МИЛЛИЯТЧЕЛЕК** ........................ 115
1. Милләтләрнең үз-үзенә ярдәм итү принцибы ........ 115
2. Милли дәүләтләр федерациясе ........................ 118
3. Азчылыкның милли вә мәдәни мохтәрияте ............ 123
4. Заманыбызда миллиятчелек нинди булырга тиеш? .. 125
5. Милли хис иң динамик бер мәгънәви куәттер...... 127

**САДРИ МАКСУДИ-АРСАЛ.**
Миллият тойгысының социологик әсаслары.
*Оригинал-макет Галеевой Д.Р.*